Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 49 (1465) 15 декабрь 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga


12-13

Алтын Урдада үзбәк хан идарә иткән 1320 елларда аның бер кардәше Толбийәне Мисыр солтанына кияүгә бирәләр, Каһирәдә аның төрбәсе хәзер дә исән, аның исемендәге мәчет тә бар.


19

Татар халкы үзбәк, казах, кыргыз халыкларына Чыңгыз Әхмәров, Галия Измайлова кебек йөзәрләгән талантлар бүләк иткән, әмма үзбәк галиме Бегали Касимов бурычлы булып калмаган, безнең татар әдәбияты турында дистәләгән хезмәт язган.

23

Үзебезнең байтак авылларда калайдан табак-комган ясау, әхатын-кызларыбыз гап-гади оекбаш, шәл бәйләү һөнәрен онытып барса да, әлеге хезмәт Оренбург өлкәсенең Әсәкәй авылында гүзәл дәвам итә.

Бәрәкәтле яшәү сәнгатедер – Халкыбызның каз өмәсе дә!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Дәүләт Думасы барлык эшләүче ата-аналар өчен бала карау буенча пособиеләр түләүне хуплады.
- Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты үз утырышында 2024 елга җәмәгать транспортында йөрү тарифларын раслады, уртача тариф 9,5 процентка артачак.
- Татарстанның Әгерҗе районында -51 градус салкын теркәлде.
- Казанда Укытучы һәм остаз елына нәтиҗәләр ясалды.
- Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге оешуга 60 ел тулу уңаеннан «Әдәби Әлмәт» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды.
- Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Ленар Шәехнең «One Song Will Be Enough» исемле яңа китабы Лондонда басылып чыкты.
- Башкортстанның Чишмә районы Келәш авылы мәдәният йортында дин эшлеклесе, галим, язучы Зыя Камалиның 150 еллыгына багышланган тантана узды һәм авыл мәчете диварында бөек мәгърифәтчегә тактаташ ачылды.
- Санкт-Петербургның Татар мәдәни үзәгендә татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилгә багышланган иҗат кичәсе узды.
- Кырымның Симферополь шәһәрендәге Җәмигъ мәчетендә беренче җәмәгать намазы укылды.
- Уфада Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаевның 95 еллыгы уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды һәм шагыйрьнең «Сез белмәгән Атнабай» китабы тәкъдим ителде.
- Иҗау шәһәренең Габдулла Тукай исемендәге 6 нчы гимназия 25 еллыгын билгеләп узды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

15 декабрь – педагог, тел галиме, РСФСР Педагогика фәннәре академиясенең мөхбир-әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы Фазлуллинның тууына 140 ел (1883-1964);

– татар китабы эшлеклесе, әдип, тәрҗемәче, нашир Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнинең тууына 140 ел (1883-1934);

– актриса, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Бикә Шакир кызы Шакированың тууына 100 ел (1923-1996).

20 декабрь – шагыйрь һәм журналист Дифгать Шәмси улы Сираевның тууына 90 ел (1933-1985).

СЫНАМЫШЛАР

18 декабрьгә чана юлы төшә; бу көнне торбадан чыккан төтен өскә күтәрелсә – салкыннар башлана, аска төшсә – кар ява ● 19 декабрьдә көн нинди булса, 22 майда да шундый була ● Йолдызлар ачык күренсә – көн яхшыра, тоныкк күренсә – кар ява.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 08 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 11 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 03 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **4 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **22 декабрьдә 6 сәгать 59 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Декабрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 19 декабрь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(13-19 декабрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 2 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Әгъзам **ФӘЙЗРАХМАНОВ**

ТЕЛЕВИДЕНИЕ – тәрбия коралы



Татарстан телевидениесенең тарихы әлләни зур түгел. Ул үткән гасыр урталарында гына барлыкка килә. Беренче тапшыру тәҗрибә рәвешендә 1955 елның 27 февралендә күрсәтелә һәм чын мәгънәсендә могҗиза булып тоела.

«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә тыныч кына эшләп йөргәндә партия өлкә комитетының идеология буенча секретаре Мурзаһит Вәлиев чакыртып алды да: «Иртәгә син телевидениедә эшли башлыйсың. Бурычларны Фаик Газизович аңлатыр» – дип, сүзен йомгаклап та куйды. Мондый тәкъдим минем өчен бик гаҗәп иде. «Телевизорның нәрсә икәнлеген дә белмим. Тапшыруларын карагазым юк», – дип фикеремне җиткердем. «Белерсең, карарсың», – дип, Мурзаһит Вәлиев сүзсез генә миңа карап тора башлады. Сөйләшүнең тәмамлануын аңлап, саубуллашып чыктым.

Фаик Газиз улы мине телевидениегә алып барды. Тапшырулар бара торган студияне күрсәтте. Аның үзенең дә телевидение техникасын, тапшыруларның ничек оештырылуын рәтләп белмәве күренеп тора иде.

Миңа «Соңгы хәбәрләр» тапшыруларын әзерләү бурычы йөкләнде. Атнасына 6 тапкыр, рус һәм татар телләрендә, 15 әр минут. Татарча тапшыруларны алып бару өчен миннән кала бер генә хезмәткәр, ә русчаларын 4 журналист әзерли. Телевидение тапшыруларын әзерләүнең газета журналисты хезмәтеннән нык аерылып торуын бирәдә эшли башлауга ук яхшы тойдым. Таң атуга телевидениегә килеп, кичен үзебез әзерләгән тапшыруларны карагач кына өйгә кайтабыз. Хәйдәр Сөләйманович белән беренче көннәрдән үк һәр проблеманы үзара киңәшләшеп хәл иттек. Бәхәсле мәсьәләләр турында алдан сөйләшеп, нәтиҗә ясап, студиядә бу мәсьәлә буенча фикер барганда бер-беребезне якладык.

Телевидениегә эшкә килгәндә составны яңарту чорына туры килдем. Радио-телевидение комитетының яңа рәисе Фаик Надыйров һәм аның телевидение буенча урынбасары Хәйдәр Шакирҗанов тарафыннан кадрлар сайлауга да, һәр хезмәткәр эшчәнлегенә дә ныклы контроль урнаштырылды. Шул чакта бер төркем хезмәткәрләр радиодан күчте: дикторлар Айрат Арсланов, Әминә Сафиуллина, журналистлар Кыям Янгулов, Николай Грачев, Рәшидә Таминдарова һ.б. Театрлардан да берничә кеше килде. Баш режиссер итеп Гали Хөсәенов билгеләнде.

Бу чорда әдәби-драматик тапшыруларның баш мөхәррире Рафаэль Мостафин, татар тапшыруларының өлкән мөхәррире Туфан Миңнуллин иде. Талантлы язучылардан Роберт Миңнуллин, Әнәс Хәсәнов, Әхмәт Рәшитов, Роза Туфитулова, Касыйм Фәсәхов, Абдулла Сәләхетдинов телевидение тапшыруларының сыйфатын күтәрүгә күп көч куйды. Бүгенге талант иясе Ринат Мөхәммәдиев дә хезмәт юлын телевидениенең балалар редакциясендә башлады. Аның белән бергә музыкаль тапшырулар редакциясенә университетны тәмамлап Рәшит Әхмәтов та килде. Алар бирәдә шәхес булараk формалашты, тырышып эшләде.

Республика халкына, бигрәк тә өлкән буынга яхшы таныш Айрат Арсланов Татарстанның радио һәм телевидениесендә озак вакытлар диктор булып эшли. Нинди генә тапшыруны бирсәң дә, зур тырышлык куеп, тамашачы канәгать булырлык итеп башкара. Редакторлар әзерләгән текстны берничә кат укып чыга, уңайсыз урыннарын төзәтә, сүз басымнарын билгели. Бу шәхеснең үзенчәлекле башкару стиле, дөньяга карашын билгеләп алып бар иде. Үз вакытында Айрат Арсланов башкаруындагы шактый мелодия язмалары бөтенсоюз фирмасы тарафыннан әзерләнеп бөтен илгә тарала. Элекке СССРның студияләре аларны бүген дә файдалана.

Телевидениедә эшләү чорында Идел буе шәһәрләренең студияләрендә үзебез әзерләгән программаларны еш кына күрсәтеп кайта идек. Безнең һәр визит зур канәгатьлек белән кабул ителде. Тапшырудан соң үткәрелгән йомгаклау вакытында бик күп сорауларга җавап бирергә туры килде.

Казан телевидение студиясендә мин 25 елдан артык эшләдем. Башта «Соңгы хәбәрләр» редакциясенең өлкән редакторы, аннары 20 ел чамасы иҗтимагый-сәяси тапшыруларның баш мөхәррире булдым. Әле партком секретаре булып та хезмәт куйдым. Телевидениенең тапшырулар вакыты редакторлар арасында алдан ук бүлеп куела иде. Һәркем шул билгеләнгән норманы төгәл үтәргә тиеш. Хәтеремдә, берзаман әдәбият-сәнгать редакциясенең өлкән редакторы Туфан Миңнуллинга билгеләнгән вакыт җитми башлады. Директор белән киңәшкәч, аена өстәмә 30 минут таптык. Бик канәгать булган иде.

Дөрес, эшнең җитәрлек булмавына зарланучылар сирәк очрады. Чөнки тапшыруларны әзерләү өчен еш кына бөтен республиканы айкап чыгарга, кирәкле күренешләрне кино тасмасына төшерергә, аннары монтаж ясарга кирәк. Барысы да әзер булгач, әле берничә тапкыр репетиция үткәрәсең. Халык канәгать калсын дип, районнар турындагы тапшыруларны чиратбуенча тигез дәрәҗәдә күрсәтергә тырыштык.

Шулай күнегелгән инде, бүген дә телевидение тапшыруларын игътибардан калдырмыйм, һәр көнне «Татарстан хәбәрләре» тапшыруларын карап барам. Авторларның табышларына балалар кебек шатланам. Тапшыруларга чүп-чар тутырсалар, сәгатьләр буе тынычлана алмыйм. Әйтергә кирәк, Казан телевидениесе тапшыруларының тематикасы канәгатьләндереп бетерми. Аларның кайберләрендә атналар буе бер үк әйберләр турында сөйләнелә. Президент кайда булган, бүген ничә кеше вирус йоктырган, ничә кеше үлгән? Көн саен урам себерү, кар көрәү, янгыннар, аварияләр, балаларын ташлап китүчеләр турында мәгълүматлар бирелә. Эре-эре заводлардан, оешмалардан ел дәвамында бер генә хәбәр дә бирелмәве сәерсенү уята. Кайбер районнардан материаллар бөтенләй юк. Ә бит һәр тапшыруны нәтиҗәләрәк файдаланып була. Нинди тармактагы эшне яктырту өчен урын калдыру әлләни авыр түгел. Атна дәвамында тегеяки бу тема буенча күзәтү биреп алу да тамашачы өчен кызыклы. Безнең бу уңайдан айлык планыбыз бар иде. Республика чикләре буйлап оештырылган тапшырулар циклы да уңышлы үтте. Бу тәҗрибәләрне кабатлау бүген дә отышлы булыр иде.

Мәгълүмат тапшыруларда тел чуарлыгы күзгә нык ташлана. Авторлар тарафыннан урыннарда язып алынган чыгышларны бөтенләй аңлап булмый. Алар ярым русча, ярым татарча. Элек андый язмалар ныклап монтажлана яки бөтенләй ташлана иде. Репетицияне җентекләп үткәрмичә тапшыру эфирга чыкмады. Рәшит Шиһапов, Эдмас Үтәгәнов, Клара Газизова, Флера Бикмурзина, Иван Прошкурантов, Миләүшә Миношина кебек режиссерлар 2-3 минутлык чыгыш ясаучы белән дә сәгатьләр буе репетицияләр үткәрде. Бүген исә телевидениедә эшләүче хезмәткәрләрнең тел кытыршылыклары, басымнарны тиешле урынга куймавы сизелә. Һава торышына күзәтү ясаучы ханымнарның берсе еллар буе «һ» авазын әйтә алмый азапланды. Ярый әле, күптән түгел аны бер егет белән алмаштырдылар. Аның чибәрлеге дә бар, русча да, татарча да дикциясе дә әйбәт.

Тапшырулар өчен билгеләнгән вакыт, аларда катнашучылар саны турында да уйланырга иде. Әйтик, 30 минутлык «Таяну ноктасы» тапшыруына алты кеше чакыру үзен акламый. Аларга фикерләрен әйтү өчен вакыт җитми. Ә менә «Ком сәгате» һәм «Әй, язмыш, язмыш» тапшырулары өчен билгеләнгән берәр сәгать вакыт кайчак күбрәк. Җитмәсә, кайбер чыгыш ясаучыларның фикерләре бик сыек була.

Бүгенге телевидение тапшыруларында теләсә кемнең чыгып җырлап-биеп йөрүе, аларның күбесенең моның өчен бернинди сәләте дә, әзерлеге дә булмавы турында шактый языла. Бу хакта гади телевизор караучыларның гына түгел, профессиональ артистларның да чыгышлары ишетәбез. Элек эфирга чыгачак һәр башкаручы, янгыраячак җыр телевидение-радио комитетының художество советы аша үтте. Шунлыктан ул чорда бүгенге кебек экранга чыгып сикергәләп йөрүчеләр булмады. Бүген исә әз-мәз акчасы булган кеше, үзе белән бер төркем кешеләр җыеп, телевидениегә йөгерә. Алар эссе көннәрдә җыелган черкиләр кебек шушы җырлаучы тирәсендә бөтерелә. Чын профессионал бервакытта да җырлаганда сикергәләп йөрми, бөтерелеп йөрү өчен төркем дә туплап килми. Сәләтең юк икән, кеше күлдерергә ярамый. Чама хисе дигән нәрсә дә бар бит. Шуңа күрә, үткән гасырда уңышлы эшләгән художество советын кабат торгызырга кирәк. Ул чагында эфир чүп-чардан шактый чистара төшәчәк.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Күренекле әдип юбилее

Үткән дүшәмбедә Казанның К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәсендә күренекле замандашыбыз, олы әдип һәм галим, байтак ил зыялыларына мәгълүм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Төркия, Көньяк Америка һәм тагын күп кенә илләрнең әдәби премияләр лауреаты Ринат Мөхәммәдиевнең 75 яшьлегенә багышланган иҗат кичәсе булып узды. Ничәмә-ничә еллар буе Сабантуй мәйданыннан башлап Советлар Союзының барча мөнбәрләренда «ат» уйнаткан, исеме һәм әсәрләре дистәләгән ил укучыларына мәгълүм әдипнең соңгы 25 ел гомере Мәскәү каласында үтә иде, халык аны нык сагынган, күрсәсең, ул тамаша залын тутырып җыйналды.

Р.Мөхәммәдиев – 70 кә якын китап авторы, аның әсәрләрен үзебезнең Татарстанга караганда Төркия, Азәрбайҗан, Урта Азия, Европа, Америка илләрендә, хәтта Кытайда да күбрәк һәм тирәнрәк беләләрдер, ахры. Уен түгел, аннан башка бер генә татар әдибенең дә Кытай университетларының ике мең студент сыешлы залларында яки Төркиянең 30 дан артык каласында иҗат бәйрәмнәре уздыру кебек бәхеткә ирешкәне юк. Мондый киң колачлы әдипнең юбилей бәйрәмен уздыру шактый четерекле булырдай тоелган иде дә, ул озак еллар буе онытылмаслык дәрәҗәдә узды.

Прозаикларның әсәрләрен сәхнәләштерү аның иҗатын күзалларга ярдәм итә. Бу кичәдә дә, сценарий авторы Хәбир Ибраһимов зәвыгы буенча, күрсәсең, Р.Мөхәммәдиевның «Сират күпере», «Кенәри – читлек кошы», «Тәмле прәнник» әсәрләреннән аерым эпизодлар, газиз Ана, татар гармуны, туган як кадере турында әдип язган җан тетрәткеч өзекләр сайлап алынган. Әдип рухын Тинчурин театры артистлары халык күңеленә житкерә белде. Шуңадыр, мондый данлы әдип кичәсен тамаша дип түгел, рухи дәрес, җан авазы дип атарга да була.

Әлбәттә, күнегелгән гадәт буенча, кичә барышында юбилей хуҗасына тиешле котлау сүзләре һәм тәбрикләүләр дә байтак яңгырады. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р.Зәйдулла, Мамадыш районындагы якташлары исеменнән килгән хакимият вәкиле С.Спиридинов, әдип иҗатына беркадәр күз йөгерткән филология фәннәре докторы Ә.Закирҗанов тамашачыларга байтак мәгълүматлар, ә без аларны тыңлап туя алмаган җырчыларыбыз Г.Ибушев, Р.Низамов, Р.Насыйбуллин һәм каләмдәшебез Х.Ибраһимов күңелләрдә ут кабызырдай моңнар бүләк итте, ирле-хатынлы Гөлчәчәк һәм Ирек Хафизовлар әдип әсәрләреннән өзекләр укыды. Тамашачыларга рәхмәт сүзләре җиткерү өчен сәхнәгә менгәч, заманында Татарстан һәм Россия парламентларының депутаты булган Р.Мөхәммәдиевның 1993 елда сәрхүш Ельцин өеренең Югары Советны тупка тотып таратуы турындагы хакыйкатьне искә төшерүе дә артык булмады, безгә нинди даирә кубызына биеп һәм мәгыйшәттә хөкем сөрүебезне аңлап яшәү кыйммәт.

Язучы бәйрәме

Декабрь башында Чаллы каласында татар әдәбияты көне булып узды. Казаннан гына да автомобильчеләр каласына 15 кә якын шагыйрь һәм язучы рәхим иткән иде. Аларны килгән җәһәттән үк шәһәрдә татар теле һәм әдәбияты укытуга йөз тоткан гимназия һәм мәктәпләргә алып киттеләр. Аларда очрашу һәм түгәрәк өстәл янында бәхәс куерткаsuccеннан соң Чаллының татар драма театры бинасына тупладылар. Биредә болай да байтак халык җыелган, ә сәбәбе бер – әдибә Айгөл Әхмәтгалиеваның 50 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтү иде.

Кунаклар әүвәл театр залында Айгөлнең «Капка» хикәясе буенча куелган спектакльне мөнәзара кылды. Аннары сәхнәгә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла күтәрелде һәм, юбиленнан тыш, Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов фәрманы буенча, әдибәне «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелү шатлыгы белән котлады. Шәһәр башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рамил Хәлимов та Айгөлгә барча укытучылар, тәрбиячеләр, китапханәче һәм мәдәният хезмәткәрләре исеменнән котлау ирештерде. Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Ф.Сафин, «Чаллы икмәге» җәмгыятенең генераль директоры Р.Юнысов та әдибәгә яңгырдай явып торган иҗат уңышлары гына теләде. Айгөлнең якташлары – актанышлылар да мондый иҗат бәйрәмнәрен туган төбәктә көтеп яшәүләрен белдерде. Аннары инде сәхнәгә әүвәл Казаннан килгән әдипләр, аннары Камал һәм Тинчурин исемнәрендәге, алардан тыш Әлмәт белән Оренбург калаларындагы драма театрлары вәкилләре тезелешеп чыкты. Коры котлаулар гына ардырыр иде дә, А.Карачурина һәм «Казан егетләре» чыгышы кичәгә ямь бирде.

1 нче биттә – Әгерҗе районы Мукшур авылында каз өмәсе.

«Иҗатында – Минзәлә холкы»

Минзәлә ягы шагыйрьләрен данлап, олылап яши. Бер ай элек Тулбай авылында Салисә Гәрәева хөрмәтенә монумент ачылып, аның 85 яшьлек юбилее уңаеннан кичә узган иде. Декабрьдә минзәләлеләр янә бер күренекле якташлары – Гөлшат Зәйнашевага багышланган ямьле чара үткәрде.

Г.Зәйнашева 1928 елда Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында игенче гаиләсендә туа. Илдә барган мәхшәр бу гаиләне дә урап узмый, кулак ярлыгы тагылып, алар да туган җирдән сөрелә. Ата-ана ике генә яшьлек сабыйны билгесез олы юлга үзләре белән алырга җөрьәт итми. Йөрәкләреннән өзеп, баланы күрше Минзәлә районының Югары Тәкермән авылындагы туганнарында калдыралар. Ачлы-туклы балачак һәм үсмерлек елларын кичеп, кагылулар-сугылуларга бирешмичә, илдә шагыйрә булып танылачак, «Туган җирем – Татарстан», «Китмә, сандугач», «Менәргә иде Урал тауларына», «Күл буена килсәң иде», «Кояш гомере», «Аерылмагыз», «Туган авылым урамы» һ.б. җырлары телдән-телгә, чордан-чорга күчеп яшәячәк ятимә кызның балачагы шушы авылда уза. Тәкермән аны үз итә, бүген дә онытмый, онытырмый.

Авыл җирлеге башлыгы Алия Шәрипова – Минзәлә төбәгендә Г.Зәйнашева исемендәге фестивальне оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе. Гөлшат апаның кияве Рафаэль Шакирҗанов та фестивальне үткәрүгә матди ярдәм күрсәтеп килә. Балалар һәм өлкәннәр арасында нәфис сүз һәм җыр буенча Тәкермән авылы мәдәният йортында районкүләм үткәрелгән конкурс тора-бара республика-күләм мәдәни чараларның берсенә әйләнеп, быел унынчы мәртәбә, киң колачлы итеп уздырылды.

Фестивальне йомгаклау тантанасы «Кояш гомере телим мин, Минзәләм, сиңа!» дип музыкаль кичә рәвешендә С.Өметбаев исемендәге Минзәлә драма театры бинасында үтте. Гала-концертта республиканың Актаныш, Мөслим, Сарман, Саба, Тукай, Мамадыш, Минзәлә районнарыннан нәфис сүз осталары, җырчылар катнашты. Ясле-бакчаларда тәрбияләнүче малай-кызларның минзәләчә итеп Гөлшат апаларының шигырьләрен сөйләүләре, аның сүзләренә язылган җырларны башкаруы тамашачы күңеленә хуш килде.

Минзәлә районы башлыгы Айдар Сәлахов үз чыгышында: «Ун ел элек Югары Тәкермәндә кечкенә генә чарадан башланган әлеге фестиваль киңәеп, бүген республика дәрәҗәсенә күтәрелүе – шатлыклы вакыйга. Бигрәк тә балаларның катнашуы, матур итеп чыгыш ясаулары куанычлы. Минзәлә районыннан чыккан танылган якташ язучыларыбыз күп. Алга таба аларның иҗатына да игътибарны арттыру төп максатыбыз булыр», дигән куанычлы сүзләр әйтте.

Танылган җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова, Асаф Вәлиев, Гөлнара Тимерҗанова чыгышлары, Г.Зәйнашева турында истәлекләре да кичәгә ямь өстәде. Кичәдә Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, язучылар Әлфия Ситдыйкова һәм Лилия Гыйбадуллина да чыгыш ясады, үз шигырьләрен укыды.

Гөлшат апа әдәбиятка сәхнә әсәрләре, кыска пьесалар белән аяк баскан. «Безнең Минзәлә театрында Гөлшат Зәйнашеваның «Бәхет кошым» (1964), «Кем гүзәл?» (1970), «Комиссия килгәч» (1976), «Яшел сумка» (1982), «Язмышлар һәм ялгышлар» (2000) спектакльләре куела. Без моның белән бик горурланабыз» – дип билгеләп узды театр директоры Илнур Гайниев. Быел киң колач белән үткән фестивальнең төп оештыручысы, башка төбәкләрдән килгән катнашучыларны кунакчыл кабул итеп, гала-концертны әзерләүче һәм уздыручы – Минзәлә театры булды. Чарада катнашкан һәр иҗат коллективына ТР Мәдәният министры И.Әюпованың рәхмәт хаты тапшырылды.

Лилия ФАИСОВА.

Халыкны әдипләре ныгыта

Әлеге чараларның бер-бер артлы оештырылуы һич тә очраклы түгелдер. Әүвәл КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында мәшһүр әдибебез Аяз Гыйләҗев һәм мажар (венгр) язучысы Арпад Галгоцины тууларына 95 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе, икенче көнне башкалабызның «Туган авылым» комплесында шагыйрь Разил Вәлиевнең кырыгы үткәрелде.

Яшь аермалары ике дистә ел булган Аяз ага белән Разил абыйны нинди җепләр бәйли? Р.Вәлиев 1968 елның көзендә, Мәскәүдәге Әдәбият институтында укыганда Аяз абый белән очраша. Өлкән әдип яшь шагыйрьгә, поэзия белән генә чикләнмичә, проза әсәрләре дә язып карарга тәкъдим итә. Шагыйрь, яхшатланып, минем бер повестем бар инде, дип ычкындыра. Югыйсә, ул чакта «Эт кояшы»ның күңелдә бөреләнеп йөргән генә вакыты. «Алып кил», – ди остаз. Бер атнадан кулыгызга тапшырырмын, дип вәгъдә итә студент. Аяз ага повестька яхшы бәя бирә, фатиха була бу. Әмма Казандагы нәшриятта, җәмгыятебезгә кара ягу бу, дип әсәрне кире боралар. Повесть 22 елдан соң, 1990 елда гына ташка басыла...

Венадан хат-хәбәр

Р.Вәлиев остазын гомер буе онытмый. Менә шушы җылы мөнәсәбәтләрнең бер мисалы:

«Сәлам, Фатих туган! Мин әле һаман Австриядә хастаханәдә ятам. Монда медицина югары дәрәҗәдә, әйбәт дәвалыйлар. Әмма авыруым көчле булып чыкты, бирешәсе килми, бераз алга китеш бар сыман. Монда килгәндә гел ятып кына тора идем, хәзер аякка басып хастаханә бакчасына чыга башладым. Тагын да әйбәтләнүен көтеп, өмет белән яшим. «Җыен» фонды сериясендә «Аяз Гыйләҗев» китабы әзерлибез. Төзүчесе – М.Хәбетдинова, мөхәррире – мин. Миңа кулъязманың электрон вариантын җибәрделәр. Хәзер шуны укыйм».

Р.Вәлиевнең вафатына өч ай чамасы кала, 2023 елның 3 августында тәрҗемәче төрек кардәшебез Фатих Кутлуга ватсап аша юллаган хәбәре бу. Ә Фатихны әлеге ике шәхесне тоташтыручы күпер, дип әйтергә була. Фатих бәй бүген дә – Разил абый белән Аяз ага гаиләсендә көтеп алынган кунак. Ул Разил абыйның соңгы көннәрендә өйләренә килеп, Коръән укып, хәлен җиңеләйтергә тырышты. Соңгы сулышын биргәндә, аңа ясин чыкты...

Фидакарь тәрҗемәче

Ф.Кутлуны Аяз Гыйләҗевны Төркиягә ирештерүче, дияргә дә була. Хәзерге вакытта Төркиядә күренекле әдипнең дүрт иҗат җимеше – «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Яра», «Язгы кәрваннар» әсәрләре төрек телендә дөнья күргән икән, болар бөтенесе – Фатих тырышлыгы. «Әдипнең тууына 95 ел тулу уңаеннан быел Төркиядә «Берәү» повесте чыгарга тиеш иде. Икътисади кыенлыклар аркасында, бу эш киләсе елга кичектерелде. Ташка басылып чыгуны көтеп ята торган әле тагын бер әсәре – «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» бастыруга әзер, бүген үк нәшриятка бирерлек. «Йәгез, бер дога» романының аз гына эше калды. Татарстан Язучылар берлегенең Тәрҗемә үзәге эшчәнлеге кысаларында «Берәү» повестен төрекчәгә күчереп бетердем. Аяз абыйның иҗатын төрек халкы бик җылы кабул итте», – дип сөйли үзе Ф.Кутлу. Биредә Фатих дустыбызның 2020 елда Истанбулда нәшер ителә торган «Тәмрин» журналының апрель санын тулысынча Аяз Гыйләҗев иҗатына багышлап чыгартуларына ирешүен әйтеп китү дә урынлы.

Татар-мажар дуслыгы

Әдипнең «Йәгез, бер дога» романының мажар телендә басылып чыгуы – гыйбрәтле тарих. А.Гыйләҗев иҗатын җентекләп өйрәнүче, филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты Миләүшә Хәбетдинова – тагын бер фидакарь затыбыз очраклы рәвештә илленче елларда ГУЛАГ тоткыны булган Аяз аганың 1954 елда бергәләп төрмә шулпасы чөмергән дустын – Арпад Галгоцины таба. Нәтиҗәдә Арпад әфәнде өч мәртәбә Казанга килеп китә, Аяз аганың гаиләсе, иҗаты белән таныша, шулай михнәттәше белән күрешкәндәй була. Әлбәттә, аны иң дулкынландырганы – бергә күргән михнәтләрне, лагерь сәхифәләрен яктырткан «Йәгез, бер дога» романы. А.Галгоци романны тәрҗемә итүгә бишкуллап алына. Ходайның рәхмәте, тәрҗемәчебез Наил Ишмөхәммәтов аны байтак вакыт элек урысчага тәрҗемә иткән икән. Әле һаман ташка басыла алмыйча, нәшриятта үз чиратын көтеп яткан әсәр озакка сузмыйча урысчадан мажарчага күчерелә. Әле Будапешта урысчасыннан берничә ай алданрак та дөнья күрә.

Һәр әдәби әсәрнең үз язмышы. Сталин оештырган тоталитар режимны фаш иткән әлеге роман бүген дә кешелек җәмгыятенә кисәтү булып яңгырый. Шуңа күрә аны, татар, урыс, төрек, мажар телләрендә генә түгел, инглиз, Европа илләре телләренә дә тәрҗемә итеп танытасы иде. Бу бит татар әдәбиятын дөньяга таныту да. Ике әдипнең иҗатына, тормыш юлына багышланган әлеге чараны алып баручы һәм төп оештыручыларның берсе булган Миләүшә ханым менә шуларны бәян итте. Галимә ханым: «Әлеге ике әдипнең лагерьда чыныккан чын ир-ат дуслыгы татар-мажар халкы дуслыгының бер мисалы ул», – дип халыкара элемтәләрне киләчәктә тагын да киңәйтергә чакырды. Ул тәрҗемәче Ф.Кутлуның тырышлыкларына, Аяз аганың атаклы әсәрләрен Төркиядә бастырып чыгаруына ирешүенә аеруча зур бәя бирде (әлеге кичәне оештыруга зур көч салган институт директоры Рәдиф Җамалетдинов белән Миләүшә ханымның хәләл җефете, тарих фәннәре докторы Айдар Хәбетдиновны телгә алу да кирәк).

Татар әдәбиятын чит телләргә тәрҗемә итүне телгә алганда «Өч аршын җир» әсәренең күптән түгел генә Канадада, «Амазон» нәшриятында нәшер ителүен тәкърарлап китү зарур. Әлеге нәшрият китаплары аның инглиз филиалларында, 13 илдәге интернет-кибетләрендә бастырып таратыла.

Замандашлары, күргән-белгәннәр якты дөньядан китеп, әдип бераз онытылса да, әсәрләрен укып, нәшер итеп торалар икән, аның исеме, язган әсәрләренең каһарманнары, әсәрдәге тирән фикерләре, тел байлыгын тәшкил итүче табыш-бизәкләре барыбер халык күңелендә саклана, киләчәккә бара. Аяз Гыйләҗев, Арпад Галгоци, Разил Вәлиев кебек әдипләребез менә шундый бәхетле язмышка ия шәхесләрдер.

Рәшит МИНҺАҖ.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ – тәрбия коралы

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

«Яңа гасыр» каналы буенча бирелә торган рекламаларны әзерләү, аларны эфирга чыгару системасын да тәртипкә саласы бар. Элек телевидениедә реклама өчен программада махсус урыннар билгеләнде. Соңгы вакытларда кайбер әйберләрне чик-чаманы белмичә мактаган рекламалар күбәйде. Татар каналы буенча күрсәтелә торган рекламалар бәйләнчек стильдә эшләнгән. Аларны карагач, реклама авторларының телевизор караучыларны уйларга сәләтсез, ахмак дип санавына гаҗәпләнәсең.

Бу тармакка озак хезмәт куйган шәхес буларак кабатлыйм: телевидение тапшыруларын әзерләү гаять катлаулы, авыр, җаваплы хезмәт. Әмма тапшыруларның структурасын төрләндерү, сыйфатын яхшырту турында да кайгыртырга кирәк. Билгеле, мәдәниятнең, пропаганданың күпчелек тармакларындагы кебек үк телевидениедә дә чын профессионаллар бик аз. Аларны эзләү, табу, әзерләү – җитәкчеләр бурычы. Моның өчен төрле һөнәр ияләреннән торган махсус совет оештырганда да начар булмас иде. Телевидениенең һәр тармагындагы җаваплы хезмәткәрләрнең бурычын билгеләү дә зарур. Кайбер хезмәткәрләрнең вазыйфаларын киметә төшкәндә дә файдалы булыр. Киләчәктә телевидение тапшыруларының кызыклырак, мавыктыргычрак булуына өметләник.

Бүген дә телевидениедә Данил Гыйниятов, Илдар Сафиуллин, Фәнис Камал, Рәвеф Шакиров, Фәридә Габитова кебек сәләтле хезмәткәрләр бар. Аларның санын арттыра төшкәндә бик яхшы булачак.

● Россиядә картлык буенча уртача пенсия аена 19 322 сум (197 евро чамасы) тәшкил итә, Германиядә исә карт-карчыклар моннан 8 тапкырга диярлек артыграк – 1544 евро (152 мең сум чамасы) пенсия ала.

● 2023 елда Россия халкы эзотерика һәм астрологияне өйрәтү курсларына 1 миллиард сум акча тоткан. Яңа һөнәрләр үзләштерергә дип онлайн сатып алынган курсларга исә барлыгы 2,5 миллиард сумнан артыграк акча сарыф ителгән: биредә иң популяр юнәлешләр – нутрициология һәм коучинг (берсе – ашарга, икенчесе – яшәргә өйрәтә), шулай ук психология.

● Татарстанда затлы-зиннәтле машиналар саны шактый кимегән. Хәзер республикада бәясе 10 миллион сумнан артыграк булган 215 автомобиль бар икән. Быел 1,2 миллион татарстанлыдан барлыгы 5 миллиард сум транспорт салымы җыелырга тиеш.

Әйдә халыкка хезмәткә, балда-майда йөзмәккә!..

Хакимнәрнең нәрсә белән сыйлануы халыкны һәрвакыт кызыксындыра. Әмма алар, яраннарын көнләштермәс өчен, бу турыда беркайчан да чын дөресен сөйләп бетерми. Серлелек исә гайбәт һәм имеш-мимеш тудыра. Кремль даирәләрендә серлелек күбрәк булган саен, «өстәгеләр»нең тормышы хакында уйдырмаларны да халык күбрәк тарата бара. Хәзер исә күп кенә кызыклы фактлар яшерен булудан туктады. Кремль әһле ни белән тукланган соң? Дәүләткә бу күпмегә төшкән? Бүгенге җитәкчеләребез нинди ризыкны үз итә?

Коймак корсак

Ленин бер дә аскет булмаган. Володя Ульянов балачактан ук тәмле һәм туклыклы ашарга күнеккән. Петербургка укырга киткәч, әнисенең бәлешләрен сагынган. Шунлыктан яңа танышы Надеңька Крупская өенә һәр якшәмбе кунакка йөргән, аның әнисе пешергән коймак, бәлеш, бөккәннәр белән сыйланган. Шушенское сөргенендә инде ирле-хатынлы Ульянов-Ленин һәм Крупская табынында яңа савылган сөт, сөләйман балыгы, киек кош, яшелчә, гөмбә, җиләк, бал өзелмәгән. Империя биргән 8 сумлык пособиегә киләчәктә аны җимерәчәк Ульянов рәхәтләнеп яшәгән: бер атнада Владимир Ильич өчен сарык суйганнар, икенчесендә сыер ите китергәннәр. Сөт, эремчек, шәңгәне теләсәң күпме ашап булган. Социал-демократлар башлыгының сөргендәге тормышы җәза үтәүне түгел, шифаханәдә ял итүне хәтерләткән.

Грузин кухнясы

Большевиклар Октябрь революциясеннән соң да тук тормыштан баш тартмаган. Инде 1920 елда ук Халык комиссарлары советы «үтә җаваплы һәм алыштыргысыз хезмәткәрләр» өчен айлык паек билгеләгән. В.Ленин ай саен 3,2 килограмм шикәр һәм 1,6 килограмм атланмай алып торган – бик теләсәң дә, ачтан үләрлек түгел. Реввоенсовет рәисе Лев Троцкий Гражданнар сугышы фронтлары буйлап махсус поездда йөргән, составка ит, балык, яшелчәне саклар өчен рефрижиратор тагылган. Халык аскет дип ышанган Феликс Дзержинскийның атналык менюсы мондыйрак булган: дүшәмбе – киек коштан консоме, кыздырылган сөләйман балыгы, полякларча чәчәк кәбестә; сишәмбе – гөмбәле солянка, бозау итеннән кәтлит, шпинатлы йомырка тәбәсе; чәршәмбе – әспедән измә-аш, сыер ите, брюссель кәбестәсе; пәнҗешәмбе – боярлар шулпасы, парда пешкән чөгә балыгы, яшел борчак; җомга – чәчәк кәбестә боламыгы, мәрсин балыгы, ногыт борчагы; шимбә – чөгә шулпасы, алма-чия-слива тутырып кыздырылган күркә, каймаклы гөмбә; якшәмбе – шампиньонлы аш, Маренго чебеше, әспе.

Ил өчен иң авыр чакларда да Кремльдә мәҗлесләр тынып тормаган. Большевик Лев Каменевның килене 1930 елда Кремль ашханәсеннән ризык ташуны болай дип искә ала: «Ризык ике кешегә генә исәпләнеп бирелсә дә, тугыз кеше иркенләп туенырлык була иде. Ай саен 500 сум биреп барасың да, көн саен барып ашыйсың. Кеше саен яртышар кило атланмай һәм кара уылдык та бирәләр. Коры паек алсаң да була – тәм-том, исерткечләр, галәмәт зур балыклар, бик яхшы сыйфатлы итләр һ.б.»

1941 елның октябрендә, немец гаскәрләре Мәскәү янында ук торганда, Польша дипломаты В.Прушинский Кремльдәге кабул итүне сурәтләп калдырган: «Табын искиткеч зәвык белән бизәлгән. Голландиядән кайтартылган эскәтер җәелгән өстәлләргә император фарфор заводында

ясалган затлы сервиз куелган. Һәр кунакның каршында – кабымлык тулы аерым тәлинкә һәм берничә төрле исерткечле шешә. Уылдыкны ике тапкыр чыгардылар. Аштан соң төрледән-төрле ит, киек кош, балык ризыклары бирелде».

Иосиф Сталин дачасында үткәрелгән мәҗлесләр турында исә әллә никадәр китап язылган. Төн уртасында башланып таңга кадәр дәвам иткән әлеге мәҗлесләрдә генералиссимус искиткеч күп ашаган. Ул грузин ашлары һәм шәрабларын яраткан, итле ризыкларга өстенлек биргән. Даими рәвештә шулай сыйланган җитәкчеләр көндез бик аз гына капкалаган, күбесе атнасына бер көнне җиләк-җимеш ашап, сок эчеп кенә үткәргән. Шулай итеп, партия юлбашчылары һәрвакыт коммунизмда яшәгән, халыкка исә аны ерак киләчәктә генә ышандырган.

Үзе кукуруз ашамаган

Хакимияткә Никита Хрущев килгәч, илдә җитди үзгәрешләр башланган. Әмма затлы табыннар бер дә үзгәрмәгән, киресенчә, тантаналар тагын да күбәйгән. Зур уңыш җыюны да, шахтерлар рекордларын да, космоска очуларны да, дус илләр җитәкчеләре килүне дә билгеләп үткәннәр. Хрущев заманында андый тантаналы мәҗлесләр атнасына ике тапкырдан да кимрәк уздырылмаган. Халыкны витаминга бай кукуруз белән сыйланырга өндәсәләр дә, җитәкчеләрнең үз табыны түшкә-түшкә дуңгыз итеннән, томалап пешерелгән 15-20 килолы мәрсин балыгыннан сыгылып торган. Кремльдә үткәрелгән банкетлардан соң официантлар үзләренә балык, шәраб, коньяк тутырып киткән, әле һәркайсына 100 әр сум акча да бирелгән.

Торгынлык чоры

Леонид Брежнев заманында затлы мәҗлесләр кими төшкән. Ул Көнбатыш гадәтләрен керткән: кунакларын бутерброд-канапе ише кабымлыклар белән сыйлаган. Ә инде бәйрәмнәрдә кара һәм кызыл уылдык, затлы балык, түшкә-түшкә ит, диңгез деликатеслары, экзотик җиләк-җимешләрдән күз явын алырлык табыннар әзерләнгән. Ябык ашханәдә бик яхшы сыйфатлы ризыклар Политбюро әгъзаларына арзан бәядән сатылган. Элита өчен прейскурант 50 биттән торган, анда 94 исемдәге кондитер эшләнмәсе, 320 төрдәге диетик продукт, 72 төрле балык һәм уылдык, 65 төрле казылык, сыр, май тәкъдим ителгән, боларның берсен дә Советлар Берлегенең бер генә кибетеннән дә, бер генә базарыннан да табып булмаган. Политбюро әгъзаларына ай саен 400 сумлык, кандидатларга – 300 сумлык бушлай ризык бирелгән. Кремль ашханәсендә 60 тиенгә менә дигән итеп сыйланып булган.

Тыйнак һәм зәвыклы

Михаил Горбачев вакытында кабул итүләр башта бик кырысланган – бөтен илдәге кебек, Кремльдә дә әчкечелеккә каршы көрәш җәелдерелгән. Халык талонга яшәгәндә, юлбашчыларның бик сикеренергә намусы кушмаган. Әмма әкренләп барысы да иске эзенә төшкән. Минераль суны кабат спиртлы эчемлекләр алыштырган, уылдык, балык, ит, казылыкның сыйфаты яхшырганнан-яхшырган. Һәрхәлдә, Кремльдә беркайчан да «Завтрак туриста» консервасы бирелмәгән инде...

Путин – туңдырма, Медведев – бал ярата

Безнең көннәрдә дә Кремль табыны әллә ни үзгәреш кичерми. Банкет менюсын берничә атна алдан 20 ашчыдан торган комитет раслый. Ашамлыклар лабораториядә махсус тикшерү үтә, табынга куелганчы, һәр ризыкны Президент ышанычлылары кабып карый. Һәр банкетка яртышар тонна ит һәм балык, 5 мең данә йомырка сатып алына. Һәр ашамлык сәнгать җәүһәредәй бизәлә, кабатланмасын өчен, фотога төшерелә. Бәйрәм алдыннан ашханәдә 35-40 пешекче хезмәт куя. Кунакларны нарат җиләкле болан ите, аракы соусындагы бәрәңге коймагы, диңгез кысласы белән чәчәк кәбестәдән мусс, эрбет чикләвеге тутырып пешерелгән кыр тавыгы белән сыйлыйлар. Десертка урман җиләкләре белән ибизәлгән алмалы торт һәм җиләк-җимешле желе бирелә.

Интернет материалларыннан
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Мәдәни җомга
15 декабрь
№49, 2023

Һ. Такташ, Г. Кутуй һәм ике Галия

Бу көннәрдә әдәбиятыбызның биек мөнбәрендә үзенең лаеклы урынын алган һәм шунда мәңге калачак сүз рәссамы Гадел Кутуйны 120 еллыгы уңае белән хөрмәтләп искә алабыз. Язучының исемен атадыңмы, аңда аның әсәрләре, алардагы сүзләр яңара. «Җиңү мине Берлинга алып бара. Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә җиңүче булып йөрим. Берлинга мин, илем белән аерылу кайгысын һичкайчан татымас өчен чиксез ачу белән барам».

Җиңүче сугышчының күңелендәге уй-хисләрен никадәр тирән кичереп әйтелгән сүзләр! Шулай булмый хәле юк, бу хәлләрне читтән күзәтеп кенә торучы түгел, бәлки көне-төне, айлар-еллар буе шул ут эчендә йөрүче шагыйранә күңелле солдат яза. Чын хисләрнең башкаларда да шундый ук көч белән кабул ителүе гаҗәпмени? Туган телебезнең матурлыгын күңел түрләренә кертеп урнаштыруда «Сагыну» нәсеренең дә әһәмияте гаҗәеп зур булды. Г.Кутуй турында сүз барганда, «сагыну» сүзе үзеннән-үзе телгә килә. Чыннан да, «яратам», «сагынам» дигән сүзләр бар икән, ул тел инде матур, аһәңле, камил...

1993 елның декабрь аенда Актерлар йортында Г.Кутуйга 90 ел тулуга багышлап кичә уздырылды. Ул кичәне алып баруны миңа тапшырганнар иде. Язучының үзе белән аралашкан Әмирхан Еники белән Шириязданн Сарымсаков та килде. Хатыны Галимә апа, улы Рөстәм Кутуйлар да биредә. Әлбәттә, без Айрат Арслановны да чакырдык. Чөнки әдипнең «Сагыну» нәсерен аннан да үтемлерәк итеп башкаручыны күз алдына да китереп булмый. Әмма Айрат абый авырый булып чыкты. «Температурам югары, каты йөткерәм», диде ул. Ләкин ни күзем белән күрим, кичәнең уртасындарак сәхнә артына Айрат абый килеп керде.

– Гадел Кутуй кичәсе ничек инде «Сагыну» нәсереннән башка узсын? – диде дә әлеге әсәрне шундый кайнарланып укыды, тыңлаучылар артистның авыру хәлдә икәнлеген сизмәде дә. Димәк, каләм көче сәламәтләндерү хасиятенә дә ия икән.

Шулай да Г.Кутуйның язучы буларак осталыгы аның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда булса кирәк. Әсәрнең үзе генә түгел, аның язылу тарихы да кызыклы һәм гыйбрәтле. Ул аның иҗатташ дусты Һади Такташ белән дә бәйле. Эш шунда, 1929 елда Һ.Такташ «Югалган матурлык» дигән сәхнә әсәре яза. Аны шул ук елда Татар дәүләт театрында сәхнәләштерәләр. Драманы куюга шул заманның күренекле сәхнә көчләре җәлеп ителә. Режиссер Г.Девишев үз тирәсенә Х.Әбҗәлилов, Ш.Шамильский, Р.Кушловская, Камал III, Х.Сәлимҗанов, З.Закиров, Ф.Камалова кебек артисларны туплый. Шуңа күрә сәхнәгә куелышы ягыннан тамаша нинди дә булса сорау тудырмый. Аның тиз арада сәхнәдән төшерелүенең сәбәбе – әсәрнең рәсми идеология ягыннан тиешле таләпләргә туры килмәве, тагын да дөресрәге – капма-каршы фикер чыгаруы иде. Бу – сәнгатьлелек идеология белән тиңләштерелгән ул еллар өчен бөтенләй зарарлы күренеш. Һ.Такташка шактый нык тәнкыйть сүзләре ишетергә туры килә. Автор өчен бу яңалык булмый. Ул алдан ук шулай буласын белеп тора. Без моны аның беренче хатыны Г.Хәмзинага язган хатыннан беләбез. «Мин бер әйбер яздым, тиздән ул халыкка ирешер, аның өчен каты сүзләр булачагын сизәм. Ләкин мин курыкмыйм», дип, алдан ук үзен мондый хәлгә әзерләп куя.

Спектакльнең тиз генә сәхнәдән төшерелүен төрлечә аңлатулар булды. Театр тәнкыйте һәм тарихы өлкәсендә күп хезмәт куйган Б.Гыйззәт мондый хәлне сурәтләнгән гаиләдә фикер бердәмлеге булмауда күрде. Болай дип раслау әсәрдә күтәрелгән төп мәсьәләдән читкә алып китүгә генә хезмәт итә иде. Тәнкыйтьченең хәтта җитмешенче еллар урталарында да күңелендәгесен турыдан-туры әйтеп бирә алмавы сизелеп тора.

Чынлыкта Такташны бу очракта нәрсә борчыган? Ул пьесаның беренче пәрдәсен «Богемалар» дип атый. Димәк, биредә тәртипсез һәм иртәгәге көн турында ишәк кайгырсын, дигән караш белән яшәүчеләр турында сүз бара. Күренә ки, сәхнә күренеше барышында бу нәрсә тулысынча ачыклана. Вакыйгаларда катнашучылар – яшьләр, барысы да (!) фирка әгъзалары. Әмма эшлексезләр, әхлаксызлар, көндез ашарларына булса, кичкесе турында уйларга сәләтсезләр. Үзләреннән аз гына рәтлерәк яшәүче иптәшләренең әйберләрен сатып, тамак туйдыручылар.

Инкыйлаб татар тормышына да бик күп үзгәрешләр алып килде. Аларның яхшылары булган кебек, тискәреләре дә җитәрлек. Изге динебез, гомер-гомергә килгән гореф-гадәтләр инкарь ителде. Ирекле мәхәббәт дигән кыямәт чәчәк атты. Такташ моны «Мәхәббәт тәүбәсе» әсәрендә үк бөтен аянычлыгы белән күрсәтергә омтылды. Ләкин әсәрен «бәхетле финал» белән тәмамларга мәҗбүр булды. Әлбәттә, мондый хәл аны канәгатьләндермәде. «Югалган матурлык»та әлеге теманы яңадан күтәреп чыкты. Чөнки Зөбәйдәләр, Мәхмүтләрнең күбәеп баруына карата ул үзенең тискәре карашын белдерергә тиешлеген яхшы аңлады.

Әсәрдә туй күренешенең шыксызлыгы, бернинди әхлак киртәләренә сыймау сурәтләнү аеруча гыйбрәтле. Бу – Газиз белән Галия туе. Газиз иптәшләренә караганда өлкәнрәк, инде укуын да тәмамлаган, заводта эшли башлаган. Югары уку йортында укучы Галия белән өйләнешергә булганнар. Ләкин бу туй гап-гади эчү мәҗлесенә әйләнеп китә. Үзләре шуны «советча никах», «иптәшлек тормышы» төзү дип атый. Шуның өчен рюмка арты рюмка күтәрәләр. Шул ук мәҗлестә

исерек баштан Солтан белән Зөбәрҗәт дигәннәре дә үзләрен ир белән хатын дип игълан итә. Болар арасында, дөресендә, бер генә юньле-рәтле гаиләле пар да юк. Булуы да мөмкин түгел. Бу Газиз белән Галиягә дә кагыла. Әлеге егет белән кыз арасында идея берлеге бар. Ләкин ул әхлаклылык, гаиләдә ир белән хатынның урыны, вазыйфалары турындагы кыйммәтләр белән ныгытылмаган. Тиешле тәрбия күрсәтелмәгән, иң мөһиме – күкрәк сөте белән тиешенчә тукландырылмаган балалары да үлеп китә. Юк, сөт җитмәүдән түгел, Галиянең, дөньясын онытып, җәмәгать эшләренә йөгереп, баласына игътибар итүне онытуы, гамьсезлеге аркасында. Шул сәбәпле Галия икенче баласын тудырып та тормый, ләкин көмәнен төшертүгә үзен дә кабергә алып китә. Бу әсәрне «Югалган матурлык» дип түгел, тагын да кискенрәк «Югалган гомер» дип тә атап булыр иде. Кабатлап әйтәм, персонажларның барысы да рәсми рәвештә фирка әгъзалары. Сорау туа: йә, шуннан соң театр репертуарында мондый әсәрнең булуы белән рәсми хакимиятләр түзеп тора алалар идеме? Әлбәттә, юк. Такташка аны бастырырга рөхсәт итмиләр. З.Бәширова, Ф.Мөсәгыйть кебек үтә сәяси тәнкыйтьчеләр барында бу мөмкин дә түгел иде. Драма бары тик 1956 елда гына басыла һәм сәхнәгә яңадан күтәрелә алды.

Кутуй турында башланган сүзнең шактый дәвамлы рәвештә Такташка таба борылып китүенә сәер түгел. 1930 елда бездә һәм Башкортстанда «Җидегәнчелек» дигән корткычлык оешмасы булуын «ачтылар». Имеш, аны Г.Кутуй оештырган дип фаразладылар. 1931 елның 7 февралендә шушы оешмада катнашкан дип исәпләнелгән Г.Кутуйны, Н.Исәнбәт, Г.Минский, Т.Ченекәйне кулга алалар. Исәнбәт белән Минский 15 апрельдә, гаепләре расланмады, дип чыгарыла, ә Кутуй белән Ченекәй исә әле 16 сентябрьгә кадәр тоткынлыкта була. Ләкин, азат ителсә дә, Кутуйга әдәбиятка юл ябыла. Аның язганнарын бер генә басмада да кабул итмиләр. Язучылар даирәсендә дә чит итәләр. Хәтта кая да булса укыту эшенә дә алмыйлар.

Алда телгә алынган Актерлар йортында узган кичәдә аның хатыны Галимә апа болай сөйләде:

– Бу вакытта безнең ике балабыз бар иде. Гөлшатка – дүрт, Кирага (Эсягә) бер яшь. Гаделшага эш бирмәделәр. Без минем кечкенә генә хезмәт хакына торырга тиеш булдык. Гаделшаның эшлисе, ничек тә әдәбиятка, актив эшчәнлеккә кайтасы килә иде. Мондый хәл дүрт ел буена сузылды.

Бу урында Кутуйның нинди хәлдә калганлыгын аңлауда Риза ага Ишморат сөйләгәннәр ярдәмгә килә. Дөрес, ул әлеге кичәдә катнашмады. Безнең очрашу элегрәк, 1987 елның 12 декабрендә, аның фатирында булган иде. Ул бәян иткәннәрне көндәлегемә болайрак язып куйганмын.

– Әйе, Гадел үзенең мондый хәленә бик борчылды. Чөнки егерменче елларда әдәбиятта-сәнгатьтә аннан да хәрәкәтчән кеше булмагандыр. Шундый көннәрнең берсендә миңа аның белән аулаграк урында очрашырга туры килде. Хәлләхвәл сорашканнан соң, ул сорап куйды:

– Ничек уйлыйсың, Риза, Һадиның Галиясе ни өчен матурлыгын саклап кала алмады?

– Син бу сорауны юкка гына бирмисең. Җавабын үзең дә беләсең. Һади чынбарлыктагы хәлләргә тугрылыклы булды. Туры әйткән туганына ярамаган. Бары шул гына.

– Әгәр Галия башкачарак сурәтләнсә, аның әсәре яшәр идеме?

– Башкачарак сүзе үзе бик киң төшенчә. Әгәр дә әсәрне сәяси яктан канәгатьләнерлек дип тапкан булсалар, чыннан да, аны кирәксенерләр иде. Ләкин ул вакытта нигезе белән бөтенләй икенче әсәр булыр иде ул.

– Нигезе белән икенче әсәр...

Гадел бу турыдагы сүзне шуның белән өзеп куйды. Аерылышкач, мин уйга калдым. Гадел дустының әсәре турында тирән уйланган. Аның уңышсызлыгының Галия образы белән бәйле икәнлеген тәмам ачыклаган. Бу малай нәрсәдер кыштырдатып ятмыймы?

Шуннан соң биш-алты ай үттеме икән, ягъни 1935 елның җәйге көннәренең берсендә, мин Лядской бакчасыннан үтеп бара идем. Күреп алдым, агачлар арасынарак куелган эскәмиядә Гадел утыра. Ул да мине күрде. Ләкин урыныннан кузгалмады, миңа карый-карый, утыра бирде. Аңладым, кеше күзенә чалынасы килми. Аның янына бармыйча булдыра алмадым.

– Нәкъ менә сине көтеп утыруым иде. Ярты сәгатькә генә миңа кереп чыгыйк әле, вакытың булса, әлбәттә.

Минем театрда сәнгать җитәкчесе булып эшләгән вакытым. Репетицияне башка режиссер да башлый тора ала. Шуңа күрә аңа иярдем.

(Дәвамы 23 нче биттә).

ИГЕЛЕК ИЯСЕ

Кукмара төбәгендә Рәмзия ханымны ишетеп-күреп белмәгән инсанны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый торгандыр. Җөмһүриятебезнең мәдәни даирәсенә дә аның исеме яхшы ук таныш дип беләм. Ул бу мәртәбәгә 37 ел гомерен авыл, район мәдәниятенә багышлап, аңа фидакярләрчә хезмәт итеп һәм үз эшен югары һөнәри дәрәҗәдә башкарып иреште. Ике мәртәбә Бөтенрусия халык иҗаты фестивалендә җиңеп чыккан якташыбызның уңганлыгы-булганлыгы рәсми рәвештә дә танылды: 1992 елда ук аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән шәрәфле исем бирелде.

Якташ димәктән, Рәмзия безнең күрше Чишмәбаш карьясеннән килен булып төшкән авылдашыбыз да, ызаннарыбызны Чал Инеш кенә аерып торган ут күршебез дә әле. Тагын да тәгаенли төшсәк, минем балачак дустым Тәлгатьнең хәләл җефете дә, ягъни мәсәлән. Моннан 50 еллар элгәре үзе укмаштырып ясаган өстәлдә тимер шарлар белән бильярд уйнарга да, шахмат фигураларын йөртергә дә, шашка, домино, кәрт сугарга да мине нәкъ менә шул яшьтием өйрәткән иде. Гомер чиккәндә, кеше-кара белән аралашканда, бу мавыктыргыч уеннарның да гел кирәге чыгып торды. Энекәшеңне адәм рәтле һөнәрләргә генә өйрәткәнең өчен мең рәхмәт сиңа, яшьти!

Кыскасы, Гаяз абзыйның бәрәкәтле нигезе дә, гомер-гомергә мәгърифәтле саналган Зур Сәрдек авылы үзе дә Рәмзия киленнән егылып унды. Гәрчә мотлак сәхнә өчен яратылган күркәм, гүзәл зат булса да, ул беркайчан да җырлап-биеп кенә яшәмәде, киресенчә, үзе бер шигырендә язганча, аңа размерсыз тормыш арбасын авырыксынмыйча, һәрдаим җигелеп тартырга туры килде. Алар ире белән өч олан, бер кыз тәрбияләп үстерде. Оясында ни күрсә, очкаында шул булыр, дигәндәй, ике балалары да сәнгать юлын сайлады: бүген Фаязлары – Әтнә, Зилияләре исә Минзәлә драма театрында сәхнә тота. Ренат белән Илшатлары да, илгә-көнгә файдалы эш башкарып, әти-әнисен куандырып яшиләр.

Безнең якта Рәмзия ханым искиткеч кече күңелле, олы йөрәкле, сабыр, игелекле, мәрхәмәтле итагать иясе буларак та тирән ихтирам казанды. Шулай туры килде: ул иренең яшьли дөньядан кичкән бертуган апасының ике нарасыен да үз канаты астына сыендырды. Бүген Зөфәр белән Фирүзә дә, тормышка ныклап ябышып, матур гына дөнья көтеп ята, шөкер. Тәлгать яшьтинең әнисе Рәйсә апа да, Дилбәр тәтәсе дә олыгайган көннәрендә киленнәренең ихлас тәрбиясендә, кадер-хөрмәтендә яшәп, аңа хәерхаһ булып, хәер-фатихасын биреп, дөньядан үттеләр...

Әйе, Рәмзиябез коеп куйган гармунчы, җырчы, нәфис сүз остасы, оештыручы булу өстенә, тормыш-хәятебезне иплерәк, ямьлерәк, нәзакәтлерәк, кешелеклерәк итәр өчен җан атып яшәүче мөрәүвәтле хуҗабикә дә әле. Ул моны үзенең яшәү рәвеше белән үк раслап тора. Сез аларның җиләк-җимеш, яшелчә бакчасына гына күз салыгыз: анда затлыдан-затлы гөлләр чәчәк атып утырыр, йөзем тәлгәшләре күңелне ымсындырып торыр, җир өстендә, җәйрәп, карбыз, кавын кояшта кызынып ятар... Алар тиздән, бик тиздән өлгереп тә җитәр, ә аңарчы әле Рәмзия ханымның күңеле тулышыр да керсез, ак кәгазь битенә саф, садә шигъри юллар тамчылый башлар:

**Яшел үзәнлектә аунап үткән
Балачакның өлкән юлдашы –
Карт тупыллар чакырып кул изиләр,
Шуннан иде безнең юл башы.**

Ни гаҗәп, безнең бормалы-сырмалы юллар да нәкъ әнә шул карт тупыллар аймагыннан башланып киткән иде ич. Рәмзия Хөсәенова шигырьләрен укыганда, мин ул аймакка кабат кайтып килгәндәй булдым...

Газинур МОРАТ.

ТУГАН ЯК ЧАКЫРУЫ

Туган якта гына исә торган
Йомшак җилләр сыйпар юлларны.
Урап кайтырлар дип көтә нигез
Ерак сәфәр чыккан улларны.

Менә-менә кайтып керер диеп
Хәбәр көтә төп йорт юллардан.
Кайчан кайтсаң, ишекләре ачык,
Атттыт пешкән, чәе кайнаган.

Бакчадагы алма-чияләре
Сыгылып төшкән кебек сагыштан.
Ятим итмә туган нигезеңне,
Узып китеп йөрмә язмыштан.

Ялгызлык ул фарыз гамәл түгел,
Яшәешнең кирәк дәвамы.
Сабыйларның шавын бик юксына
Нигез бакчасының аланы.

Өч йөз алтмыш биш көн торган
гомерне үзенә төйнәп
Кайтмаска дип китеп барды,
хушлашу җырын көйләп.

Аклык-сафлык бөркеп торган
салкыннары бар иде,
Күңел кылларын тибрәткән яшел
язлары килде.

Җәйне, көзне үзенә алып китәм,
хушлашыйк, диде...
Бүген шушы бер ел белән
саубуллашырбыз инде.

Авыл күгенә бизәкләп котлау
язган ак болыт,
Өр-яңасы килә елның ак булып,
матур булып.

Рәмзия ХӨСӘЕНОВА

КӨЗГЕ МОҢ

Табигатьнең иңнәренә салып
Ак болытлы йомшак бәләгән,

Карт тупыллар дәшеп кул изиләр, Шуннан иде безнең юл башы...

ҮКЕНМИМЕН

Үкенмимен бу дөньяга
Килгәнемә һич кенә дә.
Туган якның якынлыгын
Тоеп үстек кечкенәдән.

Табигатьнең олы хисен
Яшермәде дөнья бездән.
Колач җәеп йөзеп киттек
Тормыш дигән зур диңгездән.

Сагынып кайтып керергә
Җанга якын төбәгем бар.
Шушы җирдә бөдрәләнеп
Үскән каен-имәнем бар.

Туган ягым, һәр каеның,
Талың якын күңелемә,
Һич кенә дә үкенмимен
Бу дөньяга килгәнемә.

ҖИРНЕ ТЫҢЛА

Сулаганын тоям кебек кайчак,
Үләненә ятып тын калсам.
Тыны бетеп, буылып сулый Җирем,
Тып-тын калып әгәр тыңласаң.

Иңнәрендә никадәрле авыр
Тимер-бетон йөкләр яталар!
Физик көчләр, химик көчләр Җирне
Үзәгеннән читкә тарталар.

Чишмәсенә салып, читкә түгә,
Агыза Җир моңын-сагышын.
Үләненә ятып тыңлап кара,
Ишетерсең зарлы тавышын.

ЮЛДАГЫ УЙЛАР

Тагын китәм шушы юллар белән,
Баганалар саны һаман бер.
Ерактан ук исәнлекне сорый
Ак челтәрле таныш зур күпер.

Челтәренә карап, әнкәемнең
Бәйләп куйган шәлен хәтерлим.
Җанга якын җирдән ерагаеп,
Ашыгып кына поезд теркелди.

Тирә-яктан туган җирнең яме,
Нуры, төсе, исе бөркелә.
Илсез-җирсез гомер итүләрне
Һич теләмәс идем беркемгә.

Яшел үзәнлектә аунап үткән
Балачакның өлкән юлдашы –
Карт тупыллар дәшеп кул изиләр,
Шуннан иде безнең юл башы.

Әнкәебез кылган юл догасы
Исән-имин йөртә юлларда.
Ирешсен ул дога чакыру булып
Чит җирләрдә йөргән улларга.

Әллә ниләр табар кебек булып
Юк җирләрдән бәхет эзлибез.
Өметләргә төренеп, сабыр гына
Кайтыр улын көтә төп нигез.

СИҢА КАЙТСАМ

Яшьлегемнең матур хатирәсен
Синнән эзлим, туган төбәгем.
Ямьле илләр бик күп, ләкин читтән
Матурлыгың тарта йөрәгем.

Әллә ничә урыйм, сиңа кайтсам,
Сукмакларым, инеш буйларым.
Дусларым да бик сагынып кайта
Таратырга борчу-уйларын.

Әй туган як, тулы тормышымның
Моң шатлыкка иң бай җыры син.
Киткән кеше генә белә микән
Кояшыңның үзгә җылысын.

Киткән чакта, ничә борылып карыйм,
Алып китәр әйбер бар сыман.
Чатта үскән каен кулын изи,
Яшьләй сөйгән газиз яр сыман.

ҖӘННӘТ

Җир өстендә җәннәт әнкәйләрнең
Аяк асларында, дигәннәр.
Җиргә килгән затлар әнкәйләрнең
Мең газабы белән килгәннәр.

Иләһ әмере белән җан өрелеп,
Бу дөньяга аваз салганнар.
Тик бәхетле булган әнкәйләрнең
Догаларын алып калганнар.

* * *

Искән җилләр канатында мәңгегә
кайтмас булып
Тарихка очты иске ел, әйтерсең лә
ак болыт!

Сап-сары көз энҗе сибә җиргә,
Тели-тели изге теләген.

Пәрәвәзле чуак яктысында
Җем-җем итә яңгыр тамчысы.
Ерак офыкларда соңгы тапкыр
Ялтырады яшен камчысы.

Сыгылмалы, утлы миләшләрдән
Гафу сорагандай, тезләнеп,
Пыр туздырып алтын яфракларны,
Җилләр йөри нидер эзләнеп.

Җан тартыла алтын яктылыкка,
Җәйдә калган эзне эзләргә.
Салмаклана кеше күзләрендә,
Олыгая кеше күзләрдә.

КЫШ КҮЛМӘГЕ

Мин яраткан алтын сары төсләр
Кар астында калды, күмелде.
Туен көткән яшь кәләштәй, дөнья
Өр-яңа ак күлмәген киде.

Вакыт җиткән. Кыш юрганын япкан,
Күмелгән шул көзге матурлык.
Үткәннәрне дә каплый ул юрган,
Юллар юк шул кире кайтырлык.

* * *

Сабый чакта гына казалардан
Саклый безне, саклый фәрештә.
Белеп-белми кылган гөнаһыбыз
Киртә була аннан һәр эштә.

Көч-куәтле чакта, кешеләрнең
Бик күп булса әгәр ялгышы,
«Нигә алай эшләдем икән?» – дип
Үкенеп уза калган яртысы.

КАЕН ЕЛЫЙ

Яшел яфрагыннан җылы тамчы
Шуып төшеп, җиргә сыена.
Каен елый. Энҗе күз яшьләре
Тама җирнең җылы куенына.

Табигатькә серен сөйли каен,
Тып-тын гына түгә моң-зарын.
Яшен ташы кара күмер иткән
Бер тамырдан үскән яшь парын.

Михаил Худяков

(Дәвамы. Башы 45, 46, 47, 48 нче саннарда).

Борынгыдан калган төзү сәнгате ядкярләренең Казанда булмавы татарлар яши торган башка җирләрнең архитектура ядкярләре белән бераз каплана. Касыйм ханлыгының элеккеге башкаласы – Касыйм шәһәре шулар арасында беренче урында тора. Бу ханлык Русия җирләрендә, Ука елгасы буенда татарлар тарафыннан оештырылган булып, аның тәхетендә Казан солтаны Касыйм утырган, шуңа карамастан ул урыс биләмәсе дип саналган. Казан ханлыгы исән-сау вакытта Касыйм шәһәре Казан белән тыгыз мәдәни элемтә саклаган һәм тулысынча Казан мәдәниятенә бәйле булган. 1519 елда бу бәйләнеш көчәя, чөнки Касыйм ханы Шаһгали Казан тәхетенә хуҗа булып ала һәм 50 ел буе алыш-тилеш әле бер, әле икенче тәхеттә утыра. Менә шушы хәлләрне искә төшереп, без Касыймдагы төзү сәнгате белән Казанның архитектурасы арасында зур якынлык булырга тиеш дип гөман кыла һәм татарларның мөстәкыйльлек заманындагы сәнгатьләре эзләрен эзләп Касыйм шәһәренә мөрәҗәгать итә алабыз.

Хәзерге вакытта Касыймда Казан ханлыгы дәвереннән татарларның ике архитектура ядкяре сакланган. Болар – Хан мәчетенең манарасы белән Шаһгали ханның тәкиясе (кабере). Шул ук заманда салынган Хан мәчете бинасы белән Хан сарае инде җимерелеп тәмам юкка чыккан. Бу ядкярләрнең төзелүе Казанда хөкем сөргән ханнар исеменә бәйле риваятьләргә караганда, биек манаралы Хан мәчетен, Хан сараен Казан ханы Олы Мөхәммәднең улы Касыйм салдырган. Бу 1467 елда гамәлгә ашырылган дип фаразлана (Вельяминов-Зернов, I, с.68-69). Борынгылыгына күрә ышанычлырак чыганак мәчет белән манараны Шаһгали идарә иткән елларда салынган дип күрсәтә. Бу хакта Касыйм ханы Ураз Мөхәммәднең яраны үзенең 1600 елларда язылган «Җамигыт-тәварих» әсәрендә билгеләп үтә. Шаһгали тәкиясенең 1555 елда корылуы тарихта мәгълүм.

Касыймдагы Хан мәчетенең манарасы – таштан төзелгән олпат-саллы түгәрәк манара өстендәге мәйданчыгына шундый ук кечерәк манара утыртылган, түбәсе – очлаеп килгән түгәрәк түбә. Бөтен Көнчыгыш Аурупада Касыймдагы Хан мәчете манарасына охшаш ике генә архитектура ядкяре бар, һәм аларның охшашлыгы шул дәрәҗәдә ки, барысын да бер үк төзү сәнгате мәктәбе вәкилләре салганлыгына шик калмый. Болар – Болгардагы Зур һәм Кече манаралар. «Дүрткел» мәчетенең манарасы булган Зур манара хәзер инде юк, ул 1841 елда ауган һәм безгә фәкать Паллас, Эрдман вә Шмидт рәсемнәреннән генә мәгълүм. Кече манара әле дә тора. Икесенең дә ясалышы бер үк төрле: таштан төзелгән саллы-олпат түгәрәк манаралар, өсләрендә мәйданчык һәм дә шундый ук кечерәк түгәрәк рәвешендәге икенче кат. Касыймдагы Хан мәчете манарасы бу корылмаларга ясалыш тәртибе һәм тышкы кыяфәте белән дә, төзү алымнары һәм төзү материаллары белән дә бик нык охшаган. Касыймдагы манараның Кече манарага охшашлыгы аеруча гаҗәп – икесенең дә пропорцияләре бер үк. Болгар манарасы Касыйм ядкяреннән фәкать нигезе дүрткел рәвешендә булуы белән генә аерылып тора, Касыйм манарасы нигезеннән үк түгәрәк булып күтәрелә. Касыймдагы һәм Болгардагы төзү сәнгатенең охшашлыгын бары бер төрле генә аңлату мөмкин: касыймнар әлеге архитектура шәкелләрен Казаннан күчереп алган, ә Казан исә, табигый ки, боларны үз нәүбәтендә, Болгардан алган булган. Әлеге һәйкәлләрне үзара Казан бәйләп тора. Мондый охшашлык башкача берничек тә барлыкка килә алмаган, чөнки Көнчыгыш Аурупада бүтән андый һәйкәл юк. Шулай итеп, без Казандагы төзү сәнгатенең элгәреге Болгар сәнгате белән тыгыз бәйләнгән булуына раслау табабыз.

Касыймдагы Хан сарае белән Шаһгали тәкиясенең харәбәләре дә Болгардагы биналарны хәтерләтә. Бу биналар да таштан салынган булган. Хан сараеның нигезе 1830 нчы елларда юкка чыгарыла, әмма аның планы Гагин архивында сакланып калган (план белән сызым Вельяминов-Зернов китабында күрсәтелә. I, 1 табл., 5 һәм 6 рәсем). Бу таш бина буйга 11 ½ сажин, киңлеге исә 5 ½ сажин булган, ул төрле зурлыктагы ике өлешкә бүленгән. Бина астындагы корылмага тышкы баскычтан төшкәннәр. Әле XVIII гасырда да Хан сарае янында кабартылган гарәби нәкышләр белән бизәлгән капка торган. Хан мәчете янындагы Шаһгали тәкиясе шулай ук болгар биналары белән охшаш (Вельяминов-Зернов). Ул таштан салынган, ләкин соңгы чорларга нисбәтле гөмбәзләре кирпечтән эшләнгән. Бинаның буе 7 сажин тирәсе, киңлеге 4 сажин, биеклеге 2 ½ сажин чамасы. Тәкиядә ике бүлмә: кечкенәсе дога укыр өчен хезмәт итсә, зурысында – каберләр. Бинаның 4 тәрәзәсе, ике ишеге бар. Бер ишекнең кашындагы таш тактада: «Ошбу бинаны булдыручы хуҗасы – Шәех Әүлияр солтан бине Шаһ Гали хан. 962 сәнә рамазан 21 көнедер» – дип кабартылып язылган. Бу сан 1555 елның 9 августына туры килә. Әлеге сүзләрне Коръәннең II сурәсендәге 256 аяте урап алган (Вельяминов-Зернов, I, с.494-496). Тәкиянең эчендә 9 кабер – шулар арасында Шаһгалинең үзенеке, хатыны Бүләкшадныкы, асрамалары Хансолтан белән Маһисолтанныкы... Тәкия астында гөмбәзле корылма бар.

● Казан кирмәне, XVI гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

XVI йөздә төзелгән бу татар архитектурасы ядкярләре (сакланганнары да, юкка чыкканнары да) болгар төзү сәнгатенә һичшиксез охшаган һәм Казан ханлыгында да биналар нәкъ шулай төзелгәнлеген исбатлый. Шул рәвешчә, Кремль калкулыгында табылган ике таш кыйпылчыкка һәм Касыймдагы архитектура ядкярләренә карап менә нәрсә фараз кылырга мөмкин: 1) Казан ханлыгында иң яхшы йортлар таштан салына торган булган, Битекче кенәгәсе дә Кремль калкулыгында таш биналар булуын раслый; 2) Казанда өстендәге мәйданчыгына түгәрәк икенче каты урнаштырылган саллы-олпат түгәрәк манаралар булуы ихтимал; 3) сарай биналары белән хан төрбәләре Болгардагы һәм Касыймдагы шундый ук биналарга охшаш булган; 4) иң яхшы йортлар ябыштырып эшләнгән гарәби нәкышләр белән бизәлгән булган.

Казанның риваятьләрдә хәбәр ителгән 8 манаралы Җамигъ мәчетен күз алдына китерү исә читенрәк. Мөселман Көнчыгышының классик архитектурасында 4 манаралы (почмакларга урнаштырылганнар) мәчетләр ешрак очрый; Истанбулда Әхмәд солтан мәчетенең 6 манарасы бар (ян-якларга өчәрләп урнаштырылганнар). 8 манарага килгәндә исә, иң гадие һәм иң ышанычлысы – аларның дүрткел ясап урнашулары (һәр якта икешәр манара). Казанда шундый корылмаларның булганын раслый торган мәгълүматлар бар. Мөселман Казанында манараларны болай урнаштыру каян килгәнен ачыклау Шәрекънең төзү сәнгатен өйрәнүче тарихчылар өчен кызыклы мәсьәлә, һәм аны чишү Казан белән башка мөселман мәмләкәтләре арасындагы мәдәни багланышларны яктыртып җибәрер иде, мәчетнең салыну вакытын да ачыклау җаен тудырыр иде. Алга таба без моның урыс сәнгате өчен дә әһәмияте аз түгел икәнен күрербез.

Агачтан йортлар салу мәсьәләсенә килгәндә, сәнгатьнең бу төрендә милли чалымнар гасырлар дәвамында аз үзгәреш кичергән. Хәзергә кадәр бу татар архитектурасында милли иҗатның үзенчәлегенә тап булабыз. Кызганычка күрә, әлегә кадәр сәнгать тарихчылары Казан татарларының төзү сәнгатенә тиешле игътибар биргәннәре юк.

Казан татарлары ирешкән үзенчәлекле архитектура шәкеле дип без мөселман мәчетенең манарасын мисалга китерә алабыз. Мәчет гадәттә туры почмаклы агач йорт рәвешендә салына, түбәнең уртасында манара торгызыла. Биек булмаган манара ачык беседкалы яки пыялаланган гүрнәчәле, 8 кырлы биек чатыр белән капланган, чатыр өстендәге шпицка кыйгач ай беркетелә. Аның пропорциясе аерым бер канун нигезендә саклана, шуңа күрә ул җиңел, төз һәм купшы кыяфәт ала. Классик архитектура үрнәкләре, шулай ук Кырым татарларының иҗат казанышлары белән Казан мәчетләре манараларының һичнинди уртаклыгы юк. Биредәге манаралар алардан урыннары (түбә уртасында), архитектура шәкелләре, түбәләре һәм пропорцияләре белән аерыла. Үзенчәлекле манара силуэтын һәр татар авылында очратып була, чөнки һәр татар авылында һичшиксез бер, кайсыларында ике, өч мәчет эшли. Манара иңенең биеклегенә нисбәте, шулай ук чатыр түбәнең пропорциясе тотрыклы кимәлдә саклана, ләкин татар сәнгатенең бу өлкәсе беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән. Еш кына чатыр түбәнең биеклеге аның нигезе диаметрына 3,5:1 яки 4:1 нисбәтен тәшкил итә.

Казан татарларының торак йортларында үзенчәлек азрак. Йортлар биредә урамга карап тормый, ә эчкә кертеп салына, урамнан аларны койма аерып тора. Койманың өстен рәшәткәлиләр, шуның аша монда яшәүчеләр, үзләре күренмичә генә, урамны күзәтә алалар. Авылларны бүрәнәдән салынган гадәти йортлар хасил итә. Казан байларының тораклары ике катлы берничә өйдән гыйбарәт. Астагы катта алар яшәми, ул төрле әйберләр саклау өчен келәт буларак файдаланыла; өйләр бер-берсенә пыялаланган галереялар һәм рәшәткәле террасалар белән тоташкан. Пыяла

китабыннан өзекләр

гадәттә зәңгәр, яшел, кызыл, сары, миләүшә төсләрдә. Бай йортларның өстендә һичшиксез гүрничә – борынгы урыс теремнарына охшаган чарлак була.

Татарларның милли холкы, мөгаен, бер генә сәнгатьтә дә бизәкләү сәнгатендәгедәй тулылык белән ачылмыйдыр. Бизәкләү-нәкышләү принциплары буенча татарлар урысларның капма-каршысы икән: урыслар агач биналарны һәм көнкүреш җиһазларын, гадәттә, агачны уеп бизәклиләр, буяуны бары тик тәрәзә яңакларын, капкачларын нәкышләү өчен генә кулланалар; татарлар, киресенчә, уеп-сырлап бизәмичә, фәкать төсле буяулар белән генә эш итә. Татар сәнгатенең төп табигый халәтен төсләр билгели. Аларның архитектура корылмаларын бизәкләү-нәкышләү сәнгатендә төсләргә иркен урын бирүләре Шәрекъ белән туганлыкларына аермачык ишарәләп тора. Сәмәркандтәге, яисә Шәрекъның башка төбәкләрендәге төсле чынаяк кирпечләр белән чуарлап нәкышләнгән мәчетләрнең мәгърурәнә бөеклеге белән туганлык бу.

Биналарның күзгә иң ташланып торган урыннарын буяп бизиләр – мәчетләрнең манараларын, йортларның кыекларын, коймаларны, капкаларны. Полихромия – күп төслелек – татарча буяп бизәүнең төп үзенчәлеге. Татарлар һичкайчан да әйберне бер генә төскә буямый, һәрвакыт берничә төс куллана. Бер-бер артлы чиратлашып балкып торган төсләргә карап гаҗәпкә каласың, сокланасың. Төсләрнең болай чиратлашуын (сары белән яшел, яшел белән кызыл, сары белән зәңгәр) урыслар «татарский вкус» («татар зәвыгы») диләр. Төсләрнең иң гадәти янәшәлеге (гаммасы) гади генә – ул һәрвакыт бер үк төрле диярлек: яшел, зәңгәр, ак һәм сары төсләр. Бүтән төсләрне, шул исәптән кызыл төсне дә, Казан татарлары яратмый һәм бик сирәк куллана (хатын-кыз киемнәрендәге кызыл төс урыслар эшләгән ситсы тукымалар аркасында гына таралыш тапты, элек татар киемнәре бары тик сары, яшел һәм зәңгәр тукымалардан гына тегелә торган булган)...

Татарлар йортларын юка такта белән тышлыйлар. Киң һәм тар такталар аркылыга аралаш сугыла. Тар такталар өслекнең аскы катламы рәвешендә эчкә кереп тора, ә киңнәре өске катламны хасил итә. Алар төрле төсләргә буяла. Мәчет манарасының тар такталары гадәттә ак төскә, ә киңнәре сары яки зәңгәр төсләргә буяла. Мәзин азан әйтә торган мәйданчык астындагы кайма гадәттә дүрт төстән гыйбарәт. Төсләр шул тәртиптә урнаша: яшел, зәңгәр, ак һәм сары. Галереяның баганалары һәм кәрнизе ак төскә, чатыр һәрвакыт яшел төскә буяла.

Йорт фронтоннары, кырыйлары ак төстә каймаланып, яшелгә яки сарыга буяла. Кайчакта фронтонга ярым түгәрәк тәрәз уялар, аның әйләнәсе аерым төстә була. Йорт стеналарын буяу рәвешен без ике төргә бүләбез – беренче очракта такта тышларына бәйле рәвештә стеналар аралаштырып ике төскә буяла. Киң такталар сарыга, кайчагында зәңгәргә яки яшелгә, ә тарлары ешрак акка (киң такталар яшел булганда кызылга) буяла. Икенче очракта стеналар бер генә төскә – сарыга, зәңгәргә, яшелгә буяла, ә почмаклардагы пилястрлар ак төстә була. Хуҗалары ярлырак йортларның фронтоннары гына буяла, стеналары тышланмый. Капкаларны бизәүгә аерата зур игътибар бирелә. Капканың һәр ике канаты уртада зур түгәрәк чәчәк белән бизәлә, почмакларга да чәчәкнең бер өлеше ясала. Капка үзе җете төсләргә – яшелгә, сарыга яки зәңгәргә буяла, кырыйларындагы кайма белән чәчәкләр ак төстә була. Татарлар белән урыслар арасындагы декоратив бизәүдәге аерма капкаларда бигрәк тә нык чагыла, урыслар капкаларына буяу тидермичә такталарны сырлап-уемлап бизи.



● Казан каласы, XVI гасыр. Фиринат Халиков картинасы.

Шәрекънең урыс сәнгатенә ясаган йогынтысы бер генә мәртәбә билгеләп үтелмәде инде, әмма урысларның төзү сәнгатендәге татар йогынтысы әлегә тиклем бөтенләй өйрәнелмәгән, чөнки татар сәнгате үзе дә әлегә һич өйрәнелмәгән көенчә кала килә. Монгол ханнары урысларны татар дәүләтчелегенә буйсындырып, бу ике халык арасындагы мәдәни йогынтыларны көчәйткәнче үк инде Шәрекъ мотивлары урыс сәнгатенә һичшиксез кушыла барган дип уйларга кирәк. Шәрекъ мотивларының кайсылары урыслар татарларга буйсынганчыга кадәр үк кыпчаклардан һәм болгарлардан үтеп керүен һәм кайсыларының урыслар тарафыннан татар изүе дәверендә һәм соңрак чорда үзләштерелүен аерып әйтү мөмкин түгел. Русиягә көнчыгыштан килә торган болгар-татар йогынтысы, күрәсең, Казан ханлыгы заманында да Шәрекъ мотивларын илтүче төп көч булгандыр. Урыслар, үзләренең һәм икътисади, һәм көнкүреш мәнфәгатьләре белән, татарларның башка кавемнәргә караганда казаннарга тыгызрак бәйләнгән була. Шуңа күрә дә без бу хезмәттә урысларның төзү сәнгатенә татарлар ясаган йогынтыга кагылып узуны кирәк дип саныйбыз...

И.Е.Забелинның урыс төзү сәнгате турындагы язмасын укыганда без шәрекъ йогынтысына игътибар итми калмыйбыз. Ул Мәскәү дәверендәге торак йортны тасвирлый: «Хоромнар сүзе зур яки кечкенәрәк торакны аңлата. Әлеге борынгы йорт бербөтенне хасил иткән аерым өлешләрдән торган, шул ук вакытта һәрбер өлеш мөстәкыйль дә булган, бүтәнчә әлеге борынгы йортны күплек санда «хоромнар» дип атамаслар иде. Аерым һәм төрле бүлемнәрдән торган әлеге хором бинасы, әлбәттә, төгәл план белән салынмаган. Фасад хакында да шуны ук әйтеп була. Бүлемнәре төрле һәм аерым булганга, алар хәтта бер сызыкта салынсалар да, хәзерге мәгънәдәге камил фасадны кору мөмкин булмаган. Хәер, безнең борынгы осталар аны кирәксенмәгән дә. Мәскәүнең XVI гасырда итальян архитекторлары тарафыннан салынган таш сарае да хәтта төрле зурлыктагы аерым бүлемнәрдән – Грановитый, Алтын, Ответный палаталардан гыйбарәт, һәм ул симметриясе белән бербөтен түгел. Иске гадәт буенча, бай хоромнар күп очракта урам сызыгыннан күпкә эчкә кертеп салынган (Забелин «Черты самобытности в др. рус. Зодчестве», изд. Кнебель, 1900, с.35, 47, 48 и 49). Бу тасвирламада шәрекъ, хосусән, татар архитектурасының барлык чалымнарын табып була: 1) биналарның катлаулы салынуы, аерым бүлемнәрнең һәм пулатларның бербөтен торак хасил итүе, 2) корылмаларның бер планы булмавы, 3) фасадның булмавы һәм 4) йортны эчкә кертеп салу.

Шәрекъ чалымнары Мәскәү архитектурасына аеруча көчәеп кушылган ике дәверне билгеләргә мөмкин. Болар – XVI йөзнең беренче яртысы һәм уртасы (Василий III хакимлеге һәм Иван IV хакимлегенең башы) белән XVII йөзнең икенче яртысы (Алексей Михайлович патша тәхетендә утырган вакыт). Бу дәверләрнең беренчесе генә Казан ханлыгы исән чакка туры килә һәм безнең игътибарга лаек. Әлеге заман – гомумән, Шәрекъ мәдәнияте йогынтысының көчле агым булып Русиягә агып кергән еллары һәм урысларның Шәрекъ белән бик мавыккан чагы. «Йөзбашлы җыен (Стоглавый собор) «безбожный Махметның тәпәсен (түбәтәен)» киеп йөрүгә каршы сүз әйтергә дә өлгерми, «Беседы Валаамских чудотворцев»ның авторы урыс кешеләрен төрек башлыгы белән ыштанын (ягъни тулы костюмы) киюләре өчен оялтырга мәҗбүр була. Мәскәүгә чакырып китерелгән Византия патриоты Максим Грек бик борчылып-көенеп туган илендәге дусларына, мәскәүләр, мөгаен, тиздән чалма киеп йөри башлар, ахрысы, дип яза. Шәрекъ киемнәре белән мавыгу тормыш-көнкүрештәге кискен үзгәрешләргә бәйле. Яңа баш киемен тыеп, Йөзбашлы җыен Мәскәүдә чиркәүгә бүрек салмыйча керү сыман христианнарга чит-ят булган гадәтнең пәйда булуын телгә ала» (Виппер. Иван Грозный, с.14). Нәкъ менә шушы чорда Русиядә гыйбадәтханәләр янына элеккечә итеп чаң кагу корылмалары ясау урынына 8 кырлы манаралар төзи башлыйлар. Боларның өске өлешендә биек чатыр түбә астындагы ачык мәйданчыклар була. Урыс чиркәве тарихчысы профессор Голубинский язганча, ул дәвердә «агач машлар һәм чаң кагу урыннары ике төрле ясалган: 8 кырлы машның югарыгы өлешендә мәйданчык, анда чаң һәм аның чукмары урнаштырылган, боларның барысын баганалар өстендәге биек чатыр каплап тора; һәм 4 кырлы, берничә катлы, зур аралык-бушлыклары булган маш, түбәсе биек түгел, һәм ул теге яки бу рәвештә ясалырга мөмкин. Беренче төр машларның рәвеш-кыяфәте безнең теремнардан (йорт өстендәге бина, яки манара сыман аерым йорт) алынган булса кирәк дип уйлыйм, шул вакытта аларның максатына яраклашып итеп кыяфәте бераз үзгәртелгән (чаңнар белән аларның чукмарларын урнаштыру өчен ачык мәйданчык ясалган)». (История русской церкви, т. II, 2, с. 340). Бу тасвирламадан татар мәчете манарасының төс-кыяфәтен тану кыен түгел. Мәчет манарасын үзгәртеп, профессор Голубинский әйткәнчә, максатка яраклаштырып та торасы юк, чөнки аның чатыр түбәсе астында азанчы өчен һәрвакыт ачык урын булган, бары кыңгырау гына элеп куярга кирәк. Казан ягындагы авыл мәчетләре манараларын Русиянең төньяк төбәкләрендәге чатырлы машлар белән чагыштырып карагыз – аларның бертуганнар икәненә ышанырсыз.

(Ахыры 16 нчы биттә).

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе

Мәдәни җомга
15 декабрь
№49, 2023

АЛИШ

Рафис КОРБАН

● **Абдулла Алишның хатыны Рокыя уллары белән белән. 1944 ел.**

(Дәвамы. Башы 46, 47, 48 нче саннарда).

3.

Икенче көнне үк бара алмады Оркыя Язучылар союзына. Мартның соңгы якшәмбесе иде. Көне буе диярлек дәфтәрләрнең әле берсен, әле икенчесен укыды. «Боларны кешегә күрсәтергә ярый микән соң?» дип тә уйлады. Сердәшләре куркып тормаска, Язучылар союзына илтеп тапшырырга, дип киңәш бирде-бирүен. Анда бит әле ни диярләр? Сугышның беренче елында ук пленга төшүләре хакында билгеле булгач, төрле сүзләр йөрде бит. Әминә белән аның турында да төрле пычрак сүзләр әйтеп бетерделәр. Алар гынамы соң, Мусаның беренче хатыннары Рауза белән Зәкияне ничек кенә мыскылламадылар. Аларга Әминәгә караганда күбрәк тә эләкте әле ачы теллеләрдән. Әминәгә әлләни күп эләкмәде, ул Җәлилева фамилиясен йөртми иде шул. Сейфуллина Нина Константиновна булып йөрде. Аннары, Казан күзеннән качып, бөтенләй Мәскәүгә үк китеп барды. Рауза былтырга хәтле Җәлилова булып йөрде. Улы Альберт Мусаның копиясе инде. Былтыр Бауман урамында очратты аларны Оркыя. Улы белән каядыр ашыгалар иде. «Ашыгам», – диде Рауза. Бер хәрбигә кияүгә чыккан икән дә, Киевка китәргә йөриләр икән. Киткәннәр дә ди бугай инде. Ә Зәкия Казанда – радиостудиядә эшләп йөри. Аның да кызы үсә Мусадан. Люция. Унбер яшьтә бугай инде. Анысы да әтисенә охшаган.

Оркыя, дәфтәрләрне Союзга илтсәм, анда ни булмас, юк итүләре дә мөмкин дип, Алишның шигырьләрен Алмазның язу дәфтәренә күчереп куярга кирәк дигән уйга килде. Көннең икенче яртысы шул эш белән үтте.

Тышта мартның соңгы көне, салкынча иде. Оркыя юка пәлтәсен киеп мамык шәлен бөркәнде дә, дәфтәрләрне кул сумкасына тыгып, Язучылар союзына барырга чыкты. Чернышевский урамына менеп, Бауманга төште дә, матбугат йортына таба атлады. Язучылар союзы шул бинада урнашкан иде.

Әхмәт Ерикәй ишекне болай да куркып кына ачып кергән Оркыяны караңгы чырай белән каршы алды. Хатын аның сытык чыраен күргәч, алдан әйтергә дип әзерләнеп кергән сүзләрен онытып, тәмам коелып төште. Шулай да үзен кулга алып, исәнләшергә көч тапты:

– Исәнмесез, Әхмәт абый...

– Исәнме. Ни йомыш? – диде Ерикәй, төксе генә.

Оркыя калтыранган куллары белән кул сумкасын ачып, кәгазьгә төреп килгән дәфтәрләрне чыгарды да өстәл янына килеп:

– Өченче көн бер кеше Алиш белән Муса Җәлил шигырьләре язылган шушы дәфтәрләрне калдырып китте, – диде һәм аларны Ерикәйнең алдына, өстәлгә куйды.

Дәфтәрләрне күргәч, Ерикәйнең әле генә мыскыллы елмаю белән балкыган йөзе агарынып китте:

– Нинди кеше?.. Нинди дәфтәрләр?..

– Алиш белән Җәлилнең шигырьләре. Өченче көн кичке якта Нигъмәт Терегулов атлы кеше килеп керде дә, Алиш белән Җәлилнең һәм тагын берничә кешенең фашист төрмәсендә җәзаланып үтерелүләре хакында сөйләде. Алар белән бергә булган бер тоткынның аларның төрмәдә язган шигырьләрен алып чыгуы һәм аңа бирүе турында әйтте. Ул сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан. Уфада яши икән. Менә бер елдан соң шул дәфтәрләрне безгә алып килгән.

– Ул кеше каян белгән сезнең адресны? Нишләп Мусаныкын да сезгә китергән?

– Алиш шигырьләре язылган дәфтәрдә безнең һәм Язучылар союзының адреслары күрсәтелгән. Шулар буенча китергән.

– Кем дисең әле исемен? Терегуловмы?

– Әйе, Нигъмәт Терегулов.

– Үзен күреп сөйләшергә иде бит. Адресын алып калмадыңмы?

– Уфадан, диде. Казанда тукталган. «Совет» кунакханәсендә, диде.

– Яхшы, бар, кайт. Без монда идарәдә киңәшләшербез. Нәрсә хәл иткәнне хәбәр итәрбез. Хуш.

Оркыя ни дияргә дә белмичә, хушлашып чыгып китте.

Ерикәй яшьли комсомол, партия члены булып алган, судта халык судьясы булып торган, төрле газит редакцияләрендә эшләп, сугыш елларында фронт газитләрендә хезмәт иткән, былтырдан бирле Татарстан Язучылар союзы рәисе вазыйфаларын башкаручы шагыйрь иде. Мәскәүдә яшәгәндә татар опера студиясенең әдәби бүлек мөдире булып торган Җәлилнең якын дусты булып йөрсә дә, ул дустының бернинди дә халык дошманы түгеллеген раслап, органнар алдында аклау сүзе әйтергә җыенмый иде. Киресенчә, Оркыя чыгып китүгә үк дәфтәрләрне карап, танышып чыгуны да кирәк дип тапмыйча, боларны нишләтергә икән дип баш ватты. Үзе генә бер-бер чара күрергә курыкты, әлбәттә, Оркыя кешегә таратса – бәласеннән баш-аяк. Обкомга илтеп бирергәме, әллә Черек Күл буендагы оешмага барыргамы?..

Көннәр буе «Алишларны нишләтерләр, исемнәрен акларлармы, шигырьләрен бастырып чыгарырлармы?» дип уйлап йөргән Оркыяны ике көннән күршеләрендә генә урнашкан әлеге шул дәһшәтле оешмага чакырып алдылар. Сугышка кадәр алар буш вакытлары булуга, дүртәүләп, Черек Күл тирәсе буйлап йөрергә чыга иде. Утыз җиденче елларда шул шомлы бинага кара машиналарда «халык дошманнары»н алып килгәннәрен дә күп тапкырлар күрергә туры килде аларга. Менә хәзер үзенә дә чират җитте. «Нигә чакырдылар икән?» дип борчылып, курка-курка гына барып керде хатын повесткада күрсәтелгән адрес буенча утырган тикшерүче кабинетына. Кабинетта аның белән ягымлы гына сөйләштеләр. Тикшерүче урын тәкъдим итте. Оркыя күрсәтелгән урындыкка утыруга, күзе тикшерүче алдында яткан таныш дәфтәрләргә төште. Тикшерүче моны шунда ук сизде һәм:

– Таныдыгызмы? – дип сорады.

– Таныдым. Нишләп алар монда? – диде хатын, гаҗәпләнеп.

Кабинеттагы икенче өстәл артында утырган егет язу машинкасын шакылдатып Оркыяның җавапларын кәгазьгә төшерә барды.

– Каян алдыгыз бу дәфтәрләрне?

– Ирем белән бергә тоткынлыкта булган кеше китереп бирде.

– Кем инде ул, сер булмаса?

– Сер түгел, Нигъмәт Терегулов дип таныштырды үзен.

– Сугышка хәтле ул кешене күргәнегез булдымы?

– Юк, беренче күрүем иде.

– Ниләр сөйләде инде Терегулов? Бу дәфтәрләрне кайдан алган? Берни дә алдамыйча, дөресен сөйләгез.

– Алдамыйм, дөресе шул. Әсирлектә Алиш һәм Җәлил белән бергә утырган Габбас Шәрипов дигән кеше алып чыккан булган ул дәфтәрләрне төрмәдән. Франциядә очрашкач, шул Шәрипов биргән Терегуловка.

– Терегуловның адресын алып калдыгызмы?

– Алиш дәфтәре артына язып куйдым.

– Бу кеше турында тагын ниләр сөйли аласыз?

– Берни дә. Шул бер тапкыр күрдем бары.

– Бу дәфтәрләр турында тагын кемнәр белә?

– Язучылар союзы председателе Әхмәт Ерикәй.

– Тегеруլов килгәндә өегездә тагын кемнәр бар иде?

– Улларым – Алмаз белән Айваз. Башка кеше юк иде.

Оркыя дус хатыннары турында әйтмәде. Аларны да сорау алып аптыратып бетерерләр, дип уйлады.

Шуның белән тикшерүченең сораулары бетте. Ул Оркыядан чакыру кәгазен алып, нәрсәдер язды да, кире биреп:

– Сез китә аласыз,– диде.

Хатын, хушлашып, ишектән чыкса, ишек төбендә Нигъмәт Терегулов утырып тора иде. Аларның карашлары очрашты. Оркыяга уңайсыз булып китте. Ул аның белән исәнләшеп:

– Исәнмесез, Нигъмәт. Минем бернинди гаебем дә юк, кичерегез, – диде.

– Борчылмагыз. Мин беләм,– диде Терегулов...

4.

Алиш белән танышканда Оркыя әле медицина техникумында укый иде. Ә Алиш үзе инде Җир төзелеше техникумын тәмамлап, Минзәләдә бер ел мелиоратор булып эшләгәч, Казанга кайтып, КазГрэс төзелешендә эшләп йөри. Бер үк вакытта шәһәр канализация челтәрендә техник хезмәтен башкара. Ләкин үзе технарь булса да, аның бөтен дуслары язучылар. Ул үзе дә балалар өчен хикәяләр, әкиятләр яза. Ничектер шулай бервакыт бер төркем яшь язучылар медицина техникумы укучылары белән очрашуга килде. Менә шунда күрде Алиш Оркыяны беренче тапкыр. Ул аны шунда вальс әйләнергә чакырды.

– Мин язучы Абдулла Алиш булам, – диде ул кызга.

– Ә мин медицина училищесының соңгы курс укучысы Оркыя Латыйп кызы Тюльпанова булам.

– Матур фамилия, – диде Алиш. – Чәчәк исеме икән. Лалә чәчәге.

– Миңа тюльпан ошыйрак.

– Шулайдыр, әлбәттә. Һәркемгә үз кулмәге якынрак була бит.

Аннары Алиш кыздан өенә озатып куярга сорады. Оркыя Яңа бистәдә яшәүче Казан кызы икән. Сөйләшеп кайта-кайта ул аларның Казанга Троицк шәһәреннән күчеп килгәнлекләрен, әтисенең революциягә кадәр сәүдәгәр булуын белде. Нэп елларында Казанда да сәүдә эшен киң җәелдергән булган. Заманнар үзгәргәч, бу хезмәтен ташлап, шыпырт кына көн күреп ята икән.

Озатып куйганга карап, Оркыя Алиш дип әлләни егылып китмәде. Үзен горур тотты. Бай гаиләдә үскән, светский тәрбия алган булуы әллә каян сизелеп тора иде.

Аның әтисе ягыннан туган тиешле Рабига апасы бар. Бергә яшиләр. Язучы егеткә шундый мөнәсәбәтен белеп алган апасының сүзен тыңлап кына Алишка карашы үзгәрде аның. Шулай да горурлыгы үзен нык тоттырды: өйләнешкәндә, «Фамилиямне Тюльпанова дип калдырырга риза булсаң гына кияүгә чыгам!»– дип белдерде. Алиш каршы килмәде. Ул елларда укытучылар, светский тәрбия алган кызлар арасында кияүгә чыкканда үз фамилияләрен саклап калу модада иде. Фатих дустына чыккан курсташлары Кадрия дә Ишукова булып калды. Зарар юк, яшиләр, аңа карап дөньялары кителеп төшмәде. Алар да яшәр.

Бергә яши башлагач аңлады Оркыя апасының хаклы булганын. Алиш кебек гаилә җанлы, хатыным дип, балалар дип үлеп торган тагын бер кеше бар микән бу дөньяда дип уйлый башлаган иде ул. Үзеннән дә бәхетлерәк хатын юктыр дип тә уйлады. Каһәр суккан бу сугыш башланып кына җимерде аларның бәхетен. Бөтен дөньяларын астын өскә әйләндерде. Ә аңарчы... Аңарчы алар бик бәхетле яшәде.

Сугыш башланганда Оркыя Горький паркы янындагы инфекцион хастаханәдә эшли иде. Сугыш башлануга аны госпиталь итеп үзгәрттеләр. Оркыя да шунда шәфкать туташы булып эшләвен дәвам итте.

Ирләр сугышка китә башлады. Алиш белән Муса Җәлил дә хәрби комиссариатка барып, гариза биреп кайтты. Тик аларны беренче көннәрдә үк китүчеләр белән бергә алмадылар. Алар эшкә йөрүләрен дәвам итте.

(Дәвамы киләсе санда).

Йолдызсыз калган 25 татар каһарманы

(Дәвамы. Башы 47, 48 нче саннарда).

КОТДУСОВ ХӘМИТ КОТДУС УЛЫ

Котдусов Хәмит Котдус улы – 1923 елгы, Казанның Бауман район комиссариаты аша озатылган, гвардия лейтенанты, 9 нчы механикалаштырылган корпусның 53 нче танк полкында танклар взводы командиры. 1943 елның 13 ноябрендә Герой исеменә тәкъдим ителә, 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий ордены белән генә канәгатьләнеп калырга мәҗбүр була.

Х.Котдусовның бүләкләнү кәгазе.


Все графы заполнить полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ 02165

1. Фамилия, имя и отчество Кутусов Хамид Кутусович
2. Звание Гвардии лейтенант 3. Должность, часть Командир танкового взвода 53 танкового полка 69 мех. бригады 9 мех. корпуса
Представляется к званию ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА
4. Год рождения 1923 5. Национальность башкир 6. Партийность
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) Сталингр. фр. с 8 по 11-42 Ворон. фр. с 12-42 по 2-43 г. 1-й Украинский фр. с 9-43 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне ранен
9. С какого времени в Красной Армии 1941 10. Каким РВК призван Бауманским РВК г. Казань
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) не имеет
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

В боях с 4 по 13 ноября 1943 г. по блокированию г. КИЕВА по освобождению г. Фастова и удержанию в своих руках коммуникаций противника гв. лейтенант Кутусов проявил исключительный героизм и умение руководить танковым взводом в бою. В боях 6.11.43 г. за д. Романовка и х. Шевченко тов. Кутусов умелыми и решительными действиями своего взвода обеспечил овладение полком этими населенными пунктами. Действуя с фланга, перерезал пути отхода противнику, разгромил обоз противника, поджег автомашину с б/припасами, живыми захватил мотоцикл, рацию и взял в плен двух немецких офицеров и уничтожил до взвода пехоты противника. 9 ноября в боях за Фастовец т. Кутусов лично сам уничтожил два немецких танка и до 40 солдат и офицеров пр-ка. Будучи ранен не вышел из боя, вывел машину только тогда, когда она была повреждена. Исправив машину и перевязав себя снова вышел на поле боя и занял оборону. 10-12 ноября находясь в обороне г. Фастов гв. лейтенант Кутусов действуя в составе 7 машин полка отразил три яростных атаки большой группы танков противника и удержал занимаемый им рубеж обороны.

За исключительный героизм и умелое руководство танковым взводом в боях по блокированию г. КИЕВА и освобождению г. Фастов представляю к присвоению звания ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

Командир 53 танкового полка
Гв. Подполковник /СУХОВАРОВ/
13 ноября 1943 г.

САФИН РОБЕРТ САЛИХ УЛЫ

Сафин Роберт Салих улы – 1923 елда Апас районының Шимәк авылында туа, шул район комиссариаты аша фронтка озатыла. 2 нче Белорус фронтында 49 нчы армиянең 238 нче Карачай укчы дивизиясендә 843 нче полкта пулеметчылар взводы командиры була, кече лейтенант. 1944 елның 15 июлендә Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

СӨЛӘЙМАНОВ НУРУЛЛА СӘЙФУЛЛА УЛЫ

Сөләйманов Нурулла Сәйфулла улы – 1925 елгы, Баулы район комиссариаты аша фронтка озатылган. Байкал арты фронтының 36 нчы армиясендә 94 нче укчы дивизиянең 152 нче полкында отделение командиры булып яу йөри, өлкән сержант. 1945 елның 27 сентябрендә Герой исеменә тәкъдим ителә, әмма Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

ФӘИЗОВ ГОСМАН ШАҺИМӘРДӘН УЛЫ

Фәизов Госман Шаһимәрдән улы – 1903 елгы, Лаеш район комиссариаты аша чакырылган. 373 нче укчы дивизиянең 1237 нче полкында батальон политругы, капитан. 1945 елның 28 гыйнварында Герой исеменә тәкъдим ителә, Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

МӘКСУДОВ ЗӘКИ КАШШАФ УЛЫ

Мәксудов Зәки Кашшаф улы – 1924 елда Норлат авылында туган, шул район комиссариаты аша чакырылган. Лейтенант, 19 нчы армиянең Кызыл байраклы, 310 нчы Новгород укчы дивизиясендәге 1082 нче полкта взвод командиры булып хезмәт итә. 1945 елның 2 маенда Герой исеменә тәкъдим ителә, ләкин Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

З.Мәксудовны бүләкләү кәгазе.


Все графы заполнить полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество МАКСУДОВ Заки Кашапович
2. Звание Лейтенант 3. Должность, часть Ком. взвода стрелковой роты 1082 стр. полка 310 стр. Новгородской Краснознаменной дивизии
Представляется к Присвоению звания "ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА"
4. Год рождения 1924 5. Национальность Татарин 6. Партийность Канд. ВКП/б/ с 1944 г.
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) 10.4.1943 г. Волховский фронт. 16.6.43 г. Лен. фронт. 20.11.43 г. 1-й Прибалт. фронт. 4.6.44 г. Карельский фронт и 24.2.45 г. 2-й Белорусский фронт.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне Легко ранен 14.2.44 г. Волхов. фр. 9.3.44 г. 1 Прибалтийский фронт, контужен 15.5.43 г. Волхов. фронт. Легко
9. С какого времени в Красной Армии С 10.8.42 г.
10. Каким РВК призван Нурлатским РВК, Тат А С С Р.
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Орденом "Красная Звезда" приказ по 131 кавдивизии № 016-Н от 22.2.44 г. Медаль за оборону Ленинграда в 1943 г.
12. Постоянный домашний адрес

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

2 мая 1945 года, тов. МАКСУДОВ получил задачу переправиться через пролив Балтийского моря ДИВЕНОВ, севернее города ВОЛЛИН, закрепиться на восточном берегу острова ВОЛЛИН и прикрыть переправу остальных подразделений полка. Противник имел глубокоэшелонированную оборонительную полосу на восточном берегу острова ВОЛЛИН, с большим количеством огневых средств.

В 12 часов дня 2 мая 1945 г. тов. МАКСУДОВ со своим взводом начал переправу на рыбацких лодках через пролив шириной 800 метров. Противник сосредоточил на месте переправы сильный ружейно-пулеметный и артиллерийско-минометный огонь. Тов. МАКСУДОВ первым переправился на противоположный берег пролива и вступил в рукопашную схватку с численно превосходящим противником. Противник пытаясь удержать занятый рубеж переходил в частые контратаки, которые были отбиты с большими потерями для противника. Только за один день ожесточенных боев 2 мая 1945 г. было отражено до семи контратак противника и уничтожено при этом более 150 немецких солдат и офицеров.

Тов. МАКСУДОВ сумел удержать занятый рубеж до подхода главных сил полка.

За проявленное геройство и мужество при форсировании водного рубежа и удержания занятого плацдарма, тов. МАКСУДОВ достоин присвоения звания —

"ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА"

Командир 1082 стр. полка /БАРШОВ/
Командир (начальник)
2 мая 1945

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

яки Солтанбикә Толбийә, Мисырда татар эзләре

Вак кыйпылчыклардан җыелган Алтын Урда тарихы соңгы елларда яңа мәгълүматларга байый бара. Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев һәм шушы үзәкнең өлкән фәнни хезмәткәре Эльмира Сәйфетдинова 1320 елларда Мисыр солтанына кияүгә бирелгән татар кызы Толбийә турында бәян итте.

Тарих битләреннән белгәнебезчә, патша династияләре союздаш илләр белән туганлык җепләре җәелдерергә тырышкан, бер хакимнең улы икенче хакимнең кызына өйләнгән. Андый никахлар Алтын Урда дәүләтенә дә хас булган. Дәүләт дәрәҗәсендә ислам дине кабул ителгәннән соң туганлык җепләре гарәп илләре белән ныгый. Бигрәк тә мәмлүкләр идарә иткән Мисыр белән элемтәләр бәйләнә. Алар арасында иң тантаналысы һәм серлесе – мәмлүкләр солтаны Мөхәммәд ән-Насыйр белән Алтын Урда династиясе гаиләсеннән булган кыз, Мөхәммәд Үзбәк ханның туганнан туган сеңлесе (двоюродная) Толбийә никахы була.

«Үзбәк хан идарә иткән чорда Мисыр солтаны Мөхәммәд ән-Насыйр белән татар кызы Толбийә никахы гарәп елъязмаларында матурлап тасвирлана, – ди Илнур Миргалиев. – Без Толбийәнең нәсел шәҗәрәсен тикшердек. Үзбәкханның атасы Тогрул белән Толбийәнең атасы Тукаҗи бертуганнар була. Димәк, Толбийә – Үзбәк ханның туганнан туган сеңлесе. Толбийәне ән-Насыйрга кодалау берничә елга сузыла һәм 1320 елда Мисырның башкаласы Каһирәдә никах укытыла. Мисырда татар кызына зур хөрмәт күрсәтелә. Елъязмаларда теркәлгәнчә, Мисырда мондый купшы туй аңарчы оештырылганы булмаган».

Толбийә ән-Насыйр белән 8 ел яшәгәннән соң, никах өзелә. Никахның уңышсыз тәмамлануына, яңадан 3 мәртәбә Мисыр әмирләренә кияүгә чыгуына карамастан, Толбийә үлгәнче солтан хатыны (госпожа) статусын саклый. Аның Каһирәдә абруе һәм йогынтысы саклана.

«Толбийә Каһирәдә иганәчелек итә, йортлар, биналар төзетә. Ул үзенә мәрмәрдән төрбә дә ясатып куя. Чыганаклар буенча, Толбийәнең сарае XVII гасырга кадәр саклана. Мисыр тарихчысы әл-Мәкризи һәм испан шагыйре Алонсо де Эрсилья-и Суньига сарайга сокลануларын белдереп, язып калдырганнар. Бүген Каһирәнең бер урамы Толбийә исемен йөртә», – дип сөйли Эльмира Сәйфетдинова.

Узган елда бер төркем галимнәр Мисырга барып, 5 көн дәвамында данлыклы Каһирә каберлеге белән танышып, Алтын Урда мирасын тирәнрәк өйрәнү өчен гарәп галимнәре белән хезмәттәшлек корып кайткан. Алар каберлектә Толбийә төрбәсен дә күргән.

«Толбийәнең төрбәсе җимерек түгел. Аның янында башка каберләр дә бар – алар да җимерек түгел. Бераз акча кертеп, аларны матурлап җибәрәсе иде. Кызганыч, Мисыр бюджетында аларны тәртиптә тотарга акча каралмаган. Илнең хәле мактанырлык түгел. Бу каберлекләр туризм маршрутына да кермәгән, шуңа күрә мәмлүкләр каберлегенә игътибар юк. Иң аянычлысы – каберлек тикшерелмәгән. Аны тикшерсәң, бик күп мәгълүмат табылырга мөмкин. Татарстан Толбийә төрбәсен үз канаты астына алсын иде. Россотрудничествода «ярдәм итәрбез», диделәр. Бу фикерне гарәп галимнәре дә хуплады», – ди Илнур Миргалиев.

Тарихчы бу эшне Мисырда «Мәмлүк һәм Алтын Урда бәйләнешләре» дигән темага конференция үткәрүдән башлап җибәрергә тәкъдим итә. Россотрудничество үз бинасында кунаклар кабул итәргә әзер, һәм гарәп галимнәре белән элемтәләр корылган.

«Конференциядән соң берничә галим – язма чыганакларны, берничәсе кабер ташларын өйрәнсә, реставраторлар Толбийә төрбәсен «шефство»га алса, Алтын Урда буенча яңа чыганаклар ачылыр иде. Мисыр белән элемтәләрне ныгыту Татарстан өчен сәяси яктан да отышлы. Традицион ислам дөньясы буларак та, Алтын Урда белән тыгыз бәйләнешләр булуы белән дә, Мисыр – безгә бик кызыклы ил. Толбийәнең төрбәсен «шефство»га алу зур чыгымнар таләп итми. Аның каравы, мәмлүк солтанының хатыны татар кызы булганын күрсәтеп, милли горурлыкны арттырырга, киләчәк-

● Толбийә кабере.



● Толбийә төрбәсе.

●Сәйф Сараи сурәте. Абдул Фархан фотосы.



●Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге хезмәткәрләре Мисырда гарәп галиме белән.

Тарихка керми калган ачыш: *Алтын Урда шагыйре Сәйф Сараи Җирнең Кояш тирәсендә әйләнгәнен Коперникка кадәр әйткән булган.*

тә гарәпләр белән элемтәләрне ныгытырга ярдәм итәчәк», – ди И.Миргалиев.

Толбийәне өйрәнгәндә, фәндә моңарчы беленмәгән яңа шәхесләр килеп чыгарга мөмкин. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Эльмира Сәйфетдинова Толбийә белән бәйле тагын бер татар шәхесен ачыклаган. Ул – түй процессиясе составында Алтын Урдадан Мисырга килгән Кусун исемле ир-ат. Кусун солтанның ышанычын яулап, Каһирәдә әмир дәрәҗәсенә ирешә. Соңыннан ул солтан ән-Насыйр кызына өйләнә.

«Гарәп чыганакларында татар әмиренең халык алдында купшы күренергә яратканы турында мәгълүмат бар. Сүз уңаеннан, Кусунның да төрбәсе саклана. Бәлки, Сәйф Сараиның да каберен таба алырбыз. Каһирәдә татар эзләре буйлап экскурсияләр маршруты да ясарга мөмкин. Урта гасырларда мәмлүкләр Мисыры үсешендә татарларның да зур өлеше булган», – ди Эльмира Сәйфетдинова.

Сәйф Сараи телгә алынгач, сүзебезне якынча 700 ел элек Алтын Урдада туган татар шагыйре турында дәвам иттек. Сәйф Сараи исеме бүгенге көндә еш яңгырый. Былтыр Самара өлкәсе Камышлы авылында Сәйф Сараи укулары узды. Быел шушы авылның яңа урамына Сәйф Сараи исеме бирергә ниятлиләр, диген хәбәрне дә ишеттек. Район мәктәпләрендә борынгы шагыйрьгә багышланган конференцияләр үткәрү планлаштырыла.

Сәйф Сараиның галим, шагыйрь булып формалашкан вакыты Алтын Урданың болганчык чорына туры килә. Башта чума афәте халыкны кайгыга салса, аннары Аксак Тимер (Тамерлан) Туктамыш ханга каршы сугыш башлый. 1380 елларда Сәйф Сараи Мисырга күченеп китә. Аның бәхетенә, Алтын Урданың чәчәк аткан чорында гарәп илләре, аеруча Мисыр мәмлүкләре белән илчелек мөнәсәбәтләре урнашкан, илләр арасында сәүдә җайга салынган була. Тарихчылар, Сәйф Сараины Мисырга йә илчеләр, йә сәүдәгәрләр ияртеп алып киткән, дип фаразлый, чөнки ул биредә Мисыр солтаны Заһир Сәйфетдин Бәркүкнең лаеклы хөрмәтенә ирешә, солтанның канцеляриясендә эшли. Сәйф Сараи фарсы, гарәп, төрки телләрне яхшы белә, күренекле галимнәр белән аралаша, бүгенге төрки һәм гарәп дөньясына мәгълүм булган «Гөлестан бит-төрки» әсәрен Мисырда яза. Шушында ук Туктамыш хан белән Аксак Тимер сугышларына турыдан-туры караган бөек әсәрен – «Сөһәил вә Гөлдерсен»не иҗат итә.

«Солтан Заһир Сәйфетдин Бәркүк үзенең хөрмәтле галимнәрен үзе янына күмүне васыять итеп калдырган. Бу турыда безгә Каһирә профессоры әйтте. Сәйф Сараиның кабере солтан каберлегендә булырга мөмкин, дигән фараз бар. Каберлек, андагы ташлар да ярыйсы хәлдә сакланган. Аларны Каһирәгә барып өйрәнергә кирәк. Мисыр архивларында һәм китапханәләрендә эзләнеп, Сәйф Сараи һәм, гомумән, Алтын Урда белән бәйле яңа ачышлар ясарга мөмкин», – ди И.Миргалиев.

Сәйф Сараины без урта гасыр татар шагыйре дип беләбез. Кыпчак телле башка халыклар да аны үзенеке дип таный. Башлыча, татарлардан күреп, казахлар, үзбәкләр якын итә башлады. Шулай да, Сәйф Сараины өйрәнүгә татар галимнәре нигез салды. Аны танытуда тел галиме Хатыйп Миңнегуловның, тюрколог Әмир Нәҗипнең, археолог Равил Фәхретдиновның өлеше зур.

Сәйф Сараиның туган урыны дип, Самара өлкәсе белән Татарстан чигендә урнашкан Камышлы авылы билгеләнде. Үзенең әсәрләрендә ул Идел-йортта, Камышлыда туганын күрсәтә, шуңа күрә Сәйф Сараины, шикләнмичә, татарныкы дип әйтә алабыз.

«Сәйф Сараины өйрәнеп, урта гасырларның сәяси тарихын күзалларга мөмкин. Туктамыш, Аксак Тимер, Бәркүк – барысы Сәйф Сараиның чордашлары. Бу чорда Алтын Урда җимерелә. Моның төп сәбәпләрен аңларга кирәк. Кызганыч, безгә ул заманнан тарихи кыйпылчыклар гына килеп җиткән. Без шулардан тулы картина төзергә тырышабыз. Булган кыйпылчыклар илдә җитди сәяси процесслар барганын күрсәтә. Телне куллана белү, мәдәният, фән үсеше – бөтенесе булган. «Сөһәил вә Гөлдерсен» әсәрендә Туктамыш белән Аксак Тимер сугышы да, мәхәббәт дә, ватанпәрвәрлек тә бар. Ягъни, зур булмаган бер әсәрдә төрле темалар бик оста ачыла.

Бәркүк солтанның каберлеге исән. Ул шактый зур һәм яхшы сакланган. Бәркүк безгә ни өчен мөһим? Ул Туктамышның союзнигы була, Алтын Урда тарафдары буларак, Аксак Тимергә каршы сугыша. Аның янында Сәйф Сараи да эшли.

Без Мисырда Бәркүкнең ике комплексын барып күрдек. Беренчесе – сөт әнисенеке. Солтан ул урынны бик яраткан, анда еш кына барып, догалар укый торган булган. Икенчесе – үзе күмелгән урын. Ул бик зур. Сәйф Сараи да шунда күмелгән булырга мөмкин.

Алтын Урда тарихын тирәнрәк белү өчен Мисыр мәмлүкләрен дә өйрәнергә кирәк, чөнки Алтын Урдада ислам дине кабул ителгәннән бирле, ханнар белән мәмлүк солтаннарын дуслык кына түгел, туганлык җепләре дә үзара бәйләгән. Урта гасырларда ике ил җитәкчеләре арасында кыз алышу традицияләре булган. Алай гына да түгел, мәмлүкләрнең бер өлеше – безнең яклардан чыккан кыпчаклар икәне мәгълүм. Мәмлүкләр көчле сугышчы булган. Алар хәтта «Тәре походы»н туктата алган. Мәмлүкләр хакимлек иткән чорда фән, мәдәният алга киткән. Безнең галимнәр аларга барып укыган, ә Мисыр үз мәдәниятен Алтын Урдада җәелдерергә тырышкан. Безгә туры килә торган традицион исламның чишмә башы Мисырдан. Бүген дә дин белгечләребезнең Мисырда укып кайтуы очраклы түгел».

Рифат КАЮМОВ.
Эльмира Сәйфетдинова фотолары.

ГЕНЕРАЛ

(Дәвамы. Башы 48 нче санда).

Жуков яуга һәркайсының башында генерал-лейтенантлар торган 1 нче удар (башлыгы В.Кузнецов), 5 нче (Л.Говоров), 10 нчы (Ф.Голиков), 16 нчы (К.Рокоссовский), 20 нче (А.Власов), 33 нче (М.Ефремов), 43 нче (К.Голубев), 49 нчы (И.Захаркин), 50 нче (И.Болдин) армияларын һәм шулай ук генерал-лейтенант П.Белов командалыгындагы 1 нче гвардия кавалерия корпусын әзерли. Калинин фронты 29 нчы (генерал-майор В.Швецов) һәм 39 нчы (генерал-лейтенант И.Масленников) армияларны, алардан тыш полковник С.Соколов җитәкчелегендәге 11 нче кавалерия корпусын ташларга әзерләнә. Генштаб мондый көчне дә азсына һәм Ставка резервыннан генерал-майор А.Левашев кул астындагы 4 нче һава десанты корпусын да кушып куя. Болардан тыш, регуляр гаскәргә сугышчыларының гомумсаны белән 8 меңнән артык исәпләнгән партизан отрядлары да ярдәм итәргә тиеш була. Бер уйласаң, немецларның 3-4 армиясына каршы 14-15 сугышчан берләшмә, мондый очракта инде «бүрек ыргытып та иярләреннән бәреп төшерәбез», дип шапырынырга да була.

Беренче булып, һөҗүмне 1942 елның 8 гыйнварында Калинин фронты гаскәрләре башлый, ләкин алардагы сүлпәнлек Ставканың ачуын гына кузгата, күрәсең, икенче көнне үк аларга ярдәмгә тагын Төньяк-Көнбатыш фронт карамагындагы 3 нче һәм 4 нче удар армияларны да ташлыйлар. Шуннан соң гына Калинин фронты сугышчылары Оленин каласы янында дошман гаскәрен камалышка алуга ирешә һәм төп ударны Сычевка бистәсенә юнәлтә.

10 гыйнварда Көнбатыш фронт гаскәрләре дә һөҗүмгә ташлана һәм Можайск, Верея, Медынь, Киров, Людиново, Сухиничи шәһәрчекләрен азат итә. Бу яктан да өч армия һөҗүмне Сычевкага юнәлтеп, дошманның шактый зур төркемен чолганышка алырга исәпли. Тагын бер ыргылсалар, ике һөҗүм итүче төркем бергә кушылыр, аннары Ржев каласын камалышка алыр кебек тоела. Ләкин нинди максат беләндер, Сталинның шәхси фәрманы буенча, генерал В.Кузнецов җитәкләгән 1 нче удар армияны яудан чыгаралар да Демянск каласы янына озаталар. Рокоссовский белән Голиков армиялары әүвәл Киров шәһәрен яулап алырга, аннары Вязьма белән Брянск арасындагы тимерьюлны үз кулларына төшерергә тиеш була. Берләштерелгән ике армия көчләре Киров шәһәрен азат итүгә дә ирешә, ләкин 11 гыйнварда ук немец гаскәрләре аларны кабат Кировтан бәреп чыгара. Әзәрлекләүләргә каршы тора-тора, Рокоссовский үз армиясын Сухиничига таба, ә Голиков 10 нчы армияны Людиновога алып китә. Алар фәкать 29 гыйнварда гына әлеге калаларда ныгып урнаша.

Көнбатыш фронтның Власов, Ефремов һәм Говоров җитәкләгән армиялары үзәктән, Мәскәү ягыннан һөҗүм итеп, дошман оборонасын өзәргә ниятли. Медынь белән Износок калалары арасында фашист гаскәрләре бикләп өлгермәгән 40 чакрымлы бер ара да табыла. Фронт башлыгы Жуков 19 гыйнварда шул арага 1941 елның ноябрь ахыры һәм декабрь айларында Нарофоминск юнәлешендә җиңүгә ирешкән, данлы генерал-лейтенант Михаил Ефремов кул астындагы 33 нче армияне ташларга һәм Вязьма каласын яулап алырга фәрман бирә. Нарофоминск ягыннан кергән Ефремов алда бернинди күпер һәм юллар да юклыгы, гыйнварның зәмһәрир салкыннарында билдән көрт ерып һөҗүм ясап булмаячагы, ахыр чиктә үз армиясенең капчыкка эләгәчәге турында кисәтеп тә карый, әмма җавап катгый: «Өмер үтәмәгәннәргә – трибунал!»

Вязьма – сугышка чаклы 40 мең кеше гомер итсә, хәзер инде 7 мең генә адәм баласы яшәп ятучы кала. Аның исән дип саналырдай һәм игътибарга лаек кирпеч йортлары да 57 генә. Шушы каланы совет ягына кайтарырга кирәк.

Ефремов сугышчылары шул ук көнне Верея каласын яулап ала да Вязьмага таба ыргыла, тик алар да калага 6-7 чакрым ераклыкта бетон дотларга төртелеп туктала.

Ефремов, Власов һәм Говоров армиялары 14-22 гыйнварлар арасында Дорохово, Руза, Можайск, Уваровка кебек вак шәһәрчек яки бистәләрне генә азат итүгә ирешә, аннары Васильково тимер юл үзәген әләктерергә тиеш була. Ләкин Семеновское авылы янындагы «Үлем үзәнлеге»нә эләгеп, дистә меңәрләгән совет солдаты кырыла. Өч армия да ике яктан да ут астына эләгә һәм һичбер тарафка да хәрәкәтләнә алмый.

Бизмәннәргә салсаң, немец гаскәре һич оттырмый кебек, ләкин кайбер калаларны югалту Гитлер тарафыннан бик усал бәяләнә. 15 гыйнварда ул ашыгыч фәрман буенча ике генерал-полковник Э.Гепнер белән А.Штраусны постларыннан алып ташлый да, генерал-полковник Вальтер Модельны 4 нче танк армиясына да, 9 нчы кыр армиясына да башлык итеп куя. 20 гыйнварда генерал Кюбнер да 4 нче кыр армиясын Г.Хейнрицига тапшырырга мәҗбүр була. Ә яңа командующий Модель әллә кайдан резервлар китертеп, Ржевка таба юнәлтелгән һөҗүм юлларын кисә. Совет гаскәрләре ягыннан әүвәл 29 нчы армия белән 11 нче кавалерия корпусы чолганышта кала. Аннары Ефремов үз армиясын 26 гыйнварда Вязьманы азат итү өчен һөҗүмгә ташлап караса да, немецларның ике яклап, кайчы рәвешендә ясалган контрһөҗүменнән соң, 33 нче армия фронт сызыгыннан бик ерак арада дошман чолганышында кала, ә 1942 елның февралендә бу армия азык-төлек һәм боеприпаслар белән тәэмин ителүдән дә тулысынча өзелә.



Ржев-Вязьма операциясен тасвирлаучы хәрби карта.

Немецлар Кызыл Армия ташлап чигенгән совет шәһәре урамнарында.

Гомумән, Ржев-Вязьма казанына эләккән совет гаскәрләрен азат итү җиңел бурыч булмый. Ржевны үз кулларына эләктереп, анда Гитлерның иң яраткан һәм ышанычлы генералы Вальтер Модель үз штабын булдыра. Аны казанга эләккән совет гаскәрләре ягыннан да, Тверь каласы тарафындагы һөҗүмнән дә танк корпуслары саклап тора. Вязьмада немец генералы Артур Шмидт үз өендәгедәй ныклап урнаша. Немецлар Брянск-Вязьма казанында әсирлеккә эләккән 650 меңгә якын совет тоткыннарын тимерьюллар аша Германиягә куып та азапланмый. Алар өчен Вязьма читендә 80-100 мең тоткын сыешлы концлагерьлар төзеп куялар. Әсирләр гыйнвар салкыннарында да ап-ачык кырда, җәһәннәм газаплары чигеп җан асрый яки туктаусыз кырыла бирә...

Ул арада Гитлер генераллары Вязьма божрасына 6 өстәмә дивизия туплап өлгерә. Февральнең беренче көннәрендә үк һөҗүмгә күчеп, алар 29 һәм 39 нчы армияләрне тулысынча бер-берсеннән аера һәм чолганышка ала. Вязьмага 7-8 чакрымда туктап калган Ефремовның 33 нче армиясе дә 3 февраль төнендә фашистлар ясаган кискен һөҗүм нәтиҗәсендә Мончалово һәм Окороково авыллары арасындагы «капчык»ка кереп каба...

Урамда утыз градустан да түбәнрәк салкын. Совет гаскәре фуфайкаларга гына «төренгән», урман эчендә вакытлыча казылган окоплардан күпләр иртә белән инде йокыдан тора алмый. Күпчелек кызылармеецлар кулында – Октябрь инкыйлабына кадәр үк чыгарылган Мосин винтовкалары. Аларга яраклы патрон, сөйрәп керткән туплар өчен снаряд юк. Үз армиясенең котылгысыз һәлакәткә таруын аңлап, генерал Ефремов фронт башлыгы Жуковтан, чолганыш чылбырын өзеп, кире совет гаскәрләре ягына чыгарга рөхсәт сорап карый. «Без камалышта калдык, яуны дәвам итү өчен боеприпаслар да, солдатларны ашатырдай азык-төлек тә юк», ди-ди гозерләүгә каршы Жуков Ефремовның яңагына чалтыраткандай кансыз җавап бирә:

– Дошман территориясенә бәреп кергән чакта итәгеңне җыеп йөр, тылың турында кайгырта бел идең.

– Үзегез бер адым да артка борылмаска, дигән фәрман белән алга кудыгыз бит, – дип Ефремов акланырга мәҗбүр була. Ә Жуков тарафыннан салкын корыч төсле усал җавап:

– Хәзер дә шул ук фәрман – бертуктаусыз алга! Солдатларны чолганышта калган авыл халкы хисабына ашат. Көз көне чигенгән чакта безнең гаскәрләрнең ташлап калдыруы мөмкин, патрон белән снарядларны да шул мәйданнан эзлә!..

Чарасыз калган Ефремов, инде фронт башлыгы өстеннән сикереп, турыдан-туры Сталинның шәхсән үзенә телеграмма суга. «Халыклар атасы»ннан «ярдәмнән ташламабыз» дигән шома гына җавап, ә Жуковтан утлы, кайнар камчы:

– Әлегә мин фронт башлыгы! Ә чолганышка эләгүгә син үзең гаепле!..

Ефремов та, ул вакытта окопларда кан коя-коя сугышучы һичбер кеше дә белми. 28 гыйнвар кичендә Жуков, гәрчә һичкем тарафыннан сораучы булмаса да, генерал Ефремовка сугышчан бәяләмә язарга утыра, аны фронт башлыгы (ягъни, Жуков) киңәшеннән башка командный

● Дошман техникасы.

ЕФРЕМОВ ФАҖИГАСЕ

● Генерал-лейтенант Михаил Григорьевич Ефремов.

● Генерал Михаил Ефремов һөҗүм алдыннан.

пункт та сайлый белми торган булдыксыз һәм хәрби берләшмәләр белән җитәкчелек итүгә яраксыз генерал дип бәяли, шушы шикаятьне Генераль штаб башлыгы Шапошниковка юллый. Әлеге донос папкасы хәрби архивта Бөек Җиңүдән соң 50 ел үткәч кенә ачыла...

Ни үкенеч, генерал Ефремов үзенә нинди үлем карары әзерләнеп ятуын әле белә алмый. Һәрбер ватанпәрвәр командир шикелле, ул да сугышчыларын яңадан-яңа һөҗүмгә куаларга мәҗбүр була. Һичьюгы камалыштагы өч гаскәр берләшсәк исән калмабызмы, дигән өмет белән Ржев ягындагы 29 нчы армия башлыгы В.Швецов белән генерал Белов корпусын да үзенә кушылырга чакырып карый. Ләкин Жуков тарафыннан Беловка да камчы сыман фәрман:

– Ефремов белән кушылырга һичбер рөхсәтем юк! Сез дошманны аерым-аерым юк итәргә тиеш, алга, алга!..

Гәрчә шул ук вакытта Калинин фронты башлыгы генерал Конев февраль аенда тулысынча камалышта калган 29 һәм 39 нчы армия башлыклары Швецов белән Масленниковка бернинди югалтулар белән хисаплашмыйча үзебезнең якка чыгарга әмер бирә. 28 февраль көнне 29 нчы армиянең соңгы сугышчысы камалыштан чыга. Санап карасалар, элек җиде дивизияне хасил иткән армиядән сыңар дивизиянең яртысы – 5200 солдат кына исән калган, аларның да 800 е тоташ канга баткан...

Совет командованиесе шул ук 18 февральдә дошман тылына 7400 гә якын десантчыны самолетлар ярдәмендә ташлый, алар 50 нче армияны коткару өчен аларга таба хәрәкәтләнә башлый. Тик немец авиациясе һәм чаңгылы роталар һөҗүме аркасында көрт эчендә траншеялар казып урнашырга һәм оборонага күчәргә мәҗбүр булалар.

Генерал Белов җитәкчелегендә чолганышта калган кавалерия корпусын коткармакчы булып, көнбатыштан 50 нче армия һөҗүмгә күчә, тик файдасыз. 33 нче армияны коткару өчен 43 нче армия сугышчылары, тар гына коридор ясап булса да, алар белән уртасында Ефремов Ставкадан чолганышны өзеп үзебезнекеләр ягына чыгарга рөхсәт алуга ирешә. Әле анда да иң якын арага – Мәскәү ягына түгел, фәкать Тверь каласына таба хәрәкәтләнергә дигән фәрман тапшыралар. Ул калага чаклы ике йөз чакрым ара. Ефремов, әлбәттә, ач-ялангач солдатларны андый озын һәм киртәле тыл буйлап исән-имин алып чыга алмаячагын яхшы аңлый. Ләкин чолганышка «эләккән» генерал белән санлашып торучы булмый...

33 нче армия кебек үк чолганышта калган 39 нчы армия белән 11 нче кавалерия корпусы 1942 елның июль уртасына кадәр дошманга бирелмичә йөри, әмма шул көннәрдә алар да тулысынча кушылырга омтылып карый, тик февраль һәм март айлары буена сузылган бу тырышлык та нәтиҗә бирми...

Ефремов армиясе чолганышка эләгүгә икенче ай бара, яз бик иртә килә. Киез итек киеп кергән сугышчылар март суларына бата-чума газап чигә башлый. Һәр көн диярлек камалыштагы совет гаскәрләрен дошман самолетлары «үтүкли», күктән махсус рәвештә тишелгән мичкәләр ташлап та солдатларны өнсез калдыралар. Бомбага тотканнан соң яки бәрелешләрдә яраланган сугышчыларны Быково дигән авылда медсанбат төзеп туплыйлар, аларның һәммәсен тиң шул ук фашист самолетлары җир белән тигезли...

Апрель башына 33 нче армиядән санаулы гына сугышчылар торып кала, алары да ач һәм шыр-ялангач. Ниһаять, апрель юк ителә. 39 нчы армия башлыгы И.Масленниковны махсус самолет ярдәмендә коткаралар, ә аның урынбасары генерал-лейтенант И.Богданов чолганышта калып һәлак була. Совет сугышчыларын коткару өчен казанга кертелгән 4 нче корпусның десантчылары һәм генерал Белов кул астындагы атлы җайдаклар бик аз күләмдә исән калып, 1942 елның 24 июнендә 10 нчы армия белән кушыла...

Ржев-Вязьма операциясе барышында, 1942 елның 1 гыйнварыннан 30 мартка кадәр арада «Үзәк» армияләр группасы – 330 меңнән артык, совет гаскәрләре 777 меңгә якын солдат югалта. 33 нче армия февраль, март һәм апрель айларында дошманның 24 танкын, 29 тубын, 8700 чамасы солдат һәм офицерын юк итә. Ләкин үзләреннән дә совет гаскәрләре ягына җан саклаган көе 889 солдат һәм офицер гына чыгып кушыла... 4 айга сузылган бу яу барышында совет гаскәрләре дошманны 80-250 чакрым арага көнбатышка таба чигендерүгә һәм Тула белән Мәскәү өлкәләрен тулысынча, ә Калинин белән Смоленск өлкәләренең кайбер районнарын баскыннардан азат итүгә ирешә. Ржев-Вязьма катастрофасы бүгенгә кадәр Кызыл Армия командованиесенең иң хурлыклы оттырышы булып санала...

Ржев-Вязьма операциясе 1942 елның 20 апрелендә генә тәмамлана. Ләкин югарыда сабак алучылар табылмый, күрәсең. Нәкъ менә шушы 20 апрель көнне Вязьма янындагы казанда җиңелү кичергән генерал-лейтенант Андрей Власовны инде өр-яңа «капчыкка» – чолганышта калган Волхов фронтына, 2 нче удар армия башлыгы итеп озаталар. Хәтта бүген дә иң көчле бронетранспортерлар ерып чыга алмаган сазлыкта совет гаскәрләре бернинди уңышка да ирешә алмый. Фронттагы 390 мең солдат һәм офицерның 32 меңгә якыны гына Мясной Бор авылы янында хасил булган «шешә борыны» аша исән чыга ала. 33 мең солдат, шул исәптән Муса Җәлил дә дошман кулына әсирлеккә төшә. Генерал Власов 11 июльдә немецлар ягына чыгып бирелә һәм үз теләге белән Гитлерга хезмәткә яллана. 1945 елның апрелендә Прага янында татар каһарманы, «Кара генерал» Даян Мурзин партизаннарының кулына эләгеп, Власов совет суды каршына баса. 1946 елның 1 августында ул гомерен дар агачында тәмамлый...

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Мәдәни җомга
15 декабрь
№49, 2023

Михаил Худяков китабыннан өзекләр

(Ахыры. Башы 8-9 битләрдә).

Урыс машлары бураларының һәм чатырларының пропорцияләре тупасрак булуы белән мәчет манараларыннан аерылып тора. Бу хәл аларның мәчетләр үрнәгендә ясалуын дәлилли – урыс осталары күчереп ясаганда мәчетләрнең көяз пөхтәлегенә ирешә алмаган. Профессор Голубинскийның чатырлы машлар белән йорт өсләрендәге теремнәр арасында охшашлык табуы исә урысларның теремнәрны да татарлардан кабул итүләреннән килә. Чыннан да, борынгы урыс теремнәры татар йортлары өстендәге пыяла тәрәзәләр куеп ясалган кечкенә өйчек-тирмәләргә, якты бүлмәләргә, янәшә торган йортларны өстән тоташтырып торган түбәле юлларга бик нык охшаган. Хатын-кызларны теремдә бикләп саклау гадәте үзе дә урысларга татарлардан кергән. Шулай итеп, бу архитектура шәкеленең урыс төзү сәнгатендә пәйда булуына китергән сәбәп тә Шәрекъкә ишарәле.

1529-1562 елларда түбәндәге чатырлы таш гыйбадәтханәләр төзелгән: Дьяков авылы чиркәве (1529), Коломенски авылындагы Вознесенски чиркәве (1532), Новгородта Хутын монастырендагы изге Григорий чиркәве (1536), Мәскәүдәге Василий Блаженый гыйбадәтханәсе (1555-1562), Мәскәү кремлендәге Богоявленски монастырендa изге Сергей чиркәве (1557) һәм Старица шәһәрендәге агач гыйбадәтханә (1558-1561). Коломенски авылындагы Вознесенски чиркәве кайбер яклары белән фарсы архитектура ядкярләренә тартым икәнен соңгы вакытта профессор Б.П.Денике әйткән иде. Елъязма бу чиркәү турында: «Бик гаҗәеп дәрәҗәдә биек тә, матур да, якты да – моңарчы Русиядә мондыйларның булганы юк иде», – дип яза (ПСРЛ, VIII с. 279). Хутын монастырендa Тверь остасы Ермила төзегән чатырлы чиркәү хакында да елъязма: «Мондыйлар Новгород өлкәсендә юк – күрер күзгә бик тә гүзәл һәм шәп», – дип хәбәр итә (ПСРЛ, VI, с. 296). Күрәсең, урыслар төзү сәнгатендә мөселман шәкелләре пәйда булуны таң калып һәм сокланып каршы алганнар. Шәрекъ йогынтыларына тормышта урын бирүче һәм, гомумән, модаларга иярүче кеше бөек кенәз Василий III үзе була. Ул Мәскәү янындагы ике күрше авылда (Коломенски белән Дьяков) чатырлы чиркәүләр салдырган һәм мондагы үз утарында гомер уздырырга яраткан.

Урыс архитектурасына татарлар ясаган йогынтының таҗы дип Казанны алу хөрмәтенә Мәскәүдә салынган Василий Блаженый соборын әйтергә кирәк. Бу гыйбадәтханәнең төзелүен елъязма: «Төрле үрнәкләр һәм күчермәләр кулланып таштан гыйбадәтханә салынды», – дип хәбәр итә. И.Е.Забелин аңлатуынча, «күчермә сүзе безнең борынгы сәнгатебездә сурәтне, нинди дә булса үрнәктән (оригиналдан) алынган копияне белдергән... бу инде гыйбадәтханәне төзегәндә художниклар мәгълүм үрнәкләрдән файдаланган дигән сүз» (Забелин. «Черты самобытности в др. рус. зодчестве», с. 11). Василий Блаженыйны салганда үрнәк булып хезмәт иткән оригинал турындагы мәсьәләне әле һаман тулысынча чишелгән дип булмый. 1871 елда И.Е.Забелин бу гыйбадәтханә белән Дьяков һәм Коломенски авылларындагы чиркәүләр арасындагы охшашлыкны ачыкласа да, эш шуннан ары китмәде, чөнки әлеге чиркәүләрнең төзелү тарихы шулай ук караңгы иде. И.Е.Забелинның чатырлы машларны үзләре иҗат иткән дигән фаразы бүгенге көнгә тиклем мәшһүр булып кала килде. Ләкин бу фаразны исбатланган дип әйтү мөмкин түгел. Киресенчә, Казан татарларының төзү сәнгате бу фаразга каршы кайбер дәлилләр бирә һәм Василий Блаженый гыйбадәтханәсенең төзелү тарихына яңа бер нур сирпи ала.

Хикмәт шунда: бу гыйбадәтханәнең иң якын тиңдәшен нәкъ менә казаннар сәнгатеннән күрсәтергә мөмкин. Василий Блаженый үзенең архитектурасы белән, барыннан да элек, Казандагы 8 манаралы Кол Шәриф мәчетен хәтерләтә (бу мәчет хакындагы риваятьне Мәрҗани язып алган). Василий Блаженыйның үзәк чатыры тирәсенә урнаштырылган һәм Шәрекъкә хас гөмбәзләре булган 8 манарасы әлеге мәчетнең 8 манарасында искиткеч тәңгәллек таба. Шулай итеп, Мәрҗани теркәп калдырган риваять читләтеп булса да раслана. Ә без әлеге 8 манараның ничек урнашкан булуын якынча булса да ачыклый алабыз. Биналарның төп фасады (алгы ягы) аерып куелмау – татар архитектурасының үзенчәлекле сыйфаты. Бу сыйфат Василий Блаженыйга да хас. Аны салу эше җиңелгән Казан каласында таш кальга төзи торган Посник Яковлевка тапшырылуы да юкка түгелдер, ул Казан архитектурасы белән якыннан танышу мөмкинлегенә ия булган.

● **Казан каласының соңгы сакчылары. Фиринат Халиков картинасы.**

Әгәр мондый фараз раслана калса, гыйбадәтханәне төзү идеясе яңа һәм бик тирән эчке мәгънәгә ия булып чыгачак. Казан ханлыгын яулау хөрмәтенә салынган чиркәүнең мөселман архитектурасы сыйфатларына ия булуы һич тә очраклы түгел икәне ачылыр. Урыс хөкүмәте, Мәскәүгә китереп кушкан өлкәләрдәге иң мөкатдәс җирле ядкярләрне башкалага күчергәне сыман, Казанның баш мәчетен Мәскәүгә күчереп, татар дәүләтен буйсындыруын аермачык әйтеп биргән. Митрополит Макарийның хөкүмәте, Җәмигъ мәчетенең шәкелен христиан гыйбадәтханәсе рәвешендә кабатлаган, мөселман мәмләкәтенең христиан державасына буйсындырылуын шушы бинада гәүдәләндергән; гүя дә мөселман сәнгатен христиан диненә йомышын үтәргә мәҗбүр итүе белән ул татар Көнчыгышын Русиягә кушуны чагылдырган сәяси-эстетик идеяне гамәлгә ашырган. Урысларның төзү сәнгате тарихчылары бу гыйбадәтханәдә митрополит Макарий башында туган ниндидер бер идея яшеренгәнлеген чамалыйлар иде. Мәсәлән, И.Э.Грабарь менә нәрсә яза: «Бик тә дини галим буларак һәм сурәтләр вә чагыштырулар белән фикерләүче иҗатчы буларак, митрополит Макарий патшага таштан гыйбадәтханә салырга киңәш бирә. Василий Блаженый храмындагы престолларның ничек урнаштырылганын күргәч, уйлар туа: чиркәүнең төзелү рәвешендә «нигезләр үлчәнеше» генә салынмаган, бәлки осталар Барма белән Посниктан һәм аларның иптәшләреннән гайре дә төзү эшенә тагын кемдер катнашкан, һәм аның катнашлыгы шул дәрәҗәдә ки, ул төзүчеләрне җитәкләүче идеянең иясе булган, һәм елъязмага теркәлеп исемнәре сакланып калган Барма белән Посник нибарысы «мондый гаҗәеп эшкә кулай вә сәләтле» кешеләр генә булганнар» (И.Э.Грабарь, История русского искусства, вып. 5, с. 38). Бу фаразлар, күрәсең, хәзер раслана, һәм әлеге гыйбадәтханәне салганда митрополит Макарий илһамланган кыю, оригиналь ниятләрне хәзер аңлатырга җай туа.

Василий Блаженый гөмбәзләренең шәрекъчә икенлеге күренеп тора, ләкин, кызганычка күрә, моның хикмәтен тулысынча аңлату мөмкин түгел, чөнки Казан архитектурасында түбәләрнең нинди булганлыгын без белмибез: Казан архитектура ядкярләре сакланмаган, Болгардагы ярымшар рәвешендәге таш гөмбәзләрнең агач өлекләре шулай ук юкка чыккан, Касыймдагы Хан мәчете манарасының түбәсе, Болгардагы, Кече манара гөмбәзе сыман ук, соңгы дәвердә ясап куелган, борынгы заманда да шулай булуына ышану кыен. Мәскәү архитектурасында башлы суган рәвешендәге шәрекъчә гөмбәзләрнең нәкъ менә XVI йөздә ишәеп китүен һәм аларның мөселман сәнгатеннән килгәнлекләре шик уятмавын истә тоткан чакта, бу югалту өчен тагын да ныграк ачынырга туры килә.

Татар сәнгатенең төсләр чуарлыгы (полихромия) кебек үзенчәлекле сыйфаты ул чорның урыс архитектурасында шулай ук кулланылыш тапкан. Мәскәү архитектурасында нәкъ менә шул дәвердә стеналарны төрле төсләргә буяу киң тарала. Татарларның яраткан яшел һәм сары төсләре Дьяков чиркәвенең бизәлешендә дә, Василий Блаженый гыйбадәтханәсенең нәкышләрендә дә күренекле урын тота. Ул гыйбадәтханәнең чатырындагы чынаяк кирпечләр дә яшел һәм сары төстә. Төсләрнең татарча чиратлашуына анда тагын кызыл төс – кирпечнең табигый төсе дә килеп кушылган, урысларның кызыл кирпече татар сәнгатендәге ак ташны алыштырган.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе

Борынгы җәмгыятьнең серләрен туганлык терминнары ярдәмендә ачарга тырышу көтелгән нәтиҗәләрне бирә алмады дип әйтергә туры килә. Л. Морганның «Борынгы җәмгыять» дип аталган атаклы хезмәтенең басылып чыгуына инде йөз елдан артык вакыт үтсә дә һәм Морган карашларын бик күпләр якласа да, борынгы җәмгыять, борынгы кеше, борынгы семья мәсьәләләренең әле һаман тулысынча һәм дөрес хәл ителгәне юк. Алай гына да түгел, Морганның карашларын яклаучылар да аның кайбер фикерләренең ялгыш булуын танырга мәҗбүр. Мәсәлән, Морган «туганлыкның малайа системасы» дигән термин куллана һәм мондый туганлык иң борынгы семья формасын чагылдыра дип исәпли. Ләкин, тикшереп карагач, нәкъ киресе килеп чыга – «малайа системасы»ндагы семья гаилә үсешенең соңгырак чор формасына карый икән. Җитмәсә, малайа халкында «малайа системасындагы» гаилә системасы гомумән юк икән.

Нурихан ФӘТТАХ

Хатын-кыз турында борынгы карашлар

Моннан йөз ел элек телнең-сүзнең төзелеше һәм аның ничек барлыкка килүе билгеле булмаган кебек, ул хәзер дә билгеле түгел. Телне-сүзне аңлауда тел гыйлеме тәкъдим иткән метод ярдәмендә телнең төзелешен, чыгышын, табигатен дөрес аңлатып булмый. Шулай булгач, тел байлыгының бер тармагы булган туганлык терминнарының мәгънәләрен аңлатуда да тел гыйлеме методы ышанычлы метод була алмый. Әгәр без туганлык терминнары сыйфатында кулланыла торган сүзләрнең иң әүвәлге мәгънәләрен белмибез икән, ничек итеп билгеле булмаган нәрсә ярдәмендә борынгы җәмгыятьнең серләрен аңлатмак кирәк соң?!

Иҗек методы принципларыннан чыгып хөкем йөрткәндә, туганлык терминнары да башка барлык сүзләр кебек ясалган. Мәсәлән, туганлык термины КЫЗ да – Ана улы, КИЛЕН дә – Ана улы, МАЛАЙ – Ата улы һәм шулай ук ЙЕГЕТ (ЖЕГЕТ) сүзе дә – Ата улы.

Ягъни, барлык туганлык терминнары да дип әйтерлек бер үк төрле калыпта «сугылган». Шуңа күрә борынгы җәмгыятьне аңлауда туганлык терминнары гына әлләни күп мәгълүмат бирә алмас дип исәплибез. Безнеңчә, эзләнүне башкачарак юнәлештә алып барырга кирәк.

Билгеле булганча, Ана, хатын-кыз Җир белән, Ата һәм ир кеше – Су-Күк белән тиңләштерелә. Мифлар һәм легендалар буенча, Җир ул – ана җылан, Су-Күк – ата җылан. Ата җылан сугышчы һәм үтерүче, Ана җылан исә – тудыручы һәм ашаучы.

Татар халык әкиятләрендә башлыча хатын-кызның җыланлыгы турында сүз бара. Бу хакта К.Насыйри болай дип яза: «Юха елан, кызга әйләнгәч, кияүгә бара ала, берәр кешенең хатыны да була ала. Шунысы кызык, юха кызның ире аны бик нык сөя, ләкин үзе һаман ябыга, кибә бара... (Юханың кияүгә баруының төп максаты – ирен ничек итеп булса да йоту).

«Ярлы егет белән юха елан» дигән әкияттә нәкъ менә шундый хәл тасвирлана: юха кыз үзенең киявен ябыктыра. «Кыз яхшы гына йөри, ә егет көннән-көн кибә, саргая» диелә әлеге әкияттә. «Өч каләм» дигән әкияттә дию кулыннан коткарылган кыз – егетнең хатыны, унбер иренең башын кистерep, сарайга элеп куйган. Хатын бу иренең дә (егетнең дә) башын чаптырып, «җир йөзенә патша» булып калмакчы була. Әкияттә шулай ук хатынның үз ирен ашаучы булуы чагыла.

Геродот скифларның килеп чыгышы турында шундый легенда сөйли: борынгы грекларның мифик герое Геракл, югалган атларын эзләп, скифлар җиренә, Гилея дигән илгә килеп чыга. Тау куышында ул ярым җылан, ярым адәм кыяфәтле бер кыз күрә. Кызның гәүдәсенең өске өлеше – кешенеке кебек, аскы өлеше җыланныкы кебек була. Геракл кыздан: «Минем атларымны күрмәдеңме?» – дип сорый. Җылан-кыз әйтә: «Атларың миндә. Әгәр минем белән кавышсаң, атларыңны бирермен», – ди. Ләкин Геракл аның белән кавышкач та, ул атларны бирергә теләми. Монда җылан-хатынның ашаучы, үтерүче булуы турында әйтелми, шулай да ул Гераклны көчли дип әйтергә була.

Сагайларның ышануынча, тау иясләренең кызлары аучыларны алдап алып китә дә, имеш, үзләренең ирләре итә. Тау иясенең кызы аучыны үтергәч кенә, имеш, аучы аның ире була ала.

Маориларның бер мифында Мауи исемле ярым алланың үлем алиһәсе Хинаны үтерергә тырышуы турында әйтелә. Бервакыт Мауи, аяк-кулларын җәеп җирдә йоклап яткан үлем алиһәсе Хинаны очрата. Мауи янында кечкенә кошлар да була. Мауи кошларга пышылдап: «Сез шауламагыз, мин Хинаны үтерәм», – ди. Моның өчен ул Хинаның гаурәтеннән кереп, авызыннан чыкмакчы була һәм шуның белән үзенә үлемсезлек яуларга тели. Ул чыннан да керергә ниятләгән җиренә кереп китә, тышкы якта аның аяклары гына торып кала. Карап торган кошларга бу бик көлке тоела һәм бер кечкенә кош көлеп җибәрә. Хина уяна, ботларын кыса һәм Мауины сытып үтерә. Мауи үзенә дә, башкаларга да үлемсезлек яулап алмый.

Молук утрауларындагы вемале телендә үлем алиһәсе һәм шул ук вакытта үрчем символы Мулуа Сатене дип атала. Димәк, бер үк алиһә тудыра да, һәм шулай ук үтерә дә! Кем соң ул? Алиһә исеме иҗекләр дәрәҗәсендә уңай тәртиптә, аерым сүзләр дәрәҗәсендә кире тәртиптә ясалган. Мулуа: Му – луа (улы); Сатене: Сате – не. Су-Күк улы Ана. Алиһә исеме тулаем улы Ана дигәнгә туры килә. Шулай итеп, үрчем һәм үлем алиһәсе Ана улы, ягъни vulva булып чыга.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

15 декабрь – Шәрык клубында – «Безнең шәһәрнең серләре» спектакле (Г.Камал) һәм театральләштерелгән экскурсия. Зур залда – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Бүләков). Кече залда – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
16 декабрь – Зур залда – «Санаулы кичләр» (А.Володин). Кече залда – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
17 декабрь – Шәрык клубында 14.00 – Балалар өчен рәсем остаханәсе. Зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров).
19 декабрь – Шәрык клубында – «Бичара кыз» спектакле һәм театральләштерелгән экскурсия. Кече залда – «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков).
20 декабрь – Зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин). Кече залда – театрның оркестры башкарында мультконцерт.
21 декабрь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

15 декабрь – «Ай, былбылым!» (Ш.Фәрхетдинов).
16 декабрь – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим).
17 декабрь – «Кияүләр» (Х.Вахит).
19 декабрь – «Полиционер» (И.Зәйниев).
20 декабрь – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци әсәре буенча).
21 декабрь – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

15, 16 декабрь – Премьера. «Матурлык» (Ә.Еники әсәре, Б.Минкин инсценировкасы).
18 декабрь – «Наз Галәм» дип исемләнгән мультконцерт.
21, 22 декабрь – «Көлсылу һәм Яңа ел бәйрәме» дип исемләнгән тамаша.

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

15–22 декабрь – «Морозко» Яңа ел спектакле һәм чыршы тирәсендә әйлән-бәйлән.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

15 декабрь – Татарстан дәүләт халык музыка уен кораллары оркестрына Ярамир Низаметдинов һәм Дамир Закиров кушылып җырлый.
16 декабрь – «Һаман истә» дип исемләнгән ретро-концерт. Катнашалар – Алмас Хәсәенов, Гөлназ Гарифуллина, Сәет Хәсәенов, Алинә Хәснетдинова, Салават Шәфыйков, Илүзә Вәлиуллова, Булат Закиров, Миләүшә Миңнушина. Сәнгать җитәкчесе – Татарстан Республикасының халык артисты Вил Усманов.
17 декабрь – 11.00 – Балалар өчен «Снежная королева» спектакле. 17.00 – «Труффальдино из Бергамо» мюзиклы.
18 декабрь – «Агыйдел» ансамбленең «Милли моңнар» дип исемләнгән концерт программасы.
20 декабрь – «П.И.Чайковскийның 100 ария һәм романсы» шәлкеменнән алтынчы концерт.
21 декабрь – «Ночь перед Рождеством» исемле концерт. Катнашалар – Татарстан дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры, В.Никитин һәм С.Тимофеева-Летуновская.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

16 декабрь – «Барокко при свечах» шәлкеменнән «Рождественские цветы» концерты.
19 декабрь – Классик музыка фестивале кысаларында «Евгений Онегин» спектакле (П.Чайковский). Казан консерваториясен тәмамлаган җырчылар А.Тихомиров (Мәскәү), А.Вальмөхәммәтов (Уфа), М.Михайлова (Чабаксар), А.Асаев, Л.Добрынина, Д.Босов (Казан) катнаша. Фестивальнең сәнгать җитәкчесе – Вадим Дулат-Алиев.
20 декабрь – La Primavera оркестрына саксофонист Леонид Друтин кушылып уйный.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

16 декабрь (шимбә). ***Җөмәдел ахир аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 12.12 сәгатьтә калка, 19.29 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.02 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчәләр файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Өрек сихәте

Өректәге калий йөрәк мускулына бик яхшы тәэсир итә, организм тукымаларындагы артык сыеклыкны чыгарырга булыша. Ул шулай ук ашкайнату барышын да көчәйтә, коры ютәлдән дә дәва бирә. Балаларга исә үсәргә ярдәм итә, сәламәтлекне ныгыта. Һиндстан һәм Пакистан галимнәре әйтүенчә, өрек җимешен даими ашау гомерне озайта. Тибет медицинасында өрек төше ютәлгә һәм күңел болгануга каршы чара буларак кулланыла. Абрикос согы организмда тоз әйләнешен яхшырта һәм шуңа бәйле рәвештә йөрәк эшчәнлеген нормага сала. Кан басымы югары булган кешеләргә өрек ашау бигрәк тә файдалы.

17 декабрь (якшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 12.28 сәгатьтә калка, 21.09 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.01 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Инҗир ютәлне баса

Ютәлләгәндә, тамак авыртканда, 2 инҗирне турап, 1 стакан сөткә салалар, кайнатып чыгарып, бик сүрән утта ярты сәгать пешерәләр. Көненә 2 тапкыр, ашар алдыннан, кайнар килеш 1 әр стакан эчәләр. Теш сызлаганда уртларны җылы инҗир белән ышкысаң, авырту берничә сәгатькә басыла.

18 декабрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 12.39 сәгатьтә калка, 22.45 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.01 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Тавыш карлыкканда

Вакланган шалфей, эвкалипт, ромашка, тырнак гөл яфракларын тигез микъдарда алып, өстенә кайнар су коялар, бераз суынгач, сөзеп, тамакны чайкыйлар һәм ингаляция ясыйлар. Әгәр шул төнәтмәгә 1 аш кашыгы бал кушып, 10-15 минут кайнатсаң, сыек ширбәт барлыкка килә, аны көненә 5 тапкыр 1 әр чәй кашыгы эчәргә була.

19 декабрь (сишәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 12.48 сәгатьтә калка, 0.20 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Тоз тешне ныгыта

Бер чеметем борыч һәм чирек чәй кашыгы аш тозы катнашмасы – менә дигән теш порошогы. Көн саен тешне шуның белән чистарту кариестан саклый, авыздан килгән тәмсез исне бетерә, урт канавын, теш сызлавын туктата. Уртларны ныгыту өчен, аларга көн саен сарымсак ышкырга кирәк. Дәва курсы – 2 атна. Аннан соң 5 көн ял итеп, тагын кабатларга мөмкин.

20 декабрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 12.55 сәгатьтә калка, 1.53 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

21 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 13.03 сәгатьтә калка. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 6.59 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Кальций чыганагы

Йомырка кабыгы – җиңел үзләштерелә торган кальций, витамин һәм микроэлементларның табигый чыганагы. Йомырканы җылы суда сабынлап юалар, эчен бушаткач, яхшылап чайкыйлар һәм, кайнар суга салып, 5 минут кайнаталар. Кипкәч, элпәсеннән чистарталар һәм бик вак итеп төяләр. Аяк-кул сынганда, яртышар чәй кашыгы порошокны көненә 3 тапкыр кабалар, артыннан җылы су эчәләр. Озак дәваланырга туры киләчәк, тик сөякләр яхшы ялганачак. Кышкы һәм язгы витамин кытлыгы чорында ярты чәй кашыгы порошокны иртәнге ашка кушып ашау файдалы. Дәва курсы – 2-3 атна.

22 декабрь (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 13.13 сәгатьтә калка, 3.26 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 6.59 сәгать.***

Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Кабаклы аш

250 грамм кабак, 100 грамм кишер, 125 миллилитр сөт, 1-2 сабак яшел укроп яки петрушка кирәк. Кабак белән кишерне шакмаклап турап, кайнап торган суга салалар, 20-25 минут пешерәләр, бераз суытып, блендер белән издерәләр. Туралган укроп яки петрушка, җылытылган сөт кушып, сүрән утта 5 минут пешерәләр. Артык куерып китсә, яшелчәләр пешкән шулпа белән сыекларга була.

Әмирнең алтын куллары

Кешеләр хәзер телефон, интернет аша гына аралашуны хуп күрә, бер-берең белән күзгә-күз карап җанлы аралашу, кунакка йөрешүләр сирәгәя бара. Тик адәм баласының табигатенә бер-берсе белән аралашу ихтыяҗы салынган бит, ягъни һәрвакыт кешегә кеше кирәк. «Әменә безнең авылда хатын-кызлар өйдә ябылып утырмыйлар, китапханәгә җыелалар», – дип гаҗәпләндерде Гөлшат ханым Әгъләмова.

Ул – 2017 елдан бирле Әмир авылы китапханәчесе. Чирмешәнгә юлым төшүгә, китапханәгә утырмага йөрүче апа-әбиләрне күрергә дип Әмиргә махсус кердек. Соңгы тапкыр монда җәй көне, шушы авылдан чыккан танылган эшмәкәр химаячеләр – бертуган Әгъләмовлар оештырган Авыл көнендә булган идек. Әлеге Авыл көнендә юбилеен билгеләп үтүчеләр дә, озак яшәгән парлар да, йорт салучылар да – берсе дә бүләксез калмый. Авылда һәр яңа туган балага әллә ничә еллар буе 100 мең акча биреп баручылар да – алар. Авыл көнендәге һәр уенның җиңүчеләренә саллы-саллы бүләкләр әзерләнгән иде. Бәйрәмнең иң дулкынландыргыч мизгеле исә Әгъләмовларның авариядә имгәнеп калган авылдаш кыз балага яңа автомобиль ачкычлары тапшыруы булгандыр. Дөресен әйткәндә, Әмирдә Әгъләмовлар өлеше кермәгән өлкә сирәк. Авыл үзәгендә балкып утыручы мәчетне 2020 елда капиталь төзекләндереп, өр-яңадан диярлек ясап чыкканнар. Авыл тарихын өйрәнеп-туплап нәшер ителгән саллы,

912 битлек китап та авылдашларга затлы бүләк булган. Анда Әмирнең һәр йорты, һәр гаиләсе турында мәгълүмат бар.

«Шул авылда туып үссәм дә, авылым турында күп нәрсәне белмәгәнмен икән», – диючеләр дә булган хәзер Әмирнең һәр йортында торучы бу китапны укыгач. Читтә яшәүче авылдашлар да соратып ала. «Бу – безнең авылның энциклопедиясе, туплап чыгаручы мөхәррире Илдар Кыямовка да зур рәхмәт», – ди әмирлеләр.

Бүген авылда 300 ләп кеше яши, шулар арасыннан 17 ханым даими рәвештә 2017 елдан бирле шушы утырмаларга йөри икән. Тик кенә утырмыйлар, халкыбызга хас булган кул эшләре белән шөгыльләнәләр – бәйлиләр, чигәләр, төрле хәйрия акцияләренә әйберләр әзерләп тапшыралар. Күз явын алырлык алъяпкычлар чигеп кигәннәр, чиккән сөлгеләр, мендәр тышларының җаны гына юк. Затлы калфаклар тегәргә, чигәргә

өйрәнгәннәр. Болардан тыш, кем нинди яңа һөнәргә өйрәнә, башкаларны да шуңа өйрәтә икән. Күптән түгел ротангтан кәрҗин үрергә өйрәнгәннәр. Эшләгәндә җырлап, рәхәтләнеп аралашып утыралар. Бу уңган ханымнар каз өмәләрен дә бергәләп үткәрә, каз канаты сыдыру кебек борынгыдан килгән эшләрне дә онытмый. Үзләре белгәнне балаларга да өйрәтүләре исә нур өстенә нур – җәен мәчеттә эшләүче лагерьга йөргән балалар да китапханәгә килеп, төрле һөнәрләргә өйрәнеп китә.

«Җыелыр урыныбыз бар, эшләр эшебез бар, ашар ашыбыз бар, шөкер», – ди Әмирнең уңган да, сөйкемле дә апа-әбиләре. Һәркайсы – дөнья бәясе кеше. Араларында төрле һөнәр ияләре – 28 ел буе мәктәптә пешекче булып эшләгән Рәсимә апа, 42 ел буе фельдшер булган Һаҗәр апа, социаль хезмәткәр Тәнзилә апа, тагын аш-су осталары, башка һөнәр ияләре бар. Аларны китапханәгә җыеп, оештырып, аралаштырып торучы тынгысыз җан – китапханәчеләре Гөлшат Әгъләмова. Эшмәкәр Әгъләмовларның кадерле сеңелләре ул. Агалары авылга матди яктан терәк булса, Гөлшат аның рухын кайгыртып торучы. Үз авылының чын патриоты, аның турында сәгатьләр буе сөйләп тора ала: «Авылыбызда башлангыч мәктәп, медпункт, балалар бакчасы эшли, барысы бер түбә астында – 2020 елда салынган күп функцияле бинага урнашкан. Кибетебез дә бар. Мәктәптә 9 бала, бакчага 5 бала йөри. Ел саен авылда бер бала туа... Аз инде, тик шуларына да шөкер».

Үзенең тарихын, шәҗәрәсен, тамырларын белгән, горурланган, үз туфрагы белән горурланырлык шәхесләр үстергән, бүген дә замананың рухи чирләренә бирешмичә, милли һөнәрләрне, йолаларны саклап яшәүче шундый авылларыбыз һаман да татарның нигезе булып кала бирә. Милләтебезне көчәйтүнең иң гади юлы – күбрәк бала табып үстерү икәнен дә аңлатасы иде халкыбызга.

Эльмира СИРАҖИ.
Автор фотолары.

Татарларга аркадаш үзбәк галиме

● Бегали Касимов.

Һәр халык үзенең тарихи яшәешендә үз кысаларында гына гомер кичерми: башка кавемнәр белән дә теге яки бу дәрәҗәдә бәйләнешләргә керә, тормыш тәҗрибәсе, рухи һәм матди байлыклары белән уртаклаша.

Татар һәм үзбәк багланыш-элемтәләре – моның күркәм бер үрнәге. Географик яссылыкта бу кавемнәр бер-берсеннән ерак булса да, аларны якынайтучы, берләштерүче факторлар шактый. Дини уртаклык, кан-кардәшлек, тел якынлыгы, үзара сәүдә, күчеш-керешүләр, бер-беренә барып белем алу, уртак рухи кыйммәтләргә таяну һ. б. – әнә шундыйлардан. Татарның күп кенә гыйлем-мәгърифәт, дин әһелләре (Г.Утыз Имәни, Г.Курсави, Ш.Мәрҗани...) Бохара, Сәмәрканд шәһәрләрендә укый. Үз чиратында Уфа, Оренбург, Әстәрлебаш һ.б. татар мәдрәсәләрендә белем алган үзбәк яшьләре дә шактый. Рабгузый, Харәзми, Суфый Аллаяр кебек уртак әдипләребез дә бар. Үзбәк халкының XV йөздә яшәгән бөек шагыйре Нәваи татарлар арасында да зур абруй казана.

Бер үк дәүләтләр, бигрәк тә Рәсәй, СССР мәмләкәтләре составында яшәү дә бу кавемнәрнең үзара аралашу-керешүенә көчле йогынты ясый. Узган гасыр урталарында Үзбәкстанда ярты миллионнан артык татар яшәве үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Соңгы чирек гасырда Татарстанда эшләүче, укучы, яшәүче үзбәкләр саны да бик нык арты. Мөгаен, аларның саны берничә меңгә җитәдер.

XX йөздә, бигрәк тә совет чорында Үзбәкстанның фән, мәдәният, мәгариф тармакларында татарлар аеруча күпләп хезмәт куя. Алар арасында Чыңгыз Әхмәров, Габдрахман Сәгъди, Мидхәт Булатов, Галия Измайлова, Әсгать Мохтар һ.б. мәшһүр затлар бар. Мондыйларның кайберләре ике халыкка да хезмәт күрсәтә. Мәсәлән, татар әдәбияты буенча җитди хезмәтләр, дәреслек-әсбаплар язган Г.Сәгъди (1889-1956) гомеренең икенче яртысын Үзбәкстанда уздыра, Сәмәрканд университетында профессор вазыйфаларын башкара, милли кадрлар хәзерләүгә зур өлеш кертә, Нәваи иҗаты буенча беренче булып докторлык диссертациясе яклый (1949).

Татар-үзбәк багланышлары әле тиешенчә яктыртылмаган. Шулай да әдәбият өлкәсенә мөнәсәбәтле мөһим генә мәкалә-хезмәтләр бар. Мондыйлар рәтендә Ризаэддин Фәхреддин, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъди, Шакир Абилов, Лирон Хәмидуллин һ.б. язмалары билгеле. Үзара багланышлар мәсьәләсе үзбәк галимнәре Ширали Турдыев, Лалә Мәгъсүмова кебек әдәбиятчыларның да игътибар үзәгендә. Болар арасында күренекле галим Бегали Касимов (19.12.1942-2004) лаеклы урын алып тора.

Ул чыгышы белән Кашкадәрья өлкәсендәге Денау кышлагыннан. 1958-1963 елларда Үзбәкстан дәүләт университетының филология факультетында белем ала. 1963-1966 елларда шунда ук аспирантура уза. 1968 елда «Мирмухсин Шермөхәммәдов (Фикри) һәм аның әдәби даирәсе» темасына кандидатлык диссертациясе яклый (бу каләм әһеле «Галия» мәдрәсәсендә укый, Г.Ибраһимовны үзенең остазы дип саный). 1984 елдан – филология фәннәре докторы. Темасы «XX йөз башы үзбәк поэзиясе». Рәсми оппонентларның берсе – Ибраһим Нуруллин. Бу ике галим тикшерү объектлары һәм фикер-карашлары белән бер-берсенә якын иде. Аралашып тордылар. Б.Касимов 1966 елдан алып гомеренең соңгы көненә кадәр үзе белем алган университетта эшләде: өлкән укытучы, доцент, профессор, кафедра мөдире, декан, проректор, диссертацияләр яклау советы рәисе һ.б.

Б.Касимовның кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре аерым китаплар рәвешендә нәшер ителгән. Болардан тыш аның дистәләгән монография-җыентыклары бар. Ул узган гасыр азакларында Төркиядә дөнья күргән 30 томлык «Төрки әдәбиятлар тарихы» китабындагы күпләгән язмаларның авторы да.

Галимнең тикшерү даирәсе шактый киң һәм төрле. Анда Ясәви һәм Нәваи кебек Урта гасыр шагыйрьләре дә, соңгы дәвер әдипләре дә бар. Әмма төп урынны XIX йөз ахыры, XX гасырның беренче яртысындагы үзбәк әдәбияты алып тора. Ул бу чорның каләм әһелләренең мирасларын, әдәби процессын монографик планда да, аерым проблемалар (мәгърифәтчелек иҗат методлары, жанрлар...) аркылы да тикшерә. Дистәләгән авторның әсәрләрен шәрех-аңлатмалар белән бастырып чыгара. Аның башка кавем вәкилләре хакында да язган хезмәтләре бар. Мәсәлән, «Исмаилбәк Гаспралы» монографиясендә (1990) ул кырым татарларының бөек мәгърифәтчесе эшчәнлеген төрки, ислам дөньясы мәйданында карый, аның әһәмиятен, ролен киң планда яктырта.

Мәгълүм ки, Урта гасыр Шәрык классикасы, шул исәптән үзбәк әдәбияты күп гасырлар дәвамында безнең рухи тормышыбызда мөһим роль уйнады. Ә инде XX йөз башларында татар сүз сәнгате, мәдәнияте, мәгърифәте зур үсеш ала һәм башка төрки кавемнәргә, шул исәптән тугандаш үзбәк халкына да көчле йогынты ясый. Бу реаль хакыйкатькә тугры калып, Б.Касимов та татар-үзбәк багланышларына даими игътибар итә. Аның татар тематикасына, үзара багланышларга багышланган махсус язмалары да бар. Аларның шактые галимнең 1986 елда дөнья күргән «Салом, келажак» җыентыгында туплап бирелгән (Ташкент: Г.Голям исем. нәшр., 1986).

Китаптагы «Шәһри Болгар хикәяте» һәм «Болгар хакыйкате» дип исемләнгән тәүге ике язмада Болгарга антик Греция хөкемдары «шәүкәтле Искәндәр»нең (Александр Македонскийның) төньякка «абехәят» (мәңгелек тереклек суы») эзләп килгән вакытта нигезләнүе бәян ителә (Мәгълүм ки, бу әфсанә-легенда Низами, Әхмәдинең мәшһүр «Искәндәрнамә» поэмаларында да гәүдәләнеш тапкан). Шушы язмаларда ук Болгар хакында, аның мөселман дөньясында мөһим үзәк булуы, андагы гыйлем-мәгърифәт турында мәгълүматлар бирелә. «Сарай язмышы» исемле өченче мәкаләдә Алтын Урда башкаласының тарихы, «шөһрәтле» шәһәр булуы искәртелә һәм аның Урта Азия хөкемдары Аксак Тимер тарафыннан «вәйран кылынуы» бәян ителә. Бу язмага фарсы әдәбиятының классигы, бераз вакыт Сарай каласында яшәп алган Кәмал Хөҗәндинең (XIV йөз) Сарайның «дилбәрдәй» матурлыгын мактаган шигыре һәм Сәйф Сараиның бу калада шагыйрь булып танылуы турындагы юллар да китерелә.

Алдагы язмада Сөембикәнең фаҗигале язмышы, аңа мөнәсәбәтле манара, Казанның Иван Грозный тарафыннан яулап алынуы хакында сүз бара. «Рус патшасы, – ди мәкалә авторы, катыкуллык белән руслаштыру сәясәтен үткәрде. Татарларга шәһәрләрдә, Идел буйларында яшәү тыелды. ... мәчетләр чиркәүгә әйләндерелде... Урыс җирләреннән күпләп хәрбиләр китерелде һәм аларга татар мөлкәтләре бүлеп бирелде».

Алдагы ике язмада татарның XVIII-XIX йөзләргә мөнәсәбәтле аерым вакыйгалары бәян ителә. Болар арасында Пугач хәрәкәте, Оренбургның роле, татарларның Бохарага килеп укулары, Әбелмәних Каргалый, Утыз Имәни, Курсави турында да мәгълүматлар бар. Автор язуынча, Р.Фәхреддиннең «Асар»ендә китерелгән 565 татар голәмәсенең күпчелеге Бохарада белем алган.

Б.Касимов бөек мәгърифәтче Ш.Мәрҗанигә махсус мәкалә багышлаган. Язмада аның тормыш юлы, Бохара һәм Сәмәркандта уку еллары, киң кырлы эшчәнлеге шактый тулы яктыртыла. Татар галименең тәнкыйди рухлы каләм әһеле булуы, Казан университеты мөгаллимнәре белән хезмәттәшлеге дә искәртелә. Бу язмага эпиграф рәвешендә Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Акмулланың Мәрҗанинең бөеклеген мәдехләгән сүзләре дә китерелә. Алга таба, бу мәкаләнең дәвамы рәвешендә, «Университет көтепханәсендә» дигән язма урнаштырылган. Анда бу мәшһүр китап сараеның тарихы, аның рухи хәзинәләргә гаять байлыгы, андагы аерым язмалар хакында сүз бара. Мәкалә авторы, мәсәлән, әдип һәм атаклы хөкемдар Бабур (1483-1530), аның «Бабурнамә» китабы, бу затның улына язган хаты хакында да мәгълүматлар бирә.

Үзбәк галименең «Истикболга йул излаб» һәм «Ягона максад йулида» дип аталган мәкаләләрендә сүз, нигездә, XX йөз башы – Октябрьдән соңгы тәүге дистә еллардагы әдәби-мәдәни-мәгърифәти бәйләнешләр хакында бара. Автор Урта Азиядә татарча китапларның, гәҗит-журналларның (аеруча «Вакыт», «Шура» басмаларының) киң таралуы, театр труппаларының, җәдитчә мәктәп-мәдрәсәләрнең эшләве хакында да яза. Ул Р.Фәхреддин, Хәмзә, Авлани, Фатих Кәрими, Фатих Әмирхан, Зариф Бәшири, Габдрахман Сәгъди һ.б. татар, үзбәк зыялылары турында да күзәтүләр ясый. Атаклы шагыйрь Гафур Голәмнең истәлекләре аша без Һ.Такташның Бохарада, Ташкентта яшәү чорын, эшчәнлеген күзаллыйбыз. Язмаларда Дәрҗия Аппакова (1898-1948), Заһидә Бурнашева (Гыйффәт туташ – 1895-1977) һ.б. татар әдипләренең дә Урта Азия якларында эшләве хакында мәгълүматлар бар. З.Бурнашева 1917-1933 елларда Үзбәкстанда җаваплы урыннарда, җөмләдән хатын-кызлар мәгариф институты директоры булып та эшләгән икән. Зариф Бәширинең «Үзбәк әдәбияты» исемле китап язуы да телгә алына. Бегали әфәнде үзенең профессор Хатип Госман белән очрашуы турында җылы бер эпизод та китерә. Язмаларда татар сүз сәнгатенең Шәрык белән Гареб арасында арадашчы булуы, урыс, Европа авторларының татарчага тәрҗемәләре хакында да мәгълүматлар бар.

Тукай – соңгы дәвер төрки дөньяда, бигрәк тә үзбәк, казахлар арасында иң билгеле татар шагыйре. Бу хакта күп төрле әдәбият, истәлек-хезмәтләр бар. Аларга Бегали әфәнде язмалары да табигый рәвештә кушылып китә. Ул бөек шагыйрь исемен, иҗатын, әсәрләрен күп кенә башка хезмәтләрендә дә телгә ала. 1968 елгы җыентыкта Б.Касимов Тукай турында махсус мәкалә дә урнаштырган. «Халык сөйгән шагыйрь» дигән бу язмада аның тормышы, иҗаты, рухи тормыштагы, үзбәк-татар мөнәсәбәтләрендәге урыны хакында кызыклы күзәтүләр бар. Б.Касимов язуынча, Г.Тукай «фәкать татарлар өчен генә түгел, үзбәкләр өчен дә кадерле». Ул «халыкка хезмәт итүнең үрнәге». Тукай «халыклар шагыйре», «безнең дә шагыйребез» (Гафур Голәм).

* * *

Язмыш миңа 62 нче яшендә якты дөньядан китеп барган Бегали Касимов белән шактый еллар буе аралашу, сөхбәтләшү мөмкинлеге бирде. Без фәкыйрегез Ленинград, Мәскәү, Дүшәнбе, Ташкент университетларында стажировка узды. Бегали әфәнде исә 1972 елда Казан университетында квалификациясен күтәрде. Ул без гаилә белән торган тулай торакта яшәде. Аралашып тордык. Ул миңа үзбәк халкы, аның мәдәнияте, әдәбияты, Шәрык классикасы белән танышуга ярдәм итте. Без аның белән Анкарада төрки әдәбиятлар тарихын язу процессында күп мәртәбәләр очраштык. 1978 елның көзендә Дүшәнбедән кайтышлый мин Ташкентта тукталдым. Бегали әфәнде шунда үзбәкнең аерым галимнәре, әдипләре белән таныштырды. 1983 елның көзендә Ташкентта стажировка узу чорында мин үзбәкнең Примкул Кадиров, Голәм Кәримов, Ләзиз Каюмов, Азад Шәрәфетдинов (И.Нуруллинның «Тукай» романын үзбәкчәгә тәрҗемә итүче) һ.б. галим-әдипләре белән дә берничә мәртәбә сөхбәтләште. Ул елларда Үзбәкстан башкаласында гомер кичерүче сабакташым, шагыйрь һәм тәрҗемәче Әдхәд Синугыл (1935-2004) белән атна саен диярлек очрашып, хәбәрләшеп тордык...

Бегали әфәнде зур галим, могътәбәр шәхес иде. Безнең халыкка, аның вәкилләренә бик тә игътибарлы һәм ихтирамлы булды. Ачык йөзле, киң күңелле, зыялы бу шәхес күз алдымнан китми, күңелдә яшәвен дәвам итә.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.
30 октябрь, 2023 ел.

“Диктофон” – кеше

Самвел Гарибян (1963-2014) – юрист, телләр өйрәтү буенча оригиналь методика авторы. Аның хәтере балачагыннан ук шәп була, үскән саен әлеге сәләте дә көчәя бара, ул гаять зур күләмле текстларны, саннарны, таблицаларны бик җиңел ятлый. Искиткеч хәтерле бу кешенең ике рекорды Гиннесс китабына кертелгән. 1990 елда Самвелга таныш булмаган 10 телдә (гарәп, урду, кхмер, бенгали, инглиз, дари, немец, итальян, испан, фарсы) 1000 сүз әйткәннәр, ул шулардан 960 ын дөрес тәрҗемәсе белән исендә калдырган. 2000 елда Гарибян рус телендәге 2 мең сүзне хәтерендә калдырырга тиеш булган – 32 генә хата ясаган. Мнемотехникада (хәтердә калдыру сәнгатендә) гаҗәеп уңышларга ирешкәч, Самвел төрле һөнәр ияләренә дә хәтерләрен яхшыртырга ярдәм иткән. Ул, үз методикасын эшләп, китаплар язган. “Хәтер мәктәбе” оештырган, анда теләгән һәркем читтән торып укый һәм хәтерен яхшырта ала. Гарибян тагын да рекордлар куяр иде әле, тик 51 яшендә яман шеш аның гомерен өзгән.

(“Bibliotekar.ru”).

Какебо методикасы

Акчаны санап тотарга күнеккән британиялеләр, җылыту өчен азрак түләү максатыннан, сугыштан соңгы еллар ысулын кулланугa күчкән – җылыткыч һәм шешәләргә кайнар су тутырып куя башлаган. Дөньяның иң бай илләреннән саналган Бөекбритания халкы да, гаилә бюджетын сакчыл тотар өчен, японнарның какебо методикасы буенча яшәүне кулайрак күрә икән. Әлеге методика чыгымнарны 35 процентка киметергә мөмкинлек бирә. Һәр ай башында көтелгән чыгымнарны махсус журналга җентекләп язарга кирәк: башта иң мөһимнәрен – ризыкка, транспорт һәм медицинага; аннары – кибет һәм рестораннарга; аннары мәдәнияткә – китап, музыка, кино, театрга; һәм соңгы пункт – бүләккә, ремонтка өстәмә чыгымнар күләме тәгаенләнә. Әмма иң башта дүрт сорауга җавап бирергә кирәк: 1) бер айда барлыгы күпме акча керәчәк; 2) нинди сумманы запаска җыеп куярга ниятлисез; 3) моңа кадәр гадәттә күпме акча тота идегез; 4) акчаны ни рәвешле янга калдырып була. Аннары акча конвертларга бүленә һәм ай буена җиткерелергә тиеш. Японнарның бу методикасы катгый финанс кысаларында яшәргә, акчаны уйлап тотарга өйрәтә. Какебо концепциясен Мотоко Хани исемле япон хатыны инде 1904 елда ук уйлап тапкан, тик аның әһәмияте, бер гасырдан артык вакыт үтсә дә, елдан-ел арта гына бара. Үз акчаңны дөрес тотарга өйрәткән, бик зәвыклы итеп бастырылган мәҗмугалар Европада иң модалы бүләкләрдән санала.

(“The Japan Times”).

Өч миллионнан колак какканнар

Американың Тинек шәһәрендә яшәүче өч бертуган Нед, Роджер һәм Стивен Ландау әниләре үлгәннән соң йортларында 1930 еллардан бирле эленеп торган картинаны сатарга ниятләгән. Аукционга куйганнар һәм беренче бәяне 250 доллар дип билгеләгәннәр. Бәя тиз арада 800 долларга җиткән, аннан соң аукционга Франция белән Германия сатып алучылары кушылган һәм бәя башта 5 мең долларга, аннары 100 меңгә, 450 мең долларга күтәрелгән. Соңгы бәяне бер француз куйган һәм картинаны 1,1 миллион долларга сатып алган. Аукционны оештыручылар аптырашта калган. Германиядән бер коллекционер шылтыраткач кына, барысы да аңлашылган. Ул әлеге картинаны гомере буе эзләвен сөйләп биргән. Полотно Голландия рәссамы Рембрандтның XVII гасыр башында язган сериясенә керә икән. Биш полотно биш сизү хисенә багышланган, Ландау гаиләсендә “Ис сизү” дип аталганы сакланган. Картинаны сатып алган француз, аның чын булуын тикшерткәч, әлеге сериядән өч картинаның хуҗасы булган коллекционерга 4 миллион долларга саткан.

(“Fox Business”).

XX гасыр башындагы инша

XX гасыр башында балаларны ничегрәк укыткан-тәрбияләгәннәр икән? Кызык өчен генә булса да, патша Россиясендәге инша темалары белән танышып карагыз әле. Башлангыч сыйныфларга: “Урман патшалыгы алыплары һәм кәрләләре”, “Кошчык ерак илләрдә ни күргән?”, “Йорт төзү һәм бакча үстерү тарихы”; 12-13 яшьлекләр өчен: “Бакча көзге йокыга тала”, “Айлы төндә елга ярында”, “Урманның иң матур чагы кайчан?”, “Бабам бакчасы”; өлкән сыйныфлардагы гимназистларга: “Бәхет чыганагы буларак сүз”, “Ни өчен тормышны сәяхәт белән чагыштыралар”, “Ватан һәм чит ил”, “Гомер ага...”, “Россиянең байлыгы нидә?”, “Матди байлыкка кына нигезләнгән бәхет бәрәкәтсез була”, “Тарихның әхлакый асылы”, “Әлгәрләр һәм варислар арасындагы рухи элемтә нәрсәгә нигезләнә?” һ.б. темалар тәкъдим ителгән.

(“Лента.ру”).

Чикләвек аша!

Британия галимнәре гомерне озайта торган ризыклар исемлеген төзегән, аңа йогурт, чикләвек һәм җиләк-җимешләр кертелгән. Белгечләр фаразлавынча, әлеге ризыклар сәламәтлек өчен файдалы, шунлыктан чирләмичә озак яшәү мөмкинлеге бирә. Галимнәр рационга әледәнәле балык, диңгез ризыкларын, ярдырылмаган ярмалар да өстәргә, мондый диета буенча тукланганда, физик күнегүләрне даими ясарга киңәш бирә. Медицина фәннәре докторы Михаил Гинзбург та яшьлекне озайтырга сәләтле биш ризыкны атаган. Ул көненә 2-3 чынаяк яшел чәй эчәргә, зәйтүн мае, җитен орлыгы, балык, шикәр өстәлмәгән ачы шоколадны даими ашарга кирәк, дип саный.

(“Die Presse”).

Чүп җыеп байыйлар

Мисыр христианнары (коптлар) Каһирә читендәге Маншият-Насир бистәсендә яши һәм 1969 елдан бирле башкаладагы чүп-чарны җыю белән шөгыльләнә. Хәзер бистәдәгеләрнең саны 40 меңнән арта. Әлегрәк бу кәсебә хәерчеләр шөгыле саналса, бүген инде кайбер мисырлылар чүп җыючыларга көнләшеп карый, чөнки аларның керемнәре бик мул яшәргә мөмкинлек бирә. Коптлар Каһирәдәге барлык чүп-чарның 85 процентын эшкәртеп бара. Баштарак барысына да кул хезмәте таләп ителсә, хәзер машиналар ярдәмгә килә – мәсәлән, пластик шешәләр дә, алюминий банкалар да эшкәртелә һәм икенчел чимал хәттә башка илләргә дә сатыла. Бу эшмәкәрләргә кризис та куркыныч түгел, чөнки чүп-чар һәрвакыт бар һәм аны шәһәр урамнарыннан көн саен җыеп китәргә кирәк. Дөрес, бистәдә һава бик начар – эшкәртүгә яраксыз бөтен нәрсә яндырыла. Тик картраклар моңа күнеккән инде, ә балаларын укырга Европага җибәрәләр. Чүп эшкәртеп баеп булса да, яңа байларның берсе дә балаларының моның белән шөгыльләнүен теләми, аларны табиб яки юристлыкка укытып, кеше итмәкче була.

(“BBC”).

Кайда тәмлерәк?

Мәктәп балаларына нинди ризык ашату турында бәхәсләр бер дә тынмый. Кемнәрдер, укучылар сыйфатлы әзерләнгән файдалы ризык белән генә тукланырга тиеш, дип саный, икенчеләре моны кыйбатсына һәм мәктәптә тамак ялгау өчен бераз арзанрак ашамлыклар да ярап тора, дип ышандырмакчы. Италиядәге стандарт сый җыелмасына руккола белән балык, томат соусы белән токмач, капрезе салаты, багет һәм йөзем керә. Финляндиядә укучыларга гадәттә борчаклы аш, чөгендер салаты, кишер, икмәк, җиләкле панкейк (коймак) бирелә. Франциядә бала-чага кыздырылган ит кисәге, кишер, кузаклы фасоль, сыр һәм җиләк-җимеш белән сыйлана. Көньяк Кореядә мәктәп балаларына гадәттә балык шулпасы, дөге белән тофу, кимчи һәм чи яшелчәләр бирелә. Греция мәктәпләрендә дөге белән томалап пешерелгән тавык, йөзем яфрагына төрелгән ит, помидор белән кыяр салаты, мандарин, анар белән йогырт ярапып ашала.

(“Интересно.cc”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

18 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шаян пластилин».
16.30 «Сәйләшергә вакыт». 16+
17.40 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
23.30 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+
0.25 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
12.35 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Атылган йолдыз эзләреннән. Ф.Яруллин». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00, 18.50, 22.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25, 0.40 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ПОДМЕНА В ОДИН МИГ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ТАЙНА КУМИРА». 16+
11.30 «БАБИЙ БУНТ ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЛЮБОВЬ ПРИХОДИТ ТИХО». 16+
14.35 «Деревни России». 12+
14.50 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
15.00 «Кто нас нарисовал». 12+
15.30 «Игры разведок. Немузыкальная история». 12+
16.30 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ИЩЕЙКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23». 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 Гении и злодеи.
7.30 Черные дыры. Белые пятна.
8.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Владимир Шилейко.
8.35, 14.40 «Забытое ремесло».
8.50, 22.15 «ОШИБКА ТОНИ ВЕНДИСА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Зеркало сцены. Театральное обозрение».
12.10 Цвет времени. Караваджо.
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 «ОДНА СТРОКА».
14.55 К 85-летию со дня рождения Миры Кольцовой. Линия жизни.
15.55 «Агора».
17.30 «Рождение Русской оперы».
17.55 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.00 Уроки русского. Чтения. А. Куприн. «Леночка». Читает Евгений Князев.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Швейцерова соната».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
23.20 «История русских браков».
23.55 «ПОРУС».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.10, 0.00 «БИМ». 16+

Сишәмбе

19 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15, 0.25 «Если хочешь быть здоровым». 16+
11.30, 15.45 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45, 21.00 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Мин татарча өйрәнәм».
16.15 Хоккей. «Авангард» - «Ак Барс». 6+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 18.50, 22.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+
21.25 «Ком сәгате». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ПОДМЕНА В ОДИН МИГ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ТАЙНА КУМИРА». 16+
11.30 «БАБИЙ БУНТ ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЗАВЕТ ЛЮБВИ». 16+
14.30 «Деревни России». 12+
14.50 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
15.00 «Тайные механизмы природы». 12+
15.30 «Секретно. Сталину. Главная загадка Великой Отечественной». 12+
16.30 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.00 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ИЩЕЙКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23». 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Престольный праздник. День Николая Чудотворца».
7.20 «Забытое ремесло».
7.35, 14.50 «Раскрытие тайн Вавилона».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 22.15 «ОШИБКА ТОНИ ВЕНДИСА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 Герард Васильев в концерте «Помнишь ли ты...»
12.00 «Феодосия. Дача Стамболи».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00, 13.20, 13.40, 23.55 «ПОРУС».
14.05 «Игра в бисер» «Павел Бажов. «Малахитовая шкатулка».
15.45 «Сати. Нескучная классика...»
16.30 Святыни христианского мира. «Риза Богородицы».
17.15 «Эрмитаж».
17.45 «Рождение Русской оперы».
18.15 «Учитель, перед именем твоим...»
19.00 Уроки русского. Чтения. А. Чехов. «Два скандала». Читает Владислав Миллер.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
23.20 «История русских браков».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.10, 0.00 «БИМ». 16+

Чәршәмбе

20 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шома бас».
16.30 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Ватандашлар». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 21.25 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30, 23.10 «Йөрәктән-йөрәккә». Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннар турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 22.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
18.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Зөһрә Шәрифуллина. 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ТАЙНА КУМИРА». 16+
11.30 «БАБИЙ БУНТ ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ДОЛГИЙ ПУТЬ». 16+
14.30 «Деревни России». 12+
14.50 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
15.00 «Тайные механизмы природы». 12+
15.30 «Перемышль. Подвиг на границе». 12+
16.30 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ИЩЕЙКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23». 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 «Всеволод Шиловский. Вспоминая старый МХАТ...» Ольга Андровская.
7.35, 14.50 «Раскрытие тайн Вавилона».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 22.15 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Зеркало времени».
12.10 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00, 13.20, 13.40, 23.55 «ПОРУС».
14.05 Искусственный отбор.
15.45 «Белая студия».
16.30 Святыни христианского мира. «Терновый венец».
17.15 «Рассекреченная история».
17.45 «Рождение Русской оперы».
18.15 «Антон Макаренко. Сопротивление личности».
19.00 Уроки русского. Чтения. Е. Замятин. «Русь». Читает Павел Ворожцов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Больше, чем любовь.
23.20 «История русских браков».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.10, 0.00 «БИМ». 16+

Пәнҗешәмбе

21 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Память сердца». 16+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Музыкаль тәнәфес».
16.30 «Дуслык иленд». 12+
16.45 Хоккей. «Автомобилист» - «Ак Барс». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Наши герои». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.30 «Гаилә учагы». 16+
10.00 «Туган авылым». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 18.50, 22.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
21.25 «Ике аккош». Зөһрә Шәрифуллина, Зөлфия Вәлиева: тормыш һәм мәхәббәт турында. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+
11.30 «БАБИЙ БУНТ ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО». 16+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «РАДОСТЬ ЛЮБВИ». 16+
14.30 «Деревни России». 12+
14.50 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
15.00 «Тайные механизмы природы». 12+
15.30 «Ордена Великой Победы». 12+
16.30 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».

22.00 «ИЩЕЙКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23». 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 «Всеволод Шиловский. Вспоминая старый МХАТ...» Алексей Грибов.
7.35, 14.50 «Блеск и слава Древнего Рима».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 22.15 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Страницы дневника. Искусство Евгения Нестеренко».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00, 13.20, 13.40, 23.55 «ПОРУС».
14.05 Абсолютный слух.
15.40 «2 Верник 2».
16.25 Святыни христианского мира. «Гроб Господень».
17.15 Моя любовь - Россия! «Бортничество в Башкирии».
17.45 «Рождение Русской оперы».
18.15 «Русский балет в Сербии. Тамара Полонская».
19.00 Уроки русского. Чтения. А. Толстой. «На острове Халки». Читает Игорь Гордин.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Раба любви». Господа, это ошибка!»
21.30 «Энигма. Микаэла Питталуга».
23.20 «История русских браков».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.10, 0.00 «БИМ». 16+

Җомга

22 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Тәймә».
16.30 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Родная земля». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
22.40 «Сөйләшергә вакыт». 16+
23.35 «ЛЮБОВЬ ПО-ЯПОНСКИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.30, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.00, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.50, 22.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Родная земля». 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+
11.30 «БАБИЙ БУНТ ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «БЕСКОНЕЧНОЕ НАСЛЕДСТВО ЛЮБВИ». 16+
14.30 «Деревни России». 12+
14.50 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
15.00 «Тайные механизмы природы». 12+
15.30 «Энергия Великой Победы». 12+
16.30 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Детский шеф». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05, 19.45 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.40 «Человек и закон». 16+
21.00 «Время».
21.45 «Фантастика». 12+
23.40 «Матадор». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Дуэты». 12+
23.55 «Шоу Большой Страны». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 «Всеволод Шиловский. Вспоминая старый МХАТ...» Анатолий Кторов.
7.35, 14.50 «Блеск и слава Древнего Рима».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 22.15 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.20 «Тридцать лет спустя в БДТ».
12.15 «Первые в мире».
12.45 «Забытое ремесло».
13.00, 13.20, 13.40 «ПОРУС».
14.05 Больше, чем любовь.
15.45 «Энигма. Микаэла Питталуга».
16.30 Святыни христианского мира. «Сирия. По стопам апостола Павла».
17.15 Письма из провинции.
17.45 «Рождение Русской оперы».
18.15 «Билет в Большой».
19.00 Уроки русского. Чтения. И. Бунин. «Ворон», «Муза». Читает Константин Крюков.
19.45 Всероссийский конкурс юных талантов «Синяя Птица».
20.50 «Нижний Новгород. Усадьба Рукавишниковых».
21.20 Линия жизни. Дмитрий Воденников.
23.25 «2 Верник 2».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.10 «БИМ». 16+

Шимбә

23 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА». 16+
11.30 «Музыкальный майдан». 16+
12.00 «Дуслык иләндә». 12+
12.15 «Видеоспорт». 16+
12.45 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.15 Хоккей. «Сибирь» - «Ак Барс». 6+
16.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
16.30 «Гаилә учагы». 16+
17.00 «Сөйләшергә вакыт». 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.30 «Адымнар». 16+
21.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
22.00 «ЗАМЁРЗШАЯ ИЗ МАЙАМИ». 16+
23.35 «СТРАШНО КРАСИВ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Гадел Кутуй турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Сөйләшергә вакыт». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Саф күңелле каласы иде». Вил Усманов концерты. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җитте шундый вакытларым». Зөһрә Шәрифуллинаның юбилей концерты. 16+
23.05 Спектакль «Мәхәббәт турында сөйләшик». 16+

«ЭФИР»

5.00, 14.50 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
5.40 «Муми-Тролли и зимняя сказка». 6+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00 «Шифры нашего тела. Печень». 16+
8.45 «РАДИ ТЕБЯ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «Удиви меня». 16+
14.30 «Деревни России». 12+
15.00 «Украденные коллекции. По следам «Черных антикваров». 16+
15.50 «АЛЕНКА ИЗ ПОЧИТАНКИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БИТВА». 6+
22.30 «ЗАХВАТ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 К 90-летию Галины Волчек. «Они знают, что я их любила». 16+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Юрий Никулин. Великий многоликий». 12+
14.15 Подкаст.лаб «Произвольная программа». 16+
15.00 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.20 «Эксклюзив». 16+
19.15 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.30 «КВН». 16+
23.35 Бокс. 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ЧА-ЧА-ЧА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.55, 8.15, 8.35, 8.55, 9.15, 9.35 «ПОРУС».
10.00, 19.50 Новости культуры.
10.15 «СТРЕКОЗА».
11.50 V Всероссийский конкурс молодых музыкантов «Созвездие».
13.00 Черные дыры. Белые пятна.
13.40 «Первые в мире».
13.55 «Между двух океанов: дикая природа Коста-Рики».
14.55 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.05 «Нобелевские победы российской науки». Алексей Абрикосов.
16.50 Острова. Сергей Урусевский.
17.30 «НЕОТПРАВЛЕННОЕ ПИСЬМО».
19.00 «Длинная дорога в Канны. Михаил Калатозов».
20.10 Большая опера 2023 г. Гала-концерт.
22.00 «Агора».
23.05 «ПАЦАНЫ».

«НТВ»

5.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Суперстар!» 16+

Якшәмбе

24 декабрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Риваять» төрки-татар этникасы ансамбле концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Дуслык иләндә». 12+
11.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.45 «Татар сүзе». 6+
14.00 «Инновации для будущего. 50 лучших инновационных идей для Республики Татарстан». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Халкым минем…». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ЖЕЛТОГЛАЗЫЕ КРОКОДИЛЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Кто мы татары?» 12+
8.00 «Гөлнарага дүрт кияү». Гөлнара Габидуллина концерты. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Эльмир Низамов турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Tatarstan today. Деньяга ачык». 16+
14.20 «Эльмир Низамов һәм дуслар». 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 Спектакль «Мылтык». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Государственная грамота. Законы Советской страны». 12+
5.30 «ТАЙНА СНЕЖНОЙ КОРОЛЕВЫ». 6+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00 «Шифры нашего тела. Внезапная смерть». 16+
8.50 «АЛЕНКА ИЗ ПОЧИТАНКИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВЕЗУЧАЯ». 12+
14.40 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.45 «РАДИ ТЕБЯ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОДИН ВДОХ». 12+
22.40 «УДИВИ МЕНЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Легкие деньги». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Быть рядом!» 12+
11.05 «Жизнь своих». 12+
12.15 «Вызов». Национальная премия в области будущих технологий. 12+
13.55 «Повара на колесах». 12+
14.55 «АМЕРИКАНСКАЯ ДОЧЬ». 16+
16.50 «Имена нелегальной разведки». Александр Коротков. 16+
19.00 «Лучше всех!»
21.00 «Время».
23.00 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»

6.10 «НЕВЕЗУЧАЯ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.40 «СТОЛИЧНАЯ ШТУЧКА». 12+
16.30, 19.00 «Песни от всей души». 12+
17.30 «Всероссийский конкурс юных талантов «Синяя Птица».
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.30, 7.50, 8.10, 8.30, 8.50, 9.10 «ПОРУС».
9.35 «Цирк». Я хотела быть счастливой в СССР!»
10.15 «ЦИРК».
11.45 Невский ковчег. Теория невозможного. Нина Лебедева.
12.10 «Элементы» с Григорием Голдовским».
12.40 «Педагогам Московской балетной школы посвящается».
13.25 250 лет Московской государственной академии хореографии. Юбилей в Большом театре России.
15.45 Линия жизни. Марина Леонова.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.30 «Романтика романса».
18.20 «Театр как судьба».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «ОСЕННИЙ МАРАФОН».
22.00 «33 удовольствия». Гала-концерт в театре «Геликон-опера».
23.20 «КОРОЛЕВСКАЯ СВАДЬБА».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.15 «Квартирник НТВ у Маргулиса». 16+

Татарлар оекбаш бәйләми?..

Оренбург өлкәсендәге Әсәкәй районының Яңа Солтангол авылына барып чыгарга туры килде. Ноябрь уртасы. Аяк асты катыра башлаган. Әмма бер мәлдә, боз ватылып, туфлием кызыл балчык катыш суга чумды...

– Болай булмый. Салкын тидереп, чирләп ятуың бар, – дип безне озатып йөрүче Ягъфәр абый Фәттахов район үзәгенә алып китте. Шөкер, Әсәкәй якын – биш чакрым ара. Биш минутта килеп җиттек. Кибеттән 45 нче үлчәмле гәлүш сатып алдым. Киез олтан да салгач, аякларм рәхәткә тиенде. Дөрес, фабрика оегы никадәр генә калын булмасын, йон оекбаш түгел инде. Бу соңгы җөмләне кычкырып әйткәнмен, ахры. Авылда оекбаш бәйләүче табарбыз, дип тынычландырырга ашыкты Ягъфәр абый. Ашыгыбрак әйткән икән.

Ни кызганыч, җирле халык театры режиссеры, китапханәче Шазия апа да соңгы вакытта Яңа Солтанголда кемнәрнең йон оекбаш бәйләгәнен исенә төшерә алмады (әнә авыл башында торучы, утызлап сарык асраучы Ильяс Нигъмәтуллин, бер көнне гәпләшеп торганда, ел саен 8-9 капчык сарык йонын чыгарып түгәм, җыючы, сатып алучы юк, дип аһ орды).

Авыл имам-хатыйбы Рафис хәзрәткә рәхмәт яусын! Ярдәм сорап түгел, сүз уңаеннан гына зарланган идем. «Миңа сәдака итеп ике оекбаш бүләк иттеләр, берсе – синеке», – дип ярты сәгатьтән икене күтәреп килде. Мин зуррагын сайладым. Дөрес, оекбаш зур гына булса да, таррак бәйләнгән икән. Шуны сиздергәч, сишәмбе көнне Әсәкәйдә базар була, барып килербез, дип «юаттылар» тагын.

Тик сишәмбе көнне базарга барырга туры килмәде. Мине сәфәргә чакырган хуҗалык башлыгы, «Алга» агрохолдингы генераль директоры, өлкә татар милли-мәдәни мөхтәрияте башлыгы, өлкә законнар чыгару җыелышы депутаты Илдус Дәүләтов Гали авылына юллады. Шушы көнне килер, дип авыл җирлеге башлыгы Идрис Муллабаев белән сөйләшеп куйган икән. Иртүк юлга кузгалдык. Мине йөртүче шофер егет Ривал «Гали хәтле Галидә оекбаш бәйләүче йөзләгәндер әле», дип Әсәкәй ягына борылып та карамады.

Самара өлкәсендәге Похвистнево районына караучы Гали авылы Яңа Солтанголдан 70 чакрымда. Бер сәгать эчендә барып та җиттек. Исәбем – Илдус Дәүләтов нәселенең шәҗәрә башында торучы Манаш тархан турында кайбер мәгълүматларны ачыклау иде.

Фараз дөрес булып чыкты. Гали авылыннан 10-15 чакрым ераклыкта гына урнашкан Солтангол дигән тагын бер авыл, чынлап та, үз заманында Манаш тархан варисларына караган. Алар әлеге биләмәне 1755 елда чуашларга саткан. Чуаш кардәшләр авыл исемենә тимәгән. Бу хакта шушы авылның тарихын барлаган Поляков дигән агай тарихи очерк язган. Үзе вафат булгангамы, кульязманы ташка бастырырга ашыгучы юк икән. «Аны кадерләп саклыйбыз, басылмыйча калмас», дип әлеге кульязманы Солтанголның ветераннар советы рәисе Артемий агай Ильин китереп күрсәтте. Ни кызганыч, авыл тирәсендә татар-мөселман зираты да калмаган икән инде.

Шунысы кызык: Идрис яшьти белән чәйләп утырганда яныбызга сугылып чыккан җирле фермерлар – Камил Исхаков белән Халит Йосыповлар да Манаш тархан шәҗәрәсенә бәйле булып чыкты. Камил – әтисе ягыннан, Халит әнисе ягыннан Манашка барып тоташа, димәк, Илдус Дәүләтовка кардәш булып чыга.

Сүз барышында һаман да шул, «каһәр төшкерә» оекбаш мәсьәләсе калкып чыкты. Әкәмәт, Галидә дә оекбаш бәйләүчеләр юк икән. Һәрхәлдә, авыл җирлеге бинасының беренче катында гына урнашкан туган як музее җитәкчесе Кәүсәрия Шәйхетдинова бу җәһәттән берничек тә сөендерә алмавын җиткерде.

Шуннан соң Идрис әфәнде, Рысайкинода булмый калмас, дип Галигә терәлеп торган күрше чуаш авылына алып китте. Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди. Ялгызы гына яшәп ятучы Лена Владимирова атлы ханым каршыма ике капчык оекбаш китереп куйды. Җаның теләгәнен сайлап алырга мөмкин. Элеккечә, үзебезнең татар әбиләре бәйләгән кебек озын кунычлы, киң аякка исәпләнгәннәре дә, хәзерге шәһәр карчыклары бәйли торган чүәк кебекләре дә, бәбиләргә, олыларга, яшүсмерләргә дигәннәре дә бар. Бәяләре 600 сум, ди Лена түтәй. Яшәсен, кардәш, уңган чуаш халкы!

Оекбаш вакыйгасы моның белән генә бетмәде әле. Казанга кайтып китәр алдыннан, Яңа Солтангол мәдәният йорты директоры Әлфия Дәүләтҗанова, әллә инде үзләрендә дә бәйләүче табылган, бездән дә бер күчтәнәч булыр, дип тагын ике йон оекбаш алып килде...

Рәшит МИНҺАҖ.
Автор фотолары.

● Яңа Солтангол мәктәбендә укучылар белән очрашу вакытында.

● Рафис хәзрәт йөз яшьтә вафат булган Мәрьям әби кабере янында.

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

Һ. Такташ, Г. Кутуй һәм ике Галия

Без Гаделнең әлеге бакча янәшәсендәге фатирына юнәлдек. Өйдә беркем дә юк. Ул мине уңайлырак урынга утыртты да, үзе, каршыма – идәнгә утырып, калын гына папканы ачып, укый да башлады. Ул бик оста укучы да иде. Шунда ук мине әсәр эченә мавыктырып алып кереп тә китте. Гади генә башлап кителгән җөмләләре шулкадәр үтемле иде, әсәрдә сурәтләгәннәр тәэсиренә бирелгәнемне сизми дә калдым. Күпмедер укыгач, ул миңа күтәрелеп карады. Китәргә ашыкмыйммы, дию. Мин аңа кул гына селтәдем. Ул тагында дәртләнеп укып китте. Шул рәвешле, ничә сәгать утырганбыздыр, Гадел үзенең тәэсирле интонациясе белән нокта куйгач кына игътибарымны йомшарттым. Ул миңа күтәрелеп карады. Бу караштa «йә, ничек?» дигән сорау бар иде.

Мин бары тик:

– Гүзәл поэма! – дип кенә әйтә алдым.

Шактый тын торгач, сүземне дәвам иттердем:

– Моны тиз генә бастырырга кирәк!

– Шаяртасың, минем кулдан аны кем алсын?

– Син түгел, мин бирермен. Алырлар, моны да алмагач, тагын нәрсә басып утырырлар икән?

Гадел, бик әйбәтләп төреп, әсәрне миңа тоттырды. Үзендә караламасы калды. Чыннан да алдылар, алай гына да түгел, бастырып та чыгардылар. Гадел тулы хокуклар белән язучылар яңадан әдәбиятка кайтты.

Әлеге кичәдә Галимә апа әйтте:

– Сугышка кадәрге биш-алты елда без бик бәхетле булып, рәхәт яшәдек. 1936 елда туган улыбыз Рөстәм тормышыбызны тагын да ямьләндереп җибәрде...

«Тапшырылмаган хатлар» повесте, чыннан да, Такташ әсәре белән бәхәскә кереп иҗат ителгән. Төп героиняларның исемнәре Галия булу әле берни дә әйтми. Чөнки аларның икесе ике Галия. Кутуй үз Галиясен тулы канлы, ихлас ярата белүче, тырыш, максатка туры баручан, балаларына яхшы ана, менә дигән табибә, абруйлы җәмәгать эшлеклесе итеп сурәтләгән. Рәсми идеология күрергә теләгән менә дигән замана хатын-кызы. Уңай геройны өлге иткән совет әдәбиятының бер мисалы. С.Цвейгның «Таныш булмаган хатын-кыз хаты» әсәрен күз уңында тотуы да шушы максатларга хезмәт итә. Автор кешене кеше изүгә корылган капитализм шартларындагы хатын-кызның язмышы күп очракларда фаҗигале тәмамлана дип расларга тели. Шул ук вакытта Кутуйның иҗат өчен хат стилен сайлавында да С.Цвейг әсәренең йогынтысы булуын әйтергә кирәк.

Шуннан соң Г.Кутуй әсәренең бәхетле язмышы башланды. Гәрчә, чәчмә юл белән иҗат ителгән булса да, ул сәхнәләргә дә күтәрелде, хәтта опера спектакле булып әверелде. Алардагы җырлар халык күңеленә кучте. Бу әсәргә бүгенге сәнгать әһелләре дә мөрәҗәгать итә. Болар барысы да Г.Кутуйның сәнгатьчә осталыгы, язучылык таланты нәтиҗәсе иде. Вафатына 78 ел үткәч тә аның шәхесен һәм әдәби мирасын зурлап телгә алабыз икән, димәк, ул үзе дә халкыбыз күңелендә яшәвен дә дәвам иттерә, дигән сүз.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Мәхәббәтле сәнгать

Артур – дизайнер. Диләрә – татар теле белгече. Икесе дә Кукмарада туып үскән. Икесе дә Казан дәүләт университетында белем алган. Гаилә корганнар. Һәм бүген икәүләшеп борынгыдан килгән чүлмәкчелек сәнгатен торгызалар.

Кукмара кешеләре гадәттән тыш тырышлыклары, үҗәтлекләре, максатчанлыклары белән аерылып тора. Бу сыйфатлар чүлмәкче Шакировларга да хас. Юкса барлы-юклы биш ел эчендә шундый нәтиҗәләргә ирешер идемени алар?

Әйе, нәкъ биш еллап элек без бу матур пар турында бер язган идек инде. Ул вакытта алар әле юлның башында гына булган. Ә хәзер ныклап аякка басканнарын күреп сөендек. Беренче күрешүебездә Кукмарага яшәргә кайтып, «Галактика» балалар иҗат клубында укыта гына башлаган чаклары булгандыр. Клубның директоры, һич көтмәгәндә, рәсем, компьютер графикасы белән бергә чүлмәкчелек һөнәрен өйрәтүне дә сорагач, Артур белән Диләрәгә башта кыенга туры килә. Казанда балчык әвәләү курсларында укып алсалар да, белем җитенкерәмәген сизеп, төрле чыганаклардан – китап, интернеттан һәм һөнәрчеләрне эзләп табып һөнәр өйрәнүгә җитди керешәләр. Кукмара кешесе тотынсамы!.. Булдырмаганы юк кукмараларның...

Дөрес, башта байтак савыт-саба ватыла. Эш бармаганда чыгырдан чыгып түгел. Үзле балчыкның сыйфатын белеп бетермәгәнлектән, пичтә яндырган вакытта ватылган тәлинкәләр турында сүз бара. Аннары балчык белән «дуслаша төшкәч», төрле сортларның холык фигылен өйрәнеп алгач, эш майлаган арба кебек бара башлый. Бүген Кукмараның үз балчыгы да, Оренбург, Урал якларыннан кайтартканы да, Испания, Төркиядән китерткәне дә эшкә ярый. Кызыл, ак балчык кулланалар. Чүлмәкчелек дисәк тә, Шакировлар гел чүлмәк кенә ясамый, тәлинкә, чәчкә савытлары, чынаяклар, муенга тага торган бөтиләр һәм тагын әллә ниләр иҗат итәләр. Берсен дә буямыйлар, сөттә юып, пичтә яндыргач үзенә бер төрле матур күрән төскә керә тәлинкәләре. Иң мөһиме, нәрсә генә ясасалар да, бөтенесенә милли бизәк төшерәләр. Тагын кызыгы шул, савыт сабалары түгәрәк түгел, өчпочмаклы, дүртпочмаклы... Берсе, әйтик, өлешләп өчпочмак чыгару өчен махсус уйланылган. Моннан биш ел элек бер генә төр тәлинкәләре булса, бүген Шакировларның иҗат әсәрләреннән киштәләр сыгылып тора. Барысы да матур, зәвыклы, карап кына торасы килә. Кукмара халкы да Шакировларны бик хөрмәт итә. Мәдәният министрлыгы үткәргән «Республикабызның мәдәни башкаласы» бәйгесенә Казаныбызга районның иң оста куллы шәхесләре белән бу матур гаилә дә килгән иде.

Яшь булсалар да, үзләренең чүлмәкчелек брендын булдырулары өстенә әле мөгаллим буларак та борынгы һөнәребезне торгызуга, үстерүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Көндезләрен «Галактика»да балаларга балчык сәнгатенең серләрен өйрәтсәләр, кичләрен һәм ял көннәрендә үзләренең RA CERAMICS шәхси остаханәләрендә бөтен теләгән кеше өчен осталык дәресләре оештыралар. Бирегә килеп бала-чага туган көннәрен уздыра, аларның әти-әниләре авыр эш атнасыннан соң бушана, күңелен ял иттерә.

Балчык әвәләүнең кеше организмына файдасы әйтеп бетергесез зур. Балаларның бармаклары хәрәкәт итәргә өйрәнә. Юкса телефон төймәләренә генә басып, баш бармактан кала бүтәннәре әлле-мәлле бер хәлгә килгәндер. Бармак хәрәкәтләнгән саен исә, баш мие әйбәтрәк эшли. Галимнәр хәтта психик тайпылышлы яисә тумыштан берәр төрле рухи авыруы, җитешсезлеге булган балалар өчен балчык әвәләтеп дәвалау-реабилитацияләү методикаларын уйлап тапкан.

Өлкәннәр дә остаханәгә бик яратып йөри икән. Бүген әле бер, әле икенче илдә сугыш башланган заманда бераз онытылып тору, баштагы уйларны бер тәртипкә китерү, куркуларны беразга гына булса да куып тарату өчен балчык әвәләү бер дигән. Аеруча яшь парлар, гашыйклар өчен мәхәббәтне ныгыту чарасы буларак файдалы чүлмәкчелек. Балчык бит ул – тереклек, тормыш башы. Коръәндә дә Адәмнең балчыктан яралтылганы турында әйтелә. Галимнәр исә балчыктагы һәм кеше организмындагы минераллар җыелмасы бер-берсенә тәнгәл килүен ачып Коръәндә язылганнарны фәнни яктан дәлилләде. Чүлмәк ясый торган әйләнмәле җайланма да кояш, тормыш символы түгелмени? Сөйгән ярың белән шул җайланманы әйләндереп, дүрт куллап балчыктан чүлмәк ясауда ниндидер романтика, тылсым бардыр сыман. Хәзер бит ирнең – хатынына, хатынның иренә вакыты юк. Берсе җанатарлар кафесында дуслары белән сыра чөмерә, икенчесе фитнес клубта тәненең бәгъзе өлешләрен кабарту белән мәшгуль. Кем өчен кабарта диген. Ире белән кара-каршы утырып сөйләшмәгәч тә. Балчык әйләнмәсе исә ир вә хатынны берләштерә, асылга кайтара. Борынгы һөнәрләр адәм баласына тормыш, кешелек асылын хәтердә яңартырга, кирәксез ыгы-зыгы, әһәмиятез вак-төяктән арынып торырга мөмкинлек бирә. Биш ел кулга-кул тотынып балчык әвәләгәнгә, әнә, күр, Диләрә һәм Артур Шакировлар нинди матур, тәлинкәләре генә түгел, үзләре дә карап туйгысыз...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

**ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124**

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 15.12.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2550 данә

Заказ 2648

16+